КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

# Мәдәни Җомга

№ 6
25 август
1995 ел

1995 елның июленнән башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы

# ТАТАРСТАН МӨСТӘКЫЙЛЬ БУЛСЫН ӨЧЕН ТАГЫН НИЧӘ «БИШЬЕЛЛЫК» КИРӘК?

بسم الله الرحمن الرحيم

Күпме генә өскә үрелсә дә,
Чиркәүләрдән өстә Ай тора...

## МӨХӘРРИР МОНБӘРЕ

Бүген Туфан Миңнуллинга 60 яшь тулды. Без олуг әдибебезне якты да, бераз ямансу да бәйрәме белән ихластан котлыйбыз. Ләкин „Аэрофлот" шатланмасын: Туфан ага әле дә булса самолетка утырмый, күктә очуга караганда, җирдә йөрүне мәгъкульрәк күрә, чөнки аның язганнары да Җир һәм Җир кешеләре хакында!

Газинур МОРАТ

## МИН ӘЙТТЕМ

**Рафаэль ХӘКИМ,**
**Татарстан Президентының дәүләт киңәшчесе**

# Татарстан үрнәге дөньяга танылды

***«Татарстан моделе» — яңа парадигма. 1990 елда Татарстанда суверенитет мәсләге җәмәгатьчелек аңында иң беренче урында торды. Шуның өстенә аңа битарафлар да аз булды. Суверенитетны яклаучы һәм аңа каршы кешеләрне тулысы белән менә шушы мәсләк яулап алды. Берәүләр аны яклады, икенчеләре аңа каршы көрәш алып барды. Татарстан белән Россия арасында төзелгән Килешү дә хокукый яктан беркетелүгә үк ул элекке иҗтимагый динамизмын югалтты һәм гамәлдә эшләүче категориягә әверелеп калды. Килешүгә кул куелгач, иҗтимагый тормыштагы акцентлар урыны алышынды. Әгәр 1994 елга кадәр башка мәсьәләләргә караганда сәясәткә өстенлек бирелсә, бүген икътисадка күбрәк өстенлек бирелә. Промышленность хәленең начарлануы һәм халыкның тормыш дәрәҗәсе түбәнәюе дә моңа сәбәпче булды. Бер сүз белән генә әйткәндә, без сәяси тотрыклылык булдыру мәсьәләсен хәл итә алдык, хәзер көн тәртибенә икътисади тотрыклылыкны булдыру мәсьәләсе килеп баса.***

Россия иҗтимагый фикерне сәяси яктан нығытмыйча һәм җәмгыятьне аңа алдан әзерләп куймыйча «шок терапиясе» ысулы белән генә бөтен икътисадны дөнья югарылыгына чыгармакчы иде. Юкса, тарихта мондый омтылышлар бер генә тапкыр булмады. «Бер рәте килеп чыгар әле»гә һәм киңәшчеләрнең тозсыз тәкъдимнәренә ышанып «реформаторлар» илне шундый хәлгә китереп җиткерделәр ки, алга таба бару юлында узып чыга алмаслык киртәләр барлыкка килде, ә артка табан сәяси низагларсыз гына чигенү һич мөмкин түгел булып чыкты. Россиядә реформалар үткәрү өчен тиешле тотрыклылык юк һәм лидерларны икътисад мәсьәләләренә караганда күбрәк 1996 елда яңа президент сайлау мәсьәләсе борчый. Бу мәсьәләне булачак сайлауларда «сул» канатны тәшкил иткән элекке коммунистларның өстенлек алачагы һәм моның дәүләт тарафыннан икътисадны тагын да ныграк күзәтү астында тоту мөһимлеген тудырачагы катлауландыра. Ил икътисадны үзәкләштерүдән базарга табан бару юлында ярты юлда туктап калачак. Татарстан Республикасында «шок терапиясеннән» баш тарту сәяси яктан акланган карар булды. Әмма без мондый адымның өстенлекләреннән файдалана алмадык. Нәтиҗәдә, Татарстанның хәле барлык күрсәткечләр буенча да гомумроссия хәленә якынаеп бара. Ә тормыш өчен әһәмиятле кайбер базар инфраструктураларын үстерүдә (мәсәлән, финанс-банк структураларын) ул аутсайдерлар хәлендә калды. Сәбәбе — стратегия булмау. Министрлыкларның һәм ведомстволарның көчле активлыгы бердәм максатка юнәлдерелмәде. Социаль гаделлек категориясенә өстенлек бирелеп, ул икътисади үсеш мәсләгенә буйсындырылмады. Халыкны якларга кирәк, әлбәттә. Әмма бу мәсьәләне төрлечә хәл итеп була. Ярлы хәленә төшкән кешеләргә, эшсезләргә бюджеттан акча бүлеп бирергә була, әмма эш урыннары булдыру һәм производствоны үстерү стимулларын булдыру белән дә шөгыльләнергә мөмкин бит. Беренче очракта бюджетка басым ясалыр һәм хөкүмәттә салымнарның күләмен арттыру теләге уяныр. Шуның нәтиҗәсендә җитештерүчәнлек тә кими. Мәгәр дәүләт яңа эш урыннарын булдыру (әйтик, хезмәт күрсәтү өлкәсендә) өчен шартлар тудыра икән, ул шуның белән бергә үзен күп кенә социаль проблемалардан да азат итә. Чыннан да, мөстәкыйль рәвештә акча эшли алган кеше дәүләт ярдәменә мохтаҗ түгел. Шуның өстенә әле ул үзенең бер якын туганын да эш белән тәэмин итә ала. Дөрес, бу очракта җитештерүчеләргә салына торган салымнарның, аренда өчен түләүнең күләмен киметергә, яңа предприятиеләрне теркәүнең тәртибен гадиләштерергә һ.б. шуның ише чаралар күрү зарурлыгы туа. Хакимиятләргә акча санап утырудан бигрәк, яңа уңайлы шартлар тудыру турында уйларга кирәк булачак. Хәзерге вакытта бюджетның киеренке хәлдә булуын, ә салым түләү күләменең иң соңгы ноктасына күтәрелүен исәпкә алсаң, республика өчен бердәнбер юл гына кала. Ул — товар җитештерүчеләр өчен уңайлы шартлар булдыру. Татарстанда икътисад мәсләге гаять кысыр булып чыкты. «Үзгәртеп кору» башында ул бер төркем башлангычлар белән бергә барлыкка килде һәм күпләрне республикадагы икътисади хәлнең үзенчәлекле күптөрлелеге турында уйланырга мәҗбүр итте. Әмма аннары ул бик азларны гына кызыксындыра торган кирәгеннән артык озын һәм моңсу телевизион тапшырулар, мәкаләләр рәвешен алды. Сайлау алды кампаниясе депутатлар арсеналында икътисади мәсләкләр булмауны күрсәтте. Бу — икътисадчыларның иҗтимагый тормышта тоткан рольләре кимүнең ачык бер билгесе. Алай гына да түгел, безнең галимнәр, икътисади кризистан чыгу юлларын күрсәтә алмау белән бергә, җәмәгатьчелекне башка илләр тәҗрибәсе белән дә таныштыра алмадылар. Нәтиҗәдә без һаман саен катлаулана һәм үрчи баручы проблемалар алдында көчсез хәлдә калдык, ә хөкүмәт комиссияләре бердәм икътисади идеология булмау сәбәпле төрле программалар әзерләүдә дөрес юл таба алмадылар.

Татарстанда федераль җитәкчелекне буш сепаратлык белән куркытудан шүрләп үҗәтлелек белән Россия җирлегендә бердәм икътисади яссылык булдыру турында тәкрарладылар. Предприятиеләр ышанычлы эчке базар һәм шул ук вакытта саклауга мохтаҗ булган Россиягә һәм БДБгә юнәлеш тоттылар. Көнбатыш фирмалар, яңа хәлдән бик тиз файдаланып, күпләп үз товарларын китерә башладылар.

**(Ахыры 12 нче биттә).**

*30 августта Татарстанның дәүләт мөстәкыйльлеге турындагы Декларация кабул ителүгә биш ел тула. Бу уңайдан «Мәдәни җомга» хәбәрчеләре зыялыларыбызга, предприятие эшчеләренә:* ***«Җөмһүриятебезнең эш-гамәлләрендә һәм шәхсән үз тормышыгызда Декларациянең йогынтысы сизеләме?»*** *— дигән сорау белән мөрәҗәгать итте. Әлеге гәзит сәхифәләрендә без аларның җавапларын урнаштырабыз.*

- **Индус ТАҺИРОВ,**
Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты рәисе, Татарстанның халык депутаты, академик:

**— Һичшиксез сизелә. Беренче чиратта, без үзебезнең элек омтылган союздаш республика принципларын нигездә гамәлгә ашырдык дип уйлыйм. Кискен көрәш шартларында Конституциябезне кабул иттек. Конституциянең күп маддәләре Шартнамә нигезендә Русия тарафыннан танылды. Әлбәттә, бүгенге шартлар белән чагыштырып караганда, монда ризасызлык тудыра торган мизгелләр дә юк түгел. Килешү нигезендә кайбер чигенүләргә барырга мәҗбүр булдык. Мәсәлән, Русиянең Татарстандагы вазифаларын һәм уртак вазифаларны билгеләү мәсьәләсендә кирәгеннән артыграк ташламалар ясап ташладык. Гомумән, сәясәттә мәҗбүрият булуын онытырга ярамый, һәм ул мәҗбүрият көчле һәм көчсез арасындагы мөнәсәбәтләр нигезендә килеп чыга. Көчлегә аргумент кирәкми. Декларацияне референдум аша халык фикере белән ныгытып Конституция кабул итү, аны юридик югарылыкка күтәрү — төп казанышыбыз.**

**Инде килеп, Декларация кабул ителгәнче безнең 2-4 процент милкебез генә үзебезнеке булса, хәзер милекнең 90 проценты теге яки бу рәвештә үзебезнеке санала. Моның нәтиҗәсе күз алдында. Безнең авыл хуҗалыгындагы хәлләр Русиянекеннән бөтенләй үзгә. Авыл хуҗалыгыбыз үсеше һәммә республикага, һәммә өлкәгә, гомумән, Русиягә үрнәк булып тора.**

**Милек мәсьәләсе — иң авыры. Дөньядагы бөтен тавыш-гауга милек мәсьәләсендә килеп чыга. Салым, бюджет мәсьәләсендә парламентларда өзлексез көрәш бара.**

**Халыкара мөнәсәбәтләргә килгәндә дә, элеккеге суверен республикалар чит илләр белән үзара мөнәсәбәтләр урнаштыра, мөстәкыйльлекләрен тиешенчә файдалана алмыйлар иде. Ә хәзер безнең Татарстаныбыз дөньяга чыгып килә, үзен дөнья күләмендә таныта бара.**

**Кыскасы, Декларациябез искиткеч зур әһәмияткә ия. Аның әһәмиятен әле без үзебез дә бәяләп бетерә алмыйбыз. Ул документ — тулы бәйсезлек Декларациясе, чөнки, анда күрсәтелгәнчә, без СССРда да (ул хәзер юк инде), РСФСРда да түгел. Декларациядә без Русиядә дип тә күрсәтелмәгән. Шуңа күрә ул — тулы бәйсезлекнең нигезе.**

Җидегән

вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

5 6 7 1 2 3 4

# УРАКЛАРЫ УРЫЛГАН, ЗУРАТЛАРЫ КУЕЛГАН

ТЕЛЕГРАММА

Лицевой счет №

Телефон № г. Казань ул., д №

Передана

из г. Казани

слов

ПРАВИТЕЛЬСТВЕННАЯ

Проверил

(Куда, Кому) Главе администрации

Точный адрес. Ютазинского района

товарищу Хайруллину Р.Н.

**Җөмһүриятебезнең олы бәйрәме алдыннан Актаныш, Минзәлә, Ютазы, Менделеев районнары хакимиятләре башлыклары А.Хәбибуллин, И.Исламов, Р.Хәйруллин, В.Вахитов Татарстан Президенты М.Шәймиевкә урып-җыюны уңышлы төгәлләүләре һәм дәүләткә ашлык тапшыру йөкләмәләрен үтәүләре турында телеграмма җибәргәннәр иде. Шушы уңайдан Илбашыбыз әлеге районнарның фидакарь игенчеләрен быелгы катлаулы шартларда яхшы уңыш үстерүләре һәм Ватан алдындагы изге бурычларын үтәүләре белән ихлас тәбрикләде. аларга сәламәтлек, иминлек һәм яңа хезмәт казанышлары теләде.**

## Мәскәүләр дә юмартланыр икән...

*Русия Федерациясенең гадәттән тыш хәлләр буенча министры Сергей Шойга, Казанга килгәч, Яшь тамашачылар театрына да сугылды. Аны бирегә сәхнә сәнгате белән «түзеп тора алмаслык» кызыксыну түгел, ә төп хезмәт вазифасы тартып китергәндер. Инде белгәнегезчә, борынгы мәһабәт бинада урнашкан яшьләр театры шушы ел башында кинәт янып киткән иде. Хәзер бирелә төзекләндерү эшләре бара. Татарстан Президенты каршындагы мәдәниятне үстерүгә булышлык фонды да бәлагә тарыган театрга хәл кадәре ярдәм күрсәтә. Һәм менә РФ хөкүмәте әгъзасы С.Шойга да үз маясыннан «кызыл әтәч» зыянын капларга 3 миллиард сум акча бүлеп бирергә вәгъдә итте.*

*Көтеп карыйк әле: Русия министры сүзендә торырмы икән?! Үз заманында Явыз Иван явыннан бихисап зыян күргән Казан Кремлен төзекләндерү өчен дә мәскәүләр шактый күләмдә акчалата ярдәм вәгъдә иткәннәр иде...*

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгы чакыруы буенча 22 августта Казанга Русиядән һәм чит илләрдән, шул исәптән Германия, Англия, Финляндия һәм Берләшкән Гарәп Әмирлекләреннән зур төркем журналистлар килде. Кремльдә, Президент резиденциясендә аларны М.Шәймиев кабул итте. Президент кунакларны, республикабызның матбугат, телевидение һәм радио вәкилләрен җылы сәламләде, аларга Татарстанда эшләрнең торышы турында сөйләде.

Хәбәрчеләрнең иҗтимагый тормыштагы төрле якларга бәйле күп санлы сорауларына җавап биреп, М.Шәймиев Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациянең кискен низаглы проблемаларны хокукый юл белән хәл итүдә, [illegible] социаль һәм мәдәни үсешендә бик зур роль уйнавын билгеләп үтте. Бу Декларация Русия Федерациясе белән Шартнамә төзү һәм Татарстан Конституциясен кабул итү өчен нигез булып торды. Суверенитет Татарстанның күп милләтле бөтен халкы исеменнән игълан ителде һәм аның социаль тотрыклылыгының нык җирлегенә әверелде. Татарстан Республикасы, Русия белән үзара мөнәсәбәтләр проблемаларын цивилизацияле юл белән хәл итә барып, аның чын федерализация һәм демократизациягә баруы өчен юл сала.

Декларация һәм Русия белән Шартнамә безгә потенциаль инвесторларны табарга, киң дөньяга чыгарга, чит ил базарларын үзләштерергә мөмкинлек бирә, дип дәвам итте үзенең сүзен Президент.

Икътисад проблемаларына мөстәкыйль, иҗади якын килү нәтиҗәсендә Татарстан халкы күчеш чорының кыенлыкларын Русиянең башка төбәкләрендә һәм [illegible] БДБ илләрендәгегә караганда җиңелрәк кичерә. Хәзер икътисади стратегия күп яктан Татарстан товарларының конкурентлык сәләтен күтәрүдән һәм шул нигездә тотрыклылыкка ирешүдән, ә тора-бара халыкның тормыш дәрәҗәсен үстерүдән гыйбарәт.

Кремльдә очрашуда Премьер-министр урынбасары И.Хәйруллин, мәгълүмат һәм матбугат министры И.Әхмәтҗанов, Президентның матбугат үзәге җитәкчесе Ә.Хәсәнов катнашты.

● **Журналистларны кабул итү вакыты.**

## Талантның милләте бармы...

Казан дәүләт консерваториясе каршындагы махсус музыка мәктәбе укучылары Даша Работкина (Н.Казачкова классы) һәм Марина Киндер (Е.Бадерин классы) өчен уку елы быел иртәрәк башлана. Алар яшь пианистларның П.Чайковский исемендәге конкурсында катнашу өчен Японияго китәләр. Ә менә Татьяна Халтурина (М.Сухаренко классы) Италиядә үткәреләчәк торган бәйгегә җыена.

Татарстан башкаласында, шөкер, танылган пианистлар байтак. Бу җәһәттән иҗади алмашның үсеп килүе дә сөендерә. Тик менә дөнья күләмендәге ярышларга китүче яшь пианистлар арасында татар балаларының булмавы гына шөбһәгә сала. Нәрсә, безнең татар балаларының талант дәрәҗәсе шулай ук чамалымыни?..

## Моңлы кыз

*Фәридә Кәлимуллинаны кечкенәдән үк шаяртып Фәридә Кудашева дип йөртәләр. Музыка мәктәбендә укыганда да ул ике еллык программаны бер елда үзләштерә. Фәридә кулына килеп эләккән теләсә нинди музыка коралыннан моң агыла башлый. Уен коралларында уйнау буенча Азнакай шәһәре һәм районы буенча 1993 елда лауреат исемен яулаган иде ул, шул ук елны Татарстанның яшь гражданнары форумында Азнакайдан делегат та булды.*

*Фәридә хәзер Әлмәт музыка училищесында укый. Якташлары аңа зур өметләр баглый. Фәридәнең бөреләнгән таланты якын елларда шаулап чәчәк атыр һәм милли сәнгатебез күгендә тагын бер яңа йолдыз кабыныр дип ышанабыз.*

## Бетәбез бит, җәмәгать...

*Татарстан дәүләт статистика комитеты 1994 елда җөмһүриятебездәге демографик хәл турындагы мәгълүматларны дөньяга чыгарды. Бездәге халык саны күчеп кайтучылар исәбенә 11,2 мең кешегә артып, 3754,8 мең кеше тәшкил иткән. Соңгы унике ел эчендә бу бик кечкенә күрсәткеч, 1993 ел белән чагыштырганда, халыкның артуы илле процентка кимегән. Бу хәл табигый үсешнең нык кимүе белән аңлатыла. Кимү 1993 елда 3,2 мең кеше тәшкил итсә, 1995 елда ул 6,8 меңгә җитте. Соңгы бер ел эчендә генә дә Татарстанда яшәүчеләрнең уртача гомер озынлыгы 2 елга кыскарды.*

*Күчеп кайтучыларның яртысыннан артыгы (55,5 проценты) — Русия Федерациясенең башка төбәкләрендә яшәүчеләр. Кайтучыларның 16,7 проценты — Үзбәкстаннан, 8,5 проценты — Казакъстаннан, 5,1 проценты — Таҗикстаннан, 4,3 проценты — Украинадан, 4,1 проценты — Кыргызстаннан. Күчеп кайтучыларның 49,7 проценты — татарлар (23586 кеше), 34,1 проценты — урыслар (16197 кеше).*

*Демографик фаразларга караганда, Татарстанга күчеп кайтучылар саны әкренләп кимиячәк һәм якындагы ике ел эчендә уртача 15 процентка азаячак. Якын арада күчеп кайтучылар саны Татарстандагы халыкның табигый кимүен каплый алмаячак, һәм 2000 елга Татарстан да халык саны кими баручы төбәкләр рәтенә керәчәк.*

## «Нигә филармониядән киттем?»

*Соңгы вакытта сәхнә осталары арасында әнә шундый сорауга үзләренчә аңлатма бирүчеләр күбәйде. Җөмһүриятебезнең атказанган артисты Мнир Соколов та «Республика Татарстан» гәзитендә (171 нче сан) Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясеннән китәргә мәҗбүр булуының сәбәпләрен аңлаткан. «Мин илдәге күп кенә концерт оешмаларының эшчәнлеге белән хәбәрдар, — дип яза ул, — әмма безнең филармониядәге кебек сүлпән иҗади мохитны, артистларны санга сукмау күренешен, җитәкчелекнең компетентсызлыгын беркайда да очратмадым...»*

*Ачынып әйтелгән әлеге сүзләргә Зөһрә Сәхабиева, Римма Ибраһимова, Эмиль Җәләлетдинов, Асаф Вәлиев, Зөһрә Шәрифуллина, Рәшит Сабиров, Марат Сиражетдинов һ.б. күп кенә эстрада маһирлары кушыламы икән? Әгәр иҗаттašларының фикерен җөпләмәсәләр, нигә соң алар филармония белән исәп-хисапларын өзгәннәр?..*

## Җомгадан — җомгага.

### Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

**Президент М.Шәймиев Кремльдә гражданлык оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү буенча Русия Федерациясе министры С.Шойганы кабул итте.**

Биектау районының «Бөреле» агрофирмасында машина белән сыер саву осталарының XYII Бөтенрусия конкурсы булып узды; абсолют чемпион исеменә «Түбән Кама» совхозыннан Алевтина Гыйсмәтуллина лаек булды.

Идел буе һәм Идел-Нократ төбәкләрендәге сигез өлкәдән һәм биш республикадан Казанга салым полициясе хезмәткәрләре киңәшмәгә җыелды.

**Татарстан Президенты М.Шәймиев Кремльдә район, шәһәр хакимиятләре башлыклары, Президент аппараты, Дәүләт Советы, Министрлар Кабинетының җаваплы хезмәткәрләре катнашында киңәшмә уздырды.**

Милли Мәҗлес рәисе, «Иттифак» фиркасе җитәкчесе Фәүзия Бәйрәмова төрки милли-хәрәкәт партиясенең махсус чакыруы буенча Төркиядә булып кайтты.

**Шушы елның августында Кыргызстанның иң гүзәл урыннарыннан саналган Ыссык Күлдә төрки халыклар яшьләре көннәре булып үтте.**

Төркиягә эш визиты белән барган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Василий Лихачев бу илнең Бөек халык җыелышы рәисе Хисаметдин Җиндорук белән очрашты.

***«Татар-Информ» мәгълүматлары, башка чыганаклар һәм авторлар хәбәрләре файдаланылды.***

# Республикабыз көнен ничек бәйрәм итәбез?

## КАЗАН

29 август көнне Муса Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында бәйрәм утырышы була. Концерт программасында Лима Кустабаева җитәкчелегендәге Халыклар дуслыгы орденлы Дәүләт җыр һәм бию ансамбле, Илһам Шакиров, Ренат Ибраһимов, Зилә Сөнгатуллина, Венера Ганиева, Салават Фәтхетдинов кебек күренекле җырчыларыбыз катнаша.

Бәйрәм бик күп урыннарда була. 30 августта ипподром белән Үзәк стадионда башланып, Кабан күле, Уң һәм Сулъяк Болак буена, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры алдындагы мәйданга кадәр барып җитәчәк.

Кабан күлендә төрле тамаша, көймәләрнең күргәзмә чыгышы була. Теләгән кешегә көймәдә йөрергә дә мөмкин.

Ипподромда иртән ат ярышлары уздырыла.

Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасы каршындагы мәйданда төрле конкурсларда катнашырга мөмкин булачак. Гаилә бәйрәмнәре үткәрү дә күздә тотыла. Кечке бал-бәйрәм вакытында биеп-җырлап күңел ачу мөмкинлеге көтелә.

Болак буенда беренче тапкыр шәһәребезнең төрле район вәкилләре җыеласы. Анда һәр район үз программасы белән чыгыш ясарга тиеш. Бу көннәрдә Болакка чиста су тутыру эшләре бара. Бөтен фонтаннарны эшләтү өчен су күп кирәк булачак. Болак буе матурланыр һәм казанлыларның яратып ял итә торган урынына әверелер.

Дәүләт һәм коммерция сәүдә оешмалары казанлыларны һәм кунакларны тәмле ризыклар белән сыйларга әзерләнә.

Үзәк стадионда тамашачылар төрле спорт ярышлары, иҗат коллективларының берләшкән концертларын карый алырлар.

## ЧАЛЛЫ

Иң зур мәйданда үтәчәк сәхнәләштерелгән кичәдә Чаллының яшьләре һәм олы яшьтәге кешеләре катнашындагы «Ваза» һәм «Торт» композицияләре аеруча матур булмакчы. Бәйрәмнең спорт-күңел ачу өлешендә гаилә ярышлары, балаларның «Күңелле стартлар»ы, кул көрәше, шахмат ярышлары, бау тартышу, кечкенә атта йөрү, төрле конкурслар һәм турнирлар үткәреләчәк, иң яхшы җырчылар, биючеләр, музыкантлар һәм цирк артистлары катнашында сәнгать осталары концерты булачак.

## Балтыйк буе татарлары берләшә

Гданьски шәһәрендә (Польша) Балтыйк буе татарларының беренче халыкара конференциясе булып узды. Конференциядә Польша, Беларусь, Литва, Латвия, Эстония татарлары делегацияләре катнашты. Милләттәшләребез татарлар күпләп яшәгән Сокулке һәм Белосток шәһәрләрендә булдылар. Польша татары — борынгы татар морзалары нәселеннән чыккан Минсәид Байрашевский проекты буенча Гданьски шәһәрендә төзелгән мәчеттә җомга намазы укыдылар.

Конференциядә мәдәният чаралары үткәрү дә каралган иде. Кунаклар Каунас шәһәреннән килгән «Ләйсән» балалар ансамбле концертын бик яратып карадылар. Яшь башкаручылар Белосток, Сокулке шәһәрләрендә дә концерт күрсәттеләр.

## Афәрин, «Хыял», афәрин, Закир!

Тампереда (Финляндия) халыкара хор музыкасы фестивале булып үтте. Анда Франция, Югославия, Чехия, Филиппин, Сингапур һәм Русиядән 52 хор коллективы килгән иде. Русиядән фестивальдә Екатеринбург малайлар хоры һәм Казаннан «Хыял» хор коллективы (Казан педагогия университеты музыка факультеты, җитәкчесе — хормейстер һәм баш дирижер Әлфия Җаббарова) катнашты.

«Хыял» хоры «көмеш» бүләккә — 4 нче урынга лаек булды. Бу — хорның зур уңышы. Халыкара хор фестивалендә «Хыял»ның алдынгы урын алуында аның башлап җырлаучысы — Закир Шаһбановның да өлеше зур. Закир (ул беренче группа инвалид) халыкара татар җыры конкурсында да (апрель, 1995) лауреат исемен яулаган иде.

## «Идел» кунак җыя

Кичә «Идел» яшьләр лагеренда Татар яшьләре көннәре башланды. Аны Татарстанның балалар һәм яшьләр эшләре буенча дәүләт комитеты, Татарстан яшьләр оешмалары советы, Бөтендөнья татар конгрессы башкарма комитеты оештырды.

Бу «көннәрдә» катнашучылар өчен «түгәрәк өстәл»ләр, секцияләр эшли. Алар республиканың җитәкчеләре, күренекле кешеләре, фән эшлеклеләре, иҗат зыялылары белән очрашалар, борынгы Болгарда, башка тарихи, истәлекле урыннарда булалар.

«Идел»гә Мәскәүдән, Санкт-Петербургтан, Ульяннан, Ырынбурдан, Самарадан, Ташкенттан, Чиләбедән, Ижаудан, шулай ук Финляндиядән, Төркиядән кунаклар килде.

## Күргәзмә залларында



Инде хәбәр ителгәнчә, Казанның Күргәзмәләр залында Республика көне уңаеннан зур экспозиция ачылды. Анда Татарстанның үткән тарихы һәм бүгенгесе турында сөйләүче 150 дән артык әсәр тәкъдим ителгән. Җөмһүриятебез мөстәкыйльлегенә багышланган әлеге икенче күргәзмә (беренчесе 1991 елда оештырылган иде) соңгы дәвердә сынлы сәнгать осталарының яңа иҗат баскычларына күтәрелә баруын раслый. Бирелә моңарчы «табу» салынган темаларны яктырткан әсәрләр дә урын алган.

А.Абзгильдин тарафыннан иҗат ителгән «Мәшһүр курайчы Ишмулла Дильмөхәммәтов портреты»; күргәзмәдән күренеш.

## Сәясәтне — яшьләргә

Шушы елның 23-24 ноябрендә Казанда «Яшьләрнең дәүләт сәясәтен фәнни тәэмин итү» дигән темага Бөтенрусия гыйльми-гамәли конференция булачак.

Бу конференцияне үткәрүнең максаты — фән әһелләрен яшьләрнең дәүләт сәясәтен гыйльми нигездә эшләүгә тарту.

## Бик тәмле күмәч

*Түбән Каманың икмәк комбинатында «Юбилейный» дип аталган тәмле күмәч пешерә башладылар.*

*«Юбилейный» күмәченең составында шикәр, май аз була, шуңа күрә аны организм җиңел үзләштерә.*

*Үзенә аерым бер рецепт белән пешерелгәнлектән, бу күмәч тиз генә искерми дә.*

## Кешеләрне аулау хакында...

Соңгы вакытта язучы Диас Вәлиевнең өч китабы дөнья күрде. Аның берсе «Охота убивать» дип атала. 80 битле бу китапта безнең өч композиторыбыз — Фәрит Яруллин, Салих Сәйдәшев, Нәҗип Җиһанов турында да язмалар бар. Монда хәтта үлгән кешеләрне дә юк итү турында, фаҗигале язмышлар, кешеләрне аулау хакында өр-яңа мәгълүматлар урнаштырылган.

Язучының икенче китабы «Необыкновенные приключения двух друзей» дип атала. Бусына — 2 яшьтән алып 70 яшькә кадәр булган балалар өчен әкиятләр тупланган. Мондагы әкиятләрне китапны иңләп-буйлап йөри торган каһарман берләштерә.

Д.Вәлиевнең яңа чыккан тагын бер китабы «В омуте бесовства и смуты» дип исемләнгән. Язучы соңгы елларда ил, җәмгыять, кешеләр белән булган хәлләрне күздән кичерә.

Китапларны «Таң» нәшрияты бастырып чыгарган.

Аларны чыгаруда «Сиразин һәм К°» фирмасы, «Кулон» фәнни-җитештерү фирмасы, «Сәүдәгәрләр-төзүчеләр берлеге» акционерлык җәмгыяте һәм «Стройкоммаш» предприятиесе; «Теплоконтроль» җитештерү берләшмәсе, «Вторчермет» җитештерү берләшмәсе, «Татснаб» акционерлык җәмгыяте», «Концерн Банк» Казан акционерлык җәмгыяте химаячылык иткән.

## Батырларны эзләү дәвам итә

«Долина» дигән эзләнүләр төркеме, сугыш үткән җирләрдә һәлак булып, җирләнмичә калган кешеләрне эзләүне дәвам иттерергә сәфәргә чыгып китте. Бу төркемдә Казан дәүләт университеты, Казан химия-технология университеты студентлары, һөнәр мәктәбе укучылары катнаша.

## Өч телле гәзит

Литва татарлары өчен махсус нәшер ителә торган «Лиетувос тоторяй» («Литва татарлары») гәзитенең бишенче саны чыкты. Ул әлегә айга бер тапкыр гына нәшер ителә. «Лиетувос тоторяй»нең беренче дүрт саны литва һәм урыс телләрендә дөнья күрде. Бишенче санында исә полякча да мәкаләләр бар.

1997 елда Литва татарлары бабаларының Бөек Литва кенәзлеге җирләрендә яши башлауларының 600 еллыгын билгеләп үтәчәк. Җирле халык белән нык аралашкан татарлар, XYI гасырда ук ана телләрен онытсалар да, милли гореф-гадәтләрен саклап калганнар. Хәзер татарлар арасында литвача да, полякча да, урысча да сөйләшүчеләр бар. Литва теле дәүләт теле статусын алгач, татарлар ул тел белән тагын да ныграк кызыксына башладылар. Олы яшьтәгеләргә яңа телне өйрәнү авыррак, әлбәттә. Менә шуңа күрә «Лиетувос тоторяй» гәзите өч телдә чыга да инде.

## Чувашстан мөселманнары мөфти сайлады

Чабаксар шәһәрендә Чувашстан җөмһүрияте мөселман берләшмәләре вәкилләренең чираттан тыш беренче корылтае булып үтте.

Корылтайда дин һәм тәрбия эшләренең торышы, аларны яхшырту чаралары турында нотык тыңланды, төбәкләрдән килгән делегатларның чыгышлары булды.

Чувашстан җөмһүрияте мөселман дини берләшмәләренең Низамнамәсе кабул ителде.

Голәмалар шурасы, диния нәзарәте президиумы, үзәк ревизия комиссиясе һәм Чувашстан җөмһүрияте мөселманнарының диния нәзарәте рәисе — мөфти итеп Морад хәзрәт Архипов сайланды.

Корылтайда Русия мөселманнарының югары координация үзәге рәисе, Татарстан җөмһүрияте мөфтие, шәех Габдулла хәзрәт Галиулла катнашты.

*«Алтмышың мөбарәк булсын, картлач!..»*

Улың Әлмәндәр.

# ТУФАННАРДАН УҢДЫ ХАЛКЫБЫЗ

Туфан Миңнуллин — гаҗәп талант иясе. Берсеннән-берсе оста, талантлы сәхнә әсәрләрен коеп кына куя, коеп кына тора. Ходай аңа оригиналь фикерләү сәләтен, тормышны өйрәнә белү тырышлыгын, аны чагылдыру осталыгын бер дә кызганмый биргән.

Заманыбызның, тормышның кайсы ягына гына кагылмасын, Туфан аны үзенчә күрә, үзенчә бәяли һәм халык күңеленең иң нечкә кылларын тибрәндерерлек итеп сурәтли. Аның һәр әсәрендә әллә никадәр табыш бар. «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр», «Үзебез сайлаган язмыш», «Әниләр һәм бәбиләр», «Гөргөри кияүләре» һәм башка бик күп спектакльләр — болар бит татар тормышының энциклопедиясе. «Әлдермештән Әлмәндәр», гомумән, мәңгелек, классик әсәр.

Туфан, икенче яктан, татар сәхнә сәнгатенең иң бай, иң мул, иң үзенчәлекле иҗат чыганагы. Безнең театр сәнгатен ул әйдәп бара, дисәм дә һич артык булмас. Галиәсгар Камал, Мирхәйдәр Фәйзи, Кәрим Тинчуриннар традицияләре бүген Туфан әсәрләрендә дәвам итә, үсә. Дөньяда яшәүнең тирән фәлсәфи мәгънәсен Туфан Миңнуллин әхлакый чисталык, пакь намус белән бәйләп, эмоциональ-тәэсирле, үтемле, гыйбрәтле, тормышчан итеп тасвирлый.

Туфан Миңнуллин — бәхетле талант иясе, чөнки халык аны күптән инде үз итте, яратты һәм ярата. Мин аңа тагын да иҗади уңышлар, озын гомер телим.

**Минтимер ШӘЙМИЕВ,**
**Татарстан Республикасы Президенты.**

## Чакматаш

Туфан Миңнуллин белән безнең тормыштагы мөнәсәбәтләр төрлечә булды: без бер-беребезне яраттык, Язучылар берлегенең арбасын бергәләп тарттык. Булды бер-беребезне өнәмәгән чакларыбыз да. Алары объектив сәбәпләрдән дә, субъектив сәбәпләрдән дә килеп чыкты.

Әмма иҗат мәсьәләсендә мин Туфанны беренче әсәрләреннән үк үз күрдем. Табигать биргән гомерлек таланты, чәч пәкесе кебек үткен, образлы теле, сәхнәне бик яхшы тоя белүе белән ул татар драматургиясен союз аренасына кадәр алып чыга алды. Җанга бер очрашуда урнашып кала торган милли образлары белән ул Кәрим Тинчуриннар мәктәбен яңа шартларда үстерә, камилләштерә барды. Бу нисбәттән аның туксан яшьлек Әлмәндәре — мәңгелек. Аның кыю каләме аркылы Канкай батырлар, Тукайлар, Җәлилләр дөньяга чыкты, гап-гади җир кешеләре зирәк акыллары белән тамашачыларны таң калдырды.

Минем үземне гаҗәпләндергән нәрсә — Туфан Миңнуллинның үз холкы. Мин аны чакматашка тиңләр идем. Чакматашка игәү белән суксаң, очкын сибелә. Туфанның чакматаш каләменә юлыккан тормыш материалыннан да дөрләп-дөрләп ут сибелә. Туган җиренә булган олы мәхәббәте — ватандарлыгы да, туып-үскән авылын тергезүе дә, мәчетләр, һәйкәлләр салдыруы да — барысы да аны яратырга, хөрмәт итәргә, утыз ел эчендә ул иҗат иткән кырыктан артык сәхнә әсәре, аларның беркайчан да бер-берсен кабатламавы аның усал холкын өнәп бетермәүчеләрне дә аның алдында, аның сәнгате каршында ихтирам белән баш иярга мәҗбүр итә. Татар драматургиясен Туфан Миңнуллин кебек фидакяр талантлар гына алга илтәчәк, дип авыз тутырып әйтергә мөмкин.

**Гариф АХУНОВ,**
Татарстанның халык язучысы,
Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе.

**Асия ЮНЫСОВА**

## «Җирдән аерылудан куркам мин»

— Нихәл, брат! — телефонда Туфан Миңнуллин тавышы. «Брат!» — димәк, Туфан абыйның кәефе шәп. — Урыныңда буласыңмы? Бер игелекле эш эшлик әле.

Ә ул ике милләт — татар һәм башкорт — язучыларының уртак мөрәҗәгать текстын язган һәм һәр ике тарафтан имзалар да куйдыртып өлгергән икән, хәзер шуны гәзит аша халыкка игълан итү хәстәренә керешкән. Кәеф шәплеге дә шуңа — шәп һәм зур, олы ниятле эшне башкарып чыкканга. «Брат!»лы көннәр шактый, әмма кайсы гамәленең көнен эчтәлекле иткәнен һәрчак белеп бетерү кыен. Үзеннән-үзе «тишелеп» чыкса гына инде. Әйтик, мәрхүм шагыйрь Нури Арсланның балалары Язучылар берлеге белән судлашып йөргән арада Туфан Миңнуллин шагыйрь каберенә чардуганны ясатып та өлгергән — шуның белән бәхәс тә вәссәлам!

Кирәге чыгып торган көнне генә үзен Казанда таба алмыйсың. «Бәй, ишетмәдегезмени? Ул бит бүген туган авылы Мәрәтхуҗага мәчет ачарга кайтып китте. Үзе төзеткән мәчетне!» Димәк, «Туфан юлы»на «Туфан мәчете» өстәлгән. Йә, гәзитләрдәге репортаждан укып беләсең, — Туфан Миңнуллин призына Кама Тамагында бокс ярышлары үткәрелгән, ди. Анда Туфан абый алдырык (приз) тапшырган, ди. Алдырыкка әтәч (!) биргән, ди. Югыйсә, кичә генә редакциягә кереп чыккан иде, серне чишсә, ни була инде, йә!

Туфан абыйның барлык изге ниятләре дә «брат!» белән тәгәлләнми.

— Юк инде, җаным-бәгърем! — Яшенле яңгыр үтәчәк, шым торырга кирәк. Хәер, бу юлы яңгыр минем башка түгел икән. — Әгәр районында нибарысы 11 данә «Казан утлары», 8 данә «Идел» журналы алдыралар икән, бу районның хакимият башлыгы башын комга тыгарга тиеш. Оялудан түгел, куркудан! Кара, надан, укымаган халык куркыныч ул. Аны өндәп тә, күндереп тә, агартып та булмый. Нишләп халык арасына чыкмыйсыз! — Бусы инде безгә кагыла. — Ике атна авылларда йөрдем. Кама Тамагы укымый икән, аның ояты миңа бит!

Татарстан Дәүләт Советына депутатлыкка кандидат итеп күрсәтелгәч тә, кампаниягә үзагымына куйган Туфан абыебыз икенче кампания — гәзит-журналларга язылу башлангач, шифаханә (авырып ята иде) белән арасын бик тиз өзде. Димәк ки, ул гәзит мөнбәрен, Дәүләт Советының утырышлар залындагы мөнбәрен өстенрәк, изгерәк күрде! Ә кем әле алай түгел ди? Җәмгыять тормышындагы һәр үзгәрешкә үз бәясен курыкмыйча кем беренче булып бирә? Туфан Миңнуллин! Гәзит — мөнбәр. Хәзер исә аның Дәүләт Советы депутаты буларак та, мөнбәре бар. Ике ел элек аның турында

(Ахыры 6, 7 нче битләрдә).

**● Мирфатыйх ЗӘКИЕВ,**

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты директоры, академик:

**— Бигрәк тә икътисади мөстәкыйльлеккә, эчке сәясәттә һәм тышкы икътисади һәм мәдәни багланышларда Декларациянең йогынтысы нык сизелә. Шәхсән үземә килгәндә, Декларация кабул ителгәч, миңа Татарстан Конституциясе комиссиясе әгъзасы буларак эшләргә туры килде. Татарстан халыкларының телләре турындагы Законның өч проектын үз кулым белән төзеп бирдем. Шул Законны гамәлгә кую буенча дәүләт программасының проектын әзерләүне оештырдым, хәзер инде Министрлар Кабинеты каршындагы Тел комитеты рәисе ярдәмчесе буларак, шул юнәлештә эш алып барам.**

**Тел, әдәбият һәм тарих институтын Татарстан юрисдикциясенә күчерү дә шушы вакыйгалар белән бәйләнгән. Мин җитәкләгән телчеләр коллективының өч томлык татар грамматикасын төзеп чыгаруын һәм шул эшнең Татарстан дәүләт бүләгенә лаек дип табылуын да Декларация белән бәйләп карыйм.**

**Үзгәртеп корулар башлангач, 1988 елда миңа татар халкының тарихын язу коллективы оештырырга туры килгән иде (элек бит Татарстан тарихын язу гына модада иде). Декларациядән соң бу коллектив, тагын да интенсиврак эшли башлап, хәзер инде беренче зур китапны чыгару алдында тора.**

**● Ринат ТАҖЕТДИН,**

Татарстанның һәм РФнең халык артисты, Татарстанның Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе:

**— Ел буе яуган карны бер көндә генә көрәп бетереп булмагандай, халкыбыз өстенә гасырлар буена өелгән коллык чылбырларын без шушы биш ел эчендә генә өзеп бетерә алмадык инде. Шуны аңлагач, мин үзем бу мөстәкыйльлектән көтеп-көтеп тә, өмет итеп-итеп тә ирешә алмаганнарыбыз өчен дә ничектер юанып куям. Ә ирешә алмау ризасызлыгы шәхсән минем үземдә дә, аралашкан-белешкән кешеләремдә дә юк түгел. Әйтик, шул ук калымнар-салымнар мәсьәләсе, халыкның акчасызлыгы, театрларыбызның, гомумән, интеллигенциянең, бигрәк тә иҗат интеллигенциясенең матди хәле... Кыскасы, чын йөрәктән әйтсәк, мөстәкыйльлекнең тәэсирен сизү азрак. Ләкин, ни генә булмасын, Татарстанның мөстәкыйльлеге турындагы Декларация, Татарстан белән Русия арасындагы Шартнамә халкыбызда рухи күтәренкелек, өмет-ышаныч тудырды, күп мөмкинлекләр ачты, дип уйлыйм. Искә генә төшерик: әле күптәнме без мәктәпләребез бетеп бара, телебез бетеп бара дип зарлана идек. Соңгы елларда күпме татар мәктәпләре, гимназияләре ачылды! Бу мәсьәләдә мин әле театрга кагылышлы гына, бер генә мисал китереп узарга телим. Элек Казандагы театр училищесының татар бүлегенә авыл балалары гына килә иде. Ә менә быел, беренче тапкыр дип әйтимме, училищега үз телләрендә чиста-матур сөйләшә алган шәһәр укучылары күпләп килгән.**

**ӘДИП ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ**

# Башта ул миңа ошамады

Театр сәнгате драматургиядән башлана. Без, режиссерлар, драматургның идеясенә, әсәренә кан өстибез, артистлар аркылы җан өрәбез.

Мин иҗат юлымда Туфан Миңнуллин кебек драматургны очратуым белән үземне бәхетле саныйм. 1956 елны татар сәнгате декадасы алдыннан мин аны беренче тапкыр Мәскәүдә күрдем. Алар Щепкин исемендәге театр студиясенә керергә имтихан бирәләр иде. Башта ул миңа бер дә ошамады. Дорфарак тавышлы, күзлек астыннан сөзеп карый, усал күренә. Бу егеттән нинди артист чыгар икән дип шикләнеп тә куйган идем. Шуннан аралаша башладык. Укуларны бетереп Казанга кайткач, мин Островскийның «Котырган акчалар» дигән пьесасын сәхнәләштердем. Туфан анда кечкенә генә бер роль, хезмәтче ролен уйнады. Алар төркеменең язмышы катлаулы булып чыкты: эшли дә башламастан, бусы сәләтле, бусы сәләтсез дип мөһер суга башладылар. Хәтта Дунаев, Шәрәфиев кебекләрдән дә берни чыкмый, болардан котылырга кирәк, дигән сүзләр йөрде. Әлбәттә, бу ашыгыч бәя бирү иде. Кемнәрдер театрдан китәргә мәҗбүр булды. Шулар арасында Туфан да бар иде. Артист буларак, ул ачыла алмый калды.

Бервакыт «Миләүшәнең туган көне» спектаклен районга алып чыккач, артистларыбыз авырып китте дә, Туфан белән миңа сәхнәдә бергә уйнарга туры килде...

Туфан Миңнуллинда крәстиян психологиясе бик көчле. Ул җиргә нык басып тора. Авылны шәп белә, чын күңеленнән ярата. Күп нәрсәләрдә ул акыллы авыл кешесе логикасы белән фикер йөртә. Мин моны яхшы мәгънәдә әйтәм.

Иҗат юлымда миңа иң күбе өч драматургның әсәрен — Нәкый Исәнбәт, Кәрим Тинчурин һәм Туфан Миңнуллин әсәрләрен куярга туры килде.

Туфан сәхнә характерын тоя, мавыктыргыч тамаша итеп бирүдә бик көчле. Искиткеч стилист, һәр язган пьесасы — әдәби әсәр. Характерларны тормыштан таба, гүя җирдән көрәк белән актарып чыгара... Туфанның бер кимчелеге — ул сәхнәдәге хәрәкәтне бигүк кабул итеп бетерми, аңа хикмәтле сүз, ситуация кирәк. Бу мәсьәләдә безнең бәхәсләр дә чыккалый иде. Ике дистә ел эчендә мин аның 14 пьесасын сәхнәләштердем. Без бер юнәлештә эшли алдык.

Туфан тоталитар чорда да яраклашмады, йөрәгендәген язды. Бөтенләй көтелмәгән темага әсәр язып ул мине шаккатыра да куя. Әмма нинди генә тема алса да, анда Туфанның үз фәлсәфәсе була.

Әгәр без бүген театр сәнгатеннән Туфан Миңнуллин исемен алып ташласак (аны яратмый торган кешеләр дә бар), репертуарыбыз никадәр ярлыланыр иде!

Туфан Миңнуллин — шаушулы кеше, әмма табигате белән бик нечкә, оялчан, чиста күңелле. Мин аның алдагы көндә дә гел уйламаган яңа әсәрләр язып безне шаккатырачагына ышанам.

**Марсель СӘЛИМҖАНОВ,**
Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының баш режиссеры,
СССРның халык артисты,
Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе.

# Яңа ачышлар насыйп әйләсен

Әгәр «Әлдермештән Әлмәндәр»дән башка әсәр язмаган булса да, Туфан Миңнуллин хаклы рәвештә татар драматургиясе классигы саналыр иде. Чөнки бу әсәрдә тирән фәлсәфи мәгънә бар. Театр өчен, сәхнә өчен иң кирәкле сыйфат — нәкъ менә шул фәлсәфи мәгънә.

«Әлдермештән Әлмәндәр»дә Туфан тормышның чын мәгънәсен ача. Әсәрдә артистларның да офыклары киң, алар үз образларында шулкадәр мавыгып, онытылып яшиләр ки, аларга ышанмый мөмкин түгел. Әлмәндәр (Ш.Биктимеров) һәм Газраил (Р.Шәрәфи) — капма-каршы образлар. Әмма артистларның һәркайсы тормышның фәлсәфи мәгънәсен ачып бирә.

Туфан Миңнуллин бер-берсенә охшамаган, бер-берсен кабатламаган күп драма әсәрләре язды. Ул үз әсәрләрендә тормышның әле моңа кадәр ачылмаган якларын ачты. Драматургның уңышы, иҗатының хикмәте дә шунда.

Теләгем: Туфан иҗади эзләнүләрен кыю дәвам итсен, яңадан-яңа тормышчан әсәрләр язсын, сәламәт булсын. Уңышлар телим. Ихлас күңелдән котлыйм.

**Ширияздан САРЫМСАКОВ,**
Татарстанның һәм РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе,
Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе, профессор.

# «Җирдән аерылудан

(Ахыры. Башы 5 нче биттә).

язганда, хыял гына булган бу теләгемнең чынга ашуына ихластан сөенәм. Бик кирәк иде анда тәҗрибәле, абруйлы, чын-чынлап халык вәкиле булган депутат сүзе.

— Туфан абый, соңгы сессиядә бик «кайнар» күрендегез...

— Җаным-бәгърем, Мәскәү съездында сүз әйтер әмәл тапканны, монда әйтәм дә әйтәм инде. Авыз йомып, тел яшереп телсез кала яздык. Телен йоткан депутатларны күрдек. Анысы, файдасы булмасын сизенсәм, мин дә буш тегермәнгә су коймам. Ишекне япканчы, әйтеп калу хәерле.

Туфан абыйның куш йөрәклелеге, кыюлыгы кайчагында куркыта да. Йодрык белән түгел, сүз җегәре белән көчле ул.

— 37 нче елларда Сез, мөгаен, репрессия ятьмәсеннән котыла алмас идегез?

— Милләтнең иркә җаны булмадым микән мин? Уемны куенда йөртмәдем. Беркайчан да. Ул елларда да Алла саклаган булыр иде әле.

«Җаны ваклыгын заманга сылтап» яшәмәгән әдип. Бу кадәресенә язганнары дәлил. Театр, тамашачы — шаһит. Югыйсә, пьесалары тулы «крамола». 60 нчы еллар башында әйт әле син: «Юләрләр йортыннан качып булмый. Чөнки дөнья — юләрләр йорты. Син үзең дә миллион пациентларның берсе», — дип. («Дөнья» дигәнен ил дип укы). «Страна дураков» дигән канатлы сүзләр безнең телгә ике-өч ел элек кенә керде бит әле. Ә ул әнә җәмгыятькә диагнозны кайчан куйган! Йә булмаса, бүгенге «яңалык». Ил, Ватан йөз чөергән, кирәксезгә калган кешеләр турындагысы. «Илнең миндә эше юк. Кем күбрәк кычкыра, кем күбрәк лыгырдый — шул батыр!» — ди Әхтәм. («Ир-егетләр»). Туфан Миңнуллинга «диссидент» ярлыгы тагар өчен яраклы пьесалары байтак. Мәшһүр «Дуслар җыелган җирдә» кыйссасы гына да ни тора! Әнә шул — тротил зарядлы пьесаларны куюдан өрекмәгәнгә күрә дә илдәге Яңарыш (дөресрәге, Тетрәнеш) чорына татар театры, төгәлрәге, Г.Камал исемендәге академия театры сәхнәсе, митинглар барган мәйданнардан кайнарлыкта калышмыйча, хәтта ки барометры дөресрәк килеш килеп керде. Театрга, заманга яраклашкан булып, үзгәрәсе, фикерләр бәрелешендә фаҗигаләр кичерәсе булмады. Тамашачысыныкы белән синхрон рәвештә типте театрның йөрәге.

— Халык белән бер сулышта булуның сере бик гади аның, — ди драматург үзе. — Кайгырганда ни җырлый да, шатланганда ни җырлый халык — шуны гына бел.

— Шуны белгән өчен язылган иде бугай бит инде Сезнең өстән Үзәк Комитетка шикаять?

— Диас Вәлиевкә мөнәсәбәтле тарихтыр инде бу. Әйе, ул мине «милләтче, фашист» дип атаган иде шикаятендә. 1987 ел иде бугай. Мине өлкә комитетына чакыртып, «тәрбияләп» тә йөрделәр әле. Ләкин мине үзгәртү кыен. Кирәк икән, мин үзем үзгәрәм.

Ягъни «мин үземә бер дәүләт: ул дәүләтнең премьер-министры да, короле дә мин үзем. Корольгә йомышларын үтәр өчен, аңа баш ияр өчен кол кирәк. Ул кол да мин үзем. Кирәк икән, король булып, ул колны җәзалыйм». («Ир-егетләр»). Мин бу фәлсәфәне үземчә, Туфан Миңнуллинның яшәү рәвешенә нисбәтән сүтәм. Ул, тормышының патшасы буларак, үзен казна эшеннән 33 яшендә азат иткән һәм иҗат дигән газап белән җәзалаган. Колы татыган иҗат газабының татлы җимешләрен патша җыйный. Әллә киресенчәме? Мондый сәерлекләр тагын да бар. Шәһәр кешесеме ул Туфан Миңнуллин, авылныкымы? Аның кулында каләм яшьтәшрәкме, әллә балтамы? Батыр кешеме ул, әллә куркакмы?

— Шәһәрләрне җенем сөйми. Бигрәк тә Мәскәүне яратмыйм. Югыйсә, шунда җиде ел укып йөрдем. Ике ел депутат булып килеп сардым. Авылныкы инде мин. XIX гасырда тусам да, мулла түгел, крәстиян булыр идем. Бу гасыр башында тусам, кулак диярләр иде мине. Туфан абыегыз беркайчан да ач калачак кеше түгел. Кирәк — балта, кирәк — көрәк тотып эшли беләм. Физик эштән тәм табам. Башлаган эшемне төгәлләп туктыйм.

Ата-анаңның исеме олы йөргән авылдашлар арасында һаман авыл баласы булып яшәү ни бәхет! Һәр күзәнәге тоя аның шушы халәтне. Кояш белән бергә уянып, бакчага — чияләр, алмагачлар янына чыгу. Бер тын шул хозурлыкны күзләү, йөрәк аша сөзү-саркыту. Аннары, иелеп, соңгы яңгырдан соң симергән әрсез алабутаны йолкып алу... Шуннан башлана инде ул мең мәшәкатьле, әмма ләззәтле вә дә тыныч, ипле көннәр. Ә көннәрдән беркөнне Туфан абыйның җиргә яртылаш батырылган көрәге кулыннан төшә. Тукта! Казанда әллә ниләр булып беткәндер. Аннан башка гына тормыш кайныйдыр. Урап киләсе булыр!

Авылдашлары белән кич утырулар тәэсиреннән шактый тулышкан «Кызыл тышлы дәфтәр»ен дә кыстырып юлга чыга әдип — машинадамы, Идел өсләтепме. Гомер елгасында Җирдән аерылмаганы кебек, су өстендә дә ярларның якын булганын хуп күрә ул. Туфан Миңнуллинның самолетка утырмавын мәзәк итеп сөйләүчеләр бар.

— Җирдән аерылудан куркам мин. Антей кебек, Җирдән көч алам. Җиргә ятып ял итәм, шунда йоклап та китәм. Мәзәк итеп сөйлиселәре килсә, мин курка торган нәрсәләр тагын да бар әле. Хатын-кызның күз яшеннән куркам — коелам да төшәм. Миннән сугышчы чыкмас иде. Минем мәйдан — сүз көрәше. Гомердә дә үземне кул белән яклаганым булмады. Көч куллану миндә нәфрәт уята. Оныгым Даниярны каратэга йөртәләр — мин каршы.

Куркаклыкның миңа гаҗәеп ошый торган чагылышы бу. Гайрәтнең йодрыкта түгел, йөрәктә тупланганы. Югыйсә, метр да җитмеш буе белән дә ике метрлы күренә белгән, кулына балта тотып дүрт

ӘДИП ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

# Тылсымлы иҗат, тылсымлы зат

Казаннан Уфага хәбәр килеп төште: танылган драматургыбыз Туфан Миңнуллинга алтмыш яшь тулган бит! Татарстанның гына түгел, Башкортстан тамашачыларының да мәхәббәтен яулаган атаклы драматург булып каршылый Туфан Миңнуллин үзенең алтмышын. Республикабызның нинди генә театрында бармый аның ифрат үзенчәлекле, тирән мәгънәле әсәрләре! Башкорт академия драма театрында куелган «Үзебез сайлаган язмыш», «Ай булмаса, йолдыз бар», «Дуслар җыелган җирдә», «Чәршәмбе-чәршәмбе», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Хушыгыз!» һәм башка драмалары белән ул Башкортстан сәхнәсенә шул тиклем табигый кереп китте, хәзер инде театрыбыз дөньясын Туфан Миңнуллиннан башка күз алдына китерүе дә мөмкин түгел.

Әйе, зур драматургны котлыйбыз без зур бәйрәме белән. Пьесалары татар йөрәген дә, башкорт йөрәген дә бердәй тетрәткән таза куллы, саф ниятле драматургны тәбриклибез. Ирексездән, шундый сорау туа: Туфан Миңнуллин драматургиясенең шундый уңыш казануының сере нидә соң? Театр белгечләренә бирелә торган бу сорауга җавап бирүе җиңел түгел. «Талант» сүзе белән генә котылып булмый монда. Чөнки талант — ул үзе сер.

Күптән түгел миңа шагыйрь Әсхәл Әхмәткуҗа белән сөйләшеп утырырга туры килде. Ул үзенең пьесасын укып сөендерде. Мин аның теленең халыкчанлыгына соклануымны белдергәч, ул үтә тыйнаклылык белән генә әйтеп куйды: «Пьеса язарга өйрәнәм генә әле мин. Менә Туфан Миңнуллинда ул халыкчанлык!» — диде.

Туфан Миңнуллинны мин шагыйрь итеп тә беләм. «Кайда соң шигырьләре?» дип сорарсыз. Әлбәттә, аерым китабы (шигырьләр китабы) юк аның. Әмма пьесаларындагы нечкә зәвык, зур осталык белән язылган җырларын рәхәтләнеп шигырь итеп тә укырлык. Әйтик, кайсы шагыйрьнең нинди әсәреннән ким «Хушыгыз!» пьесасындагы җыр текстлары?

Җитәр инде,
тургай, моңайма,
Минем моңлы чагым
болай да.
Моңаймасаң килеп
каршыма,
Урын беткәнмени
тугайда?

Бер мәлне, телефон аша сөйләшкәндә, Туфанны чираттагы премьерасы белән котладым да, өстәп әйтеп куйдым: «Кара аны, не возгордись!». Ул көлде дә шунда ук: «Безнең бөтен бөеклегебез кеше булып калуда түгелме соң?» — диде. Әйе, иң авыр кайгыларны, иң зур шатлыкларны, баш әйләндергеч уңышларны кичергәндә дә кеше булып кала алуы җиңел түгелдер. Кешенең кешелеге шундый мәлләрдә сыналадыр. Иншалла, Туфан зур-зур дәрәҗәләр, бүләкләр алды, әмма һәр очракта да кеше булып, эчкерсез дуслыкка тугры булып кала белде.

Пушкинның бер шигырендә шундый юллар бар:

Я понять тебя хочу,
Смысла я в тебе ищу.

Туфан Миңнуллиннан бүген мәгънә эзләп торасы түгел, ул аның күпкырлы, тылсымлы иҗатында. Бүген ул минем күз алдыма әдәбиятның, сәнгатьнең олы мәгънәсен иңнәренә салып, тормыш дәрьясы аша чыгып барган азамат ир булып килеп баса. Агым көчле, дәрья киң, ярлар әле ерак. Хәтәр дулкыннар, аямыйча, китереп-китереп суга. Ул чайкалып куя, әмма егылмый. Һәм без — дуслары бүген әйтәбез:

— Афәрин, Туфан! Ары табан да шулай бар! Шулай барганда гына язучы чын зур максатка ирешә ала, дибез!..

**Рафаэль САФИН,**
**башкорт шагыйре.**

● Туфан Миңнуллин татар зыялылары белән очрашу вакытында.

**● Алексей КОЛЕСНИК,**

Татарстанның халык депутаты,
Татарстан Республикасы Дәүләт Советының
даими комиссиясе рәисе:

**— Татарстанның бәйсезлек турындагы Декларациясе җөмһүриятебез тормышының барлык өлкәләренә дә уңай йогынты ясады дисәм, һич ялгыш булмас. Татарстанда дәүләт милкен хосусыйлаштыру процессы да шактый уңышлы бара. Шуның өстенә, милли бәйсезлеккә ирешү республикабыз халкына Татарстанның үз инвестиция чикларын өләшү хокукы да бирде. Ә русияленләргә мондый бәхет тәтемәде. Бүгенге көндә күп кенә милли хәрәкәт җитәкчеләре Россия Федерациясе белән Татарстан арасындагы мәгълүм Килешүгә кул куеп, без бәйсезлеккә богау салдык дип әйтергә яраталар. Мин моның белән һич тә килешә алмыйм. Әгәр без бу Килешүне тулысы белән тормышка ашыра алсак, оттырудан бигрәк отачакбыз гына. Торгынлык елларында Татарстан хөкүмәтенең чит илләр белән икътисади килешүләр төзү хокукы юк иде. Хәзер безнең мондый хокукыбыз бар. Татар телен урыс теле кебек үк дәүләт теле дип игълан итүнең дә уңай яклары сизелә. Хәзер урамда да, трамвай-троллейбусларда да татар теле бик еш яңгырый. Тора-бара фәнни учреждениеләрдә, югары уку йортларында һәм җитештерүдә дә шулай булыр, дип уйлыйм. Моның өчен вакыт кына кирәк. Иң мөһиме — без җөмһүриятебездә сәяси һәм икътисади тотрыклылыкны саклап кала алдык. Татарстан кебек күпмилләтле дәүләт өчен бу үзе генә дә гаять зур казаныш инде. Ә башка кайбер республикаларда һаман кан коела.**

**● Разия ИБӘТУЛЛИНА,**

КОМЗ заводының оптика
цехы эшчесе:

**— Дөньядагы яшәеш сүз һәм эштән тора. Гади хезмәт кешесенә икенчесе насыйп. Әйе, бүгенге көндә адәм баласына эшле булу да зур бәхет санала. Мәсәлән, мин үзем егерме өч елдан бирле заводта эшлим. Анда эшкә керү һәм хезмәт итү зур горурлык иде. Йә, Ходаем, заводның гөрләп торган, иң алдынгы предприятие булган чаклары да бар иде.**

**Бүген заводның хәле аяныч. Берничә дистә ел шушы заводка бил бөккән кешеләр, тәҗрибәле кадрлар эшсез калды. Дөрес, безнең цех эшли, тьфу-тьфу, күз тимәсен. Без ясый торган җиһазлар бик кирәкле, аңа сорау, ихтыяҗ бар.**

**Заводның җитештерүчәнлеге кимү кешеләрне эшсез генә калдырмыйча, аларның рухи байлыгына да кул салды. Завод үз көче, үз кадрлары белән төзегән мәдәният йортыннан баш тартты. Хәзер ул шәһәр башкарма комитеты карамагына күчте. Мин үзем оптимист кеше. Җырлап җибәрсәм, барлык дөнья мәшәкатьләре онытылып китә һәм киләчәккә якты, матур өметләр баглыйм, балаларым кеше хокуклары тулы якланган һәм саклаган бәхетле Татарстан җирендә яшәячәкләренә ышанам.**

# куркам мин»

йорт җиткергән ирнең куркуына кем ышансын!?

Әмма ул курка! Оныклары өчен куркуына шаһит булганым бар. Чана тарткан ике оныгы белән урам кичкәннәрен күрдем берчакны. Тын урам Туфан бабайларының хәвефле, тәшвишле, бимазалы ыгы-зыгысы белән тулган иде. Юл кагыйдәсен үтәми оныклары. Әйткәнемчә, урам тын, буш. Ләкин бабай бит белә: шау-шулы урамнар бар. Оныкларын тын урамда ул шул усал урамнардан сакларга тырыша.

Киләчәк, милләт юлындагы «урамнар» куркытканга күрә Туфан абый гимназиягә барып, балаларның татар телен ничек өйрәнүләре белән кызыксына. Алай гына да түгел, үз оныкларын узындыру җәһәтеннән үтә сак кеше татар баласын кызыксындыруның төрле хәйлә-юлларын эзли. Әйтик, телне иң яхшы белгән бала Туфан Миңнуллин бүләге белән бүләкләнә. «Аңа гына акчаны бәрәңге сатып та юнәтәм», — дип дәртләнеп йөрде ул бер-ике ел. Тик быел боеккан әле. Хикмәт балаларда түгел икән. Гимназиягә килеп йөрүен (югыйсә, үзе СССР халык депутаты чагында артыннан юллап ачтырган гимназия бит), мәшәкать өстенә мәшәкать— эти белән әни килде әле, дигән мәзәктәгечә кабул итүче укытучылар язучының дәртен суыткан.

Яшь буын белән уртак тел табу кыен түгел аңа. Яшь язучылар белән бер казанда кайнавы — «Идел» журналындагы иҗади активлыгын әйтүем, — тайга ияргән ат азгыны булып түгел, бәлки көтү башлыгы булып алдан йөрүе, алай гына да түгел, яшьләр басмасы игълан иткән һәр бәйгедә кызыл башлы сөлгене эләктерә торуы бер могҗиза бит!

— Азарт бар миндә. Комарлы уеннар яратам. Кәртне акчага уйнасам, хатынымны оттырганчы уйнар кеше мин. Шуңа күрә уйнамыйм. Бервакытны шахмат белән мавыктым. Радиода җыелып уйный идек. Урамнан кайтканда кешеләр күземә шахмат фигуралары булып күренә, кайсын ферзь, кайсын пешка итеп күңелдән уйнап кайта идем. Халыкара гроссмейстер Крогиус белән ничьяга уйнаган абзаң булыр бу. Югыйсә, уйный белмим, үҗәтлек көчле. Иҗат бәйгеләренә җиңәм дип керешмим. Тукта, язып карыйм әле, дим. Драматург прозада ни майтарыр икән, дим. Уеннан уймак килеп чыга тагы. Мин, гомумән, үземне сынарга, белмәгәнне белергә, күрмәгәнне күрергә яратам. Яшь чакта чегән кызы белән дә танышып карадым. Фахишә кызга да сүз катканым булды. Күп нәрсәнең төбенә төшәргә тырышу гадәтем соңыннан характерларны өйрәнү өчен ярады.

Беренче тәҗрибәсен малай алты яшендә ясап карый. «Бабай тәмәкесен кабызды да шырпыны, мин ни сорасам да, яшереп куйды, ул йокыга ятуга, шырпыны эләктердем дә лапас артына чыгып саламга ут төртеп тә җибәрдем. Өч минуттан күрше-күлән ду килеп янгын сүндерде. Кечерәк масштаблы шуклыклар да булгалады. Әни суга киткәч, каз йомыркаларыннан берәм-берәм бәбкә чыгарып караган идем, азагы бәрәңге бакчасы буйлап әни белән куышу белән тәгәлләнде».

— Хәзер исә тыючы юк. Әйтик, наркотик татып карау теләге туса...

— Акыл бар хәзер. Үземне йөгәнли беләм. Ләкин дөнья белән кызыксынмаган кеше язучы була алмый. Анатоль Франсның «Пингвиннар атавы» дигән әсәрендә бер пингвин итәк киеп йөри. «Нәрсә бар икән?» дип калганнары аны эзәрлекли. Мин дә шул пингвиннар кебек инде. Ләкин мин шәхесем формалашкан кеше.

— Менә әле генә Сезнең телдә сүгенү сүзенә бәрабәр сүз яңгырады — шәхес. «Шәхес түгел!» — дисез Сез үзегез ихтирам итмәгән кеше турында. Сез нинди эчтәлек саласыз бу төшенчәгә?

— Шәхесне иң элек нәселдән килә торган сыйфатлар билгели. Морзалар нәселен гәүдә тотышыннан танымыйм. Коллардан шәхес тумый. Әни бездән менә ничек шәхес ясады: «Елап кайтма! Теләнмә! Еламыйча сора!» Шәхесне бетерү — иң олы җәза. Шәхес түгел, дигәндә, принципларсыз кешене күздә тотам. Тамак хакына үрмәләргә әзер кеше дә шәхес түгел.

— 30 елдан артык сәхнә тотканнан соң кинәттән Сезгә көндәш булырлык драматург калкып чыкса, Сезнең аңа мөнәсәбәтегез?

— Үземнән талантлы драматургны яратмыйм, әмма талантсызын күрә алмыйм.

— Кешеләрдән бәхет хакында сорау гадәти хәл. Бәхет — аңлаешлы халәт. Ә менә бәхетсезлек күпйөзле...

— Хатын-кыз мәхәббәтеннән мәхрүм ир — бәхетсез. Исән килеш кешеләргә кирәкмәгән кеше — бәхетсез. Мин үзем — каләмемнән аерылсам — бәхетсез.

— Иң зур дәва?

— Оныкларым. «Кызыл тышлы дәфтәр» тагын. Шул дәфтәргә түгеләм дә исән калам.

* * *

Бу көннәрдә Кама Тамагы районы авылларында язучы, драматург, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинга 60 яшь тулуга багышланган иҗат атналыгы бара. Татар театрының 90 еллык тарихына 30 елдан артык исеме үрелгән олы шәхеснең бәйрәме, театр коллективының бәйрәме генә түгел, бөтен татар халкының бәйрәме. Туфан Миңнуллин иҗаты белән безнең һәркайсыбыз тормышына дистәләгән бәйрәм китергән кеше. Безнең соры көннәр чылбырында аның пьесалары буенча куелган спектакльләр премьераларының җылы учаклары бар.

Туфан Миңнуллин өчен 60 яшь җиләктән кайтышлый юл читенә утырып ял итү генә әле ул. Гомернең әле тук чикләвекле, тук башаклы көзләре — алда. Саллы көлтәләрдән куеласы зуратлар да ерактан — Татар иленең һәр тарафыннан күренер. Ул әле дә күренә. Туфан абыебыз гына Шүрәлегә әйләнә күрмәсен. Юбилеена өлгерткән өр-яңа әсәрендә шулай ди бит: «Шүрәлеләр алар — кешеләрдән туеп урманга качкан язучылар», — ди. Бездән туйма, Туфан абый, халык үлмәс, син үлмәс!

● **Әмирхан ЕНИКИ,**
Татарстанның халык язучысы,
Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе:
**— Декларация турында начар сүз әйтәсем килми — хәзергә әйтер яхшы сүзем дә юк.**

● **Рабит БАТУЛЛА,**
язучы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г.Исхакый исемендәге бүләк иясе:
— !?.

● **Шамил НИГЪМӘТУЛЛИН,**
рәссам-монументалист, Татарстан Рәссамнар берлеге рәисе урынбасары:
**Мөстәкыйльлекнең иң мөһим казанышы дип, мин халкыбыздагы рухи яңарышны атар идем. Безнең үз гимныбыз, флагыбыз, гербыбыз бар. Конституциябез бар. Якын һәм ерак чит илләр арасында абруебыз күтәрелде, спортчыларыбыз еш кына Татарстан флагы астында чыгыш ясый. Безне ерак-ерак илләр таный, безнең белән кызыксыналар, безнең белән эшлекле килешүләр төзиләр.**

**Ә бит элек хәлләр бөтенләй үзгә иде.**

**60 нчы еллар ахыры идеме икән, Габдулла абый Шамуков белән Бауман урамыннан барабыз. Кышкы салкын көн, аяк астында кар шыгырдый. Алдыбызда өр-яңа кибет, «Русский чай» дигән вывеска чекрәеп тора. Габдулла абый шунда бик ачынып: «Бар да урысныкы, кар да урысныкы! Тиздән үз җиребездә кардан йөрергә дә рөхсәт сорарбыз инде...» — дигән иде. Шөкер, андый заманалар узды. Республикада яшәүче халыклар бер-берсенең телләрен, гореф-гадәтләрен, мәдәниятен, сәнгатен ихтирам итешеп яши. Милләтара мөнәсәбәтләр сүздә генә түгел, гамәлдә дә яхшыра.**
**Рәссамнарга килгәндә, хәзер алар ирекле, идеология тукмагы баш өстендә тормый. Иҗат иреге безнең әсәрләрдә, бигрәк тә халкыбызның фаҗигале тарихын сурәтләгән әсәрләрдә чагыла. Шулай да рәссамнар мөстәкыйль республикадан күбрәк нәрсәләр көтә. Остаханәләр өчен түләү үзгәрмәде, рәсемнәрне сатып алу мөмкинлеге чикле, бюджеттан өлеш аз килә. Рәссамнарга чит илләрдә булу, үзләренең әсәрләрен таныту кирәк. Рәссамнар берлеге каршында тышкы мөнәсәбәтләр оешмасы бар. Аның эшчәнлеге нәтиҗәсендә яшь рәссамнар Төркиядә, Голландиядә шәхси күргәзмәләрен оештырды, тагын Париж, Словения тамашачылары безнең әсәрләр белән танышыр, дип ышанабыз.**

● **Анатолий ЛУППОВ,**
композитор, Татарстанның һәм РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе:
**— Сәясәтчеләр өчен бу вакыйга аеруча мөһимдер, әмма сәнгать әһелләре өчен дә ул шундый ук зур бәйгә лаек, чөнки хәзер әсәрләрнең темасын сайлау, тарихи күренешләрне хакыйкать кушканча яктырту мөмкинлеге, элекке еллар белән чагыштырганда, күпкә иркенәйде.**

**Моның шулай икәнен мин үз иҗатымда да тоям. Без хәзерге көндә композитор М.Шәмсетдинова белән бергәләп (Р.Мостафин либреттосы) «Сөембикә» балетын тәгәлләп киләбез. Уйлап карыйк, элек бу темага сәхнә әсәре язу мөмкинлеге бар идеме? Юк иде, әлбәттә.**

**Узган ел музыка сөючеләргә мин үземнең «Коръән укыгач» («По прочтении Корана») дигән 6 нчы симфониямне тәкъдим иткән идем, яратып кабул иттеләр. Мондый темага әсәр язуны элекке чорда күз алдына китерү дә кыен иде! Язган очракта да партиянең җитәкче органнары әсәреңне башкаруны тыярлар иде.**

**Милләтем белән урыс булсам да, мин бөтен җаным-тәнем белән татарның халык һәм профессиональ музыкасына гашыйк һәм соңгы елларда шушы өлкәләрдә аеруча уңышлы эшлим.**

**Мөстәкыйльлеген көннән-көн ныгыта барган Татарстан халкы өчен илһамланып иҗат итү — үзе олы куаныч. Музыканы тирән аңлаган, яраткан Татарстан тыңлаучылары өчен — бигрәк тә!**

ӘДИП ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

# Әлмәндәр гомере телим

70 нче елларда Язучылар берлегендә «Тынгысыз каләм» исемле бик тә кызыклы дивар гәзите чыга иде. Мөхәррире Фаил Шәфигуллин аны чын мәгънәсендә әдәби-юмористик гәзиткә әйләндерде. Арттырып әйтмим, ул елларда язучылар өчен аннан да популяррак гәзит булмагандыр. Фаил, берничә эпиграмма язуымны үтенеп, миңа да мөрәҗәгать итте. Туфан Миңнуллинга багышланганы менә шундый иде:

«Ат карагы»н язганчыга кадәр,
Шагыйрь Туфан атын «урлаган».
Тик, Миңнуллин, бәгырем,
җан кисәгем,
Сине карак диеп хурламам».

Бу эпиграммага мин игътибар бирмәдем, аны язганны да күптән оныткан идем инде. Хәсән Туфанның үзе үлгәннән соң чыккан «Гүзәл гамь» китабында шушы дүртьюллыкны күргәч, аптырап калдым. Төзүчеләр ялгышып, моны Хәсән ага шигыре дип тәкъдим иткәннәр. Минем фаразымча, остазыбыз дивар гәзитеннән эпиграмманы укыган да, күчереп алган һәм шигырьләре арасына салып куйган. Димәк, Туфан энесенә һәм аның пьесаларына аеруча җылы караган шагыйрьне әлеге эпиграмма җәлеп иткән.
Туфан Миңнуллинга килгәндә исә, ул чыннан да шагыйрь Туфан атын урларга барырлык батыр егет булып чыкты. Чакырса, мин дә барыр идем, әлбәттә... Әле дә, алтмыш яшендә дә, ат кына түгел, кыз урларга барырлык егет әле ул.

Туфандагы драматург талантым булса, эпиграмма гына түгел, аның үзе турында бер искиткеч драма яки комедия язар идем мин. Каһарманы, Тинчуриннарга тиң олы таланты... Әмма үзе турында үзе язгандыр инде ул. Әлмәндәр аның үзе түгелдер, дип кем әйтә ала?!

Туфанның үз атын урларлык яшь талантлар үсеп килүенә дә сөеник. Хәзерге яшьләр инде ат урлап вакланмаслар, авылдагы тракторына да кагылмаслар, әдәбиятыбызны бәхетле иткән ат-исемен генә урларлар әле, дигән өметтә калыйк...

**Илдар ЮЗЕЕВ,**
Татарстанның халык шагыйре,
Г.Тукай исемендәге дәүләт бүләге иясе.

# Рәхмәт сиңа, энем

1964 елда Мәскәүдән, Щепкин исемендәге театр студиясен тәмамлап, театрга менә дигән кызлар һәм егетләр кайтты. Алар бар да чибәрләр, иң әһәмиятлесе — матур итеп татарча сөйләшәләр.

Шулар арасында кара бөдрә чәчле Туфан Миңнуллин да бар иде. Аның бергә укыган иптәшләре Ренат Таҗетдинов, Равил Шәрәфиев, Наил Дунаев, Нәҗибә Ихсанова, Гөлсем Исәнголова, Фирдәвес Әхтәмова, Әзһәр Шакиров һ.б.лар — үзара бик дуслар, бер-берсенә яхшы киңәшчеләр. Аларның күбесе авылда туып-үскән, җиргә, гади тормышка якын торган кешеләр.

Редакциядән миңа: «Туфан Миңнуллинга 60 яшь тула, берничә сүз язмассызмы?» — дип шалтыраткач, мин гаҗәпләнеп калдым.

Туфанга 60 яшь! Кара, гомер ничек тиз уза! Уйлана башлагач, миндә шундый фикер туды: «Туфан — яхшы кеше» дип кенә язып җибәрергә... Әйе, ул чын мәгънәсендә яхшы кеше. Сүземне дәлилләп шуны әйтәм: җирне, тормышны, халыкны сөйгән, акыл һәм намус иясе булган кешене башкача ничек дип атарга мөмкин соң?!

**Мин Туфан иҗатына тирән анализ ясарга җыенмыйм. Ләкин аның пьесалары бик тормышчан, андагы вакыйгалар тамашачыларны шундук үзенә җәлеп итә. Шунысы әһәмиятле, Туфан явыз кешеләрнең** образлары белән мавыкмый, аның каһарманнары кешелеклеләр, омтылышлары белән яшәү ямен тоеп, тирә-юньдәгеләргә гүзәллек теләүчеләр. Бу мәгънәдә аның «Әлмәндәр»е генә дә ни тора!

Санап карасам, миңа Туфанның биш әсәрендә уйнарга туры килгән икән. «Канкай улы Бәхтияр», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр», «Адәм баласына ял кирәк» һәм «Вөҗдан газабы».

Рәхмәт сиңа, Туфан! Укучылар гаҗәпләнмәсен, мин Туфанга «син» дип эндәшәм һәм, гомумән, күңелемә хуш килгән, якын иткән кешеләремә мин «син» дип эндәшергә яратам.

«Моңлы бер җыр»да үзем уйнаган Рәхимә образы, аның улы Муса белән сөйләшүе нинди җылы мәгънәле! Рәхимәнең Мусага туры карап: «Яхшы бул, матур яшә, илеңне, телеңне, моңыңны онытма. Үз моңын оныткан кеше башкалар моңын ишетми башлый. Моны мин сиңа әйтәм, ә син бүтәннәргә, алар — үзләреннән соң килгән буынга әйтсеннәр», дигән сүзләре — һәр ананың үз баласына васыять итеп әйтелә торган сүзләр...

Шулай, Туфан, сине олы бәйрәмең белән котлап, яңа уңышлар телим. Һаман да заманча, халыкчан образларга бай булган әсәрләр язып безне куандыр!

**Рәшидә ҖИҺАНШИНА,**
Татарстанның һәм РФнең халык артисткасы.

● **Туган туфракта «казыну».**

# Ул безнең авылга җан өрде

Ни кадәрле генә аяныч, кызганыч булмасын, һәр районда ташландык авыллар бар. Менә мин килен булып төшкән Олы Мәрәтхуҗа авылы да шундый аяныч язмышлы. Кайчандыр бу авылның да гөрләп торган чагы булган бит. Ләкин минем әйтәсе килгән сүзем бу хакта түгел. Киресенчә, авылны яңартү, торгызу, үлеп барган авылга тереклек суы сибүче кеше турында. Ул — авылдашыбыз, танылган драматург, әдип Туфан Миңнуллин. Мин аның язган әсәрләрен, куелган спектакльләрен мактарга җыенмыйм. Аны болай да бөтен кеше белә. Минем аның авылыбыз өчен изге булган эшләре турында әйтеп үтәсем килә. Һәркемгә дә туган авыл, туган як газиз, якын. Аны төзек, матур хәлдә күрәсе килә. Ләкин бу бар кешенең дә кулыннан килми. Бигрәк тә хәзерге кыйммәтчелек, базар мөнәсәбәтләре җайга салынмаган заманда. Менә шушындый авыр вакытта четерекле һәм кыен эшкә алынды безнең Туфан абыебыз.

Авылда зур эшләр башлап җибәрде ул. Төзү материаллары табуда булышты, берьюлы әллә ничә йортка нигез салынды. Читтә яшәүчеләр дә яңадан авылларына кайта башладылар, ташлап киткән нигезләрен яңарттылар. Яшь гаиләләрдә яңа йортлар җиткереп чыктылар. Без үзебез дә шундый йортларның берсендә яшибез. Үз хезмәтең, үз көчең белән салынса да, Туфан абыйның булышлыгы бик күп булды бу йортларны кору-җиткерүдә. Авылда яңа таш кибет тә аның ярдәме белән төзелде. Авыл уртасында, тау битендә айлы манарасы күккә ашкан мәчет балкып тора. Ул мәчет мәчет булганчы нинди сукмакларда йөреп, кемнәрнең генә ишеген шакымагандыр Туфан абый. Аларны үзе генә белә торгандыр.

Безнең авылда башкарасы эшләр бик күп әле. Су юк, балалар бакчасы кирәк, телефон кертәсе бар. Бәлки торa-бара колхоз хуҗаларының игътибары арта төшәр. Болары да булыр.

Ә хәзергә Туфан абыйга исәнлек-саулык, сәламәтлек, озын гомер, башлаган зур эшләрендә уңышлар телик. Олы юбилеен — 60 яшь тулу көннәрен бергә туган нигезендә уздырыйк. Аңа әле тагын яшәгән кадәрле гомерен яшәргә язсын. Алда эшләр бик күп бит әле.

**Рәмзия СӘЛИМОВА.**
Кама Тамагы районы,
Олы Мәрәтхуҗа авылы.

## Кызыл тышлы дәфтәр»дән яңа сәхифәләр

Туфан МИҢНУЛЛИН

# Мин

7 ноябрь көнне кунакка бардык. Бераз гына сыйланып алгач, ир-атлар акчага карта уйнарга утырдылар. Мин ул уенны уйнамыйм. Акчасын оттырудан курка, диләр минем турыда. Мин, бу сүз ачуымны чыгарса да, эндәшмим. Чөнки ул сүзнең астында мыскыл итү ята. Янәсе, мин - - саран.

Саранмы мин, юмартмы — анысын мине якыннан белүчеләр әйтерләр. Ә менә оттыру мәсьәләсенә килгәндә, чыннан да мин куркам. Юк, акча оттырудан түгел, гомумән, оттырудан куркам. Куркам дигән сүз дөрес түгелдер, хурланам. Әйе, оттырудан хурланам. Карта уенында гына түгел, бүтән уеннарда да, әгәр мине отсалар, нишләргә белмим, җен ачуларым чыга. Үземне эт итеп сүгәм. Башым эшләми башлый. Реванш алырга теләп тагын уйныйм, тагын оттырам.

Димәк, мин табигатем белән уенчы түгел. Һәрбер уенда салкын акыллы булырга кирәк. Отылган очракта отылуның сәбәпләрен сабырлык һәм салкын кан белән анализларга кирәк. Миндә ул сыйфат юк. Шуңа күрә тормышта да мин уйнарга сәләтсез. Мавыгып китәм дә уеным чынга әйләнә. Оттырам да бәргәләнәм, газапланам, үз-үземне битәрлим. Нишләтәсең, холкым шундый. Шулай тәрбияләнгән. Күп вакыт мондый сыйфат миңа комачаулый. Шуннан оста файдаланучылар бар. Еш кына, хәрәмләшеп мине оталар да, юлларыннан алып ыргыталар. Чөнки бер оттыргач, мин тиз генә «айный» алмыйм.

Шуңа күрә мин уйнамаска тырышам. Уйнамаганда мин көчле. Башым да компьютер кебек эшләп тора, нәрсәнең нәрсә икәнен анализлый да алам. Андый чакта уен осталарының хәйлә-мәйләләре дә миңа билгеле. Уйнарга ярамый миңа. Уйнап бер тапкыр да отканым юк. Бер тәңкә отсам, йөз тәңкә оттырам. Шуңа күрә дә уйнамыйм, оттырасым килми.

1993.

# Парадокс

Кеше дип аталган хикмәтле җан иясенең мин аңлап бетермәгән тагын бер серле гадәте бар. Тормышның авырлыгыннан чыннан да авыр тормышта яшәүчеләр бик сирәк зарлана. Интегеп, кыйналып, очын-очка гына ялгап яшәүче ялгыз карчыклар яки акча җиткерә алмыйча көне-төне эшләгән күп балалы гаиләләрнең хуҗалары белән сөйләшкәндә, хәлләрен сорашканда: «Авыр булса нишлисең инде, түзәсең инде, Аллага шөкер әле, ишиебез бар, дөньялары гына тыныч булсын», - - дигән сүзләрен еш ишетәсең.

Ә менә авыз эче, бармак-беләзекләре алтын, гәүдәсе мех белән ефәккә уралган хатыннар ике сүзнең берендә ах-ух киләләр.

Авырулар да шулай. Үлем түшәгендә ятучы елмаерга азаплана, бармагына шырпы кергәне «үләм» дип кычкыра.

1994.

# Көтүчеләр һәм бозаулар

— Сине күреп сөйләшергә дә теләгән идем. Әле үзең очрадың. Элеккеге обком секретаре турында мәкаләңне укыган идем, син аңардан милли каһарман ясагансың. Ә ул милләт турында уйлап та караган кеше түгел иде.

Бу сүзләрне миңа танылган тәнкыйтьчебез, әдәбият галиме әйтте.

— - Минемчә, мәкаләдә каһарманлыкка ишарә юк, — дидем. — Мин бары тик талантлы татар баласының язмышы турында һәм миңа бер начарлык та эшләмәгән кеше хакында юбилее уңаеннан үз сүземне әйтергә теләдем, — дидем.

- - Ләкин мәкаләне укыгач, мәкалә герое татар халкының милли каһарманы булырлык шәхес дигән фикер туа, — диде галимебез.

Мин бәхәсләшмәдем.

— - Бәлки шулайдыр да, ләкин максатым ул түгел иде, — дидем.

— - Бүген, әлбәттә, элеккеге партия җитәкчеләрен сүгү модада. Ләкин мин шәхсән үземә начарлыклары тимәгәннәр хакында ямьсез сүз әйтә алмыйм.

- - Сиңа тимәсә, милләткә тиде. Гаяз Исхакыйны «враг номер один» дип атаучыны да күккә чөяр идеңме? Шул ук кеше суверенитетка да каршы чыкты бит. Син аның кем икәнен яхшы беләсең.

Иркенләп сөйләшергә вакыт тар булганлыктан, әңгәмәбез өзелде. Менә хәзер, үзем генә калгач, шул турыда уйланып утырам. Уйларым үткәннәргә китә. Үткән заманны хис аша гына түгел, акыл иләге аша да уздырырга тырышам. Уемда сорау артыннан сорау туа. Һәм алар, бергә җыелып, кемнәр гаепле, дигән бер сорау булып оеша. Шуңа җавап эзләргә тотынам. Эзләнә торгач, без барыбыз да — җитәкчеләр дә, җитәкләнүчеләр дә — система корбаннары дигән нәтиҗәгә киләм.

Әйе, партия хакимлек иткән системага үз җитәкчеләре кирәк иде, система аларны үзе тудырып, үзе тәрбияләп үстерде. Система җитәкләнүчеләрне дә үзе тәрбияләде — алар «бозаулар» булырга тиеш иде. Үзенә яраксыз булган җитәкчеләрне, ягъни көтүчеләрне һәм бозау булырга теләмәгән җитәкләнүчеләрне система үтерде яки лагерьларга озатты.

Бүген үткәннәргә ревизия ясаганда кылынган гөнаһлар өчен күбрәк җитәкчеләр гаепләнә. Ни әйтсәң дә, алар көтүчеләр, без «бозаулар» гына. Бозаудан ни таләп итмәк кирәк?

Шуңа күрәдер, элеккеге обком секретарьлары һәм бүтән партноменклатураның без бүген тәүбәгә килүен таләп итәбез, хөкем каршына бастырырга телибез. Ә алар үзләрен гаепле санамыйлар. Безне көтүче итеп куйганнарына без гаепле түгел, көтүчелек вазифасын без намус белән үтәдек, диләр. Аларның сүзендә хаклык бар. Кушылганны эшләмәсәләр, аларны да безнең ише «бозаулар» көтүенә кушарлар иде дә, алар урынына бүтән көтүчеләр табарлар иде.

Димәк, үткәндәге гөнаһлар өчен гаеплеләр юк? Димәк, бөтенебез дә тәтиләр?

Һич юк. Һич кенә дә алай дип әйтергә теләмим. Киресенчә, без барыбыз да гаеплеләр. Бозау булып яшәргә риза булучылар да, кушылганны намус белән үтәгән көтүчеләр дә. Кол булырга теләүчеләр барында колбиләүчеләр һәрвакыт булачак. Гап-гади хакыйкать. Нигә кемнәрнедер сүккән булып азапланырга?

Без мәсьәләне тарайтып, үзебезнең милли көтүчеләребезгә бәйләнәбез, аларны гаеплибез. Бәлки шулайдыр да, үзенә якынрак торган көтүчедән ешрак эләгә инде ул. Шуңа аның гаебе дә күбрәк күренә. Хезмәт хакы ала алмаган өчен мескен колхозчы мескен колхоз рәисен сүгә, мескен рәис бичара район хакимияте башлыгына нәләт укый (үзенә әйтмичә генә), бичара башлыктан аптырашта калган өстәге иптәшкә эләгә (үзенә ишеттермичә генә), өстәге иптәш үзеннән югарыда утыручының тетмәсен тетә (үзенә сиздермичә генә). Ә югарыда утыручы ни теләсә, шуны кылана. Чөнки ул «бердәнбер һәм бүленмәс» Рәсәйнең халкын бик яхшы белә. Ничәмә-ничә гасырлар буе бозау булырга күнеккән халык ул. Димәк, Рәсәй - - борын-борыннан бозаулар һәм көтүчеләр системасына корылган дәүләт. Власть алышынып тору да бу илгә үзгәреш кертә алмый. Коммунист дип аталамы ул, демократ дипме, барысы да бер системага буйсына. Көтүчеләр генә алмашына, бозаулар шул ук. Бозау яки сарык булырга теләмәүчеләрне бу илдә императорлар да, патшалар да, генераль секретарьлар да үтерә бардылар. Президент та нәкъ шулай. Әнә чеченнар белән ни эшлиләр.

Шундый хәлләр. Язмыштан узмыш юк, ахрысы, безгә. Шулай да мин үзем дөньясына кул селтәп бозау булып яшәргә риза булу ягында түгел. Ярамый! Система ничек кенә кысмасын, күңелебездәге хөрлек, азатлык чаткыларын сүндерергә ярамый. Безнең җаныбыз ничаклы азат булса, безне бозау итәргә теләүчеләр шул чаклы азрак булачак. Милли җитәкчеләр дә өскә генә түгел, аска да карарга мәҗбүр булачак. Горур халыкның җитәкчеләре дә горур була. Алар инде кемнәргәдер ярарга тырышып үзләренең Гаяз Исхакыйларын «враг номер один», димиләр. Әгәр дә кемдер минем белән килешмичә, үзебезнең элеккеге һәм хәзерге җитәкчеләрне талку ягында икән, һәм мине дә шуңа инандырырга тырыша икән, бу очракта да артык аяусыз булмаска кирәктер. Мин үзем, мәсәлән, теге яки бу җитәкченең ярамаган эшен күрсәм, гаепне аны урап алган яраннарыннан эзлим. Дөньяны бутаучылар — куштаннар. Шул ук обком секретарьларын яңадан искә төшерик. Кемнәр иде алар? Әлбәттә, талантлы кешеләр. Ләкин тирән белемнәре юк иде. Бигрәк тә гуманитар фәннәр өлкәсендә надан иделәр. Гаяз Исхакыйның бер юлын да укымаган обком секретаре аның «враг номер один» икәнен каян белсен. Филология, философия, тарих фәннәре докторлары «враг» дигәч, ул ни әйтсен?

(Дәвамы 10,11 нче битләрдә).

## «Кызыл тышлы дәфтәр»дән яңа сәхифәләр

**Юк, мин түрәләрне күккә чөеп, алардан каһарман ясарга җыенмыйм. Әмма бар гаепне аларга гына да аударып калдырасым килми. Әйткәнемчә, без барыбыз да система корбаннары.**

**Ә ничек корбан булмаска? Анысына инде җавапны аерым-аерым уйлап та эзлик, бергәләп тә уйлашыйк.**

**29 июнь, 1995 ел.**

# Люция ханым монологы

— Мин болай уйлыйм, Туфан Абдуллович. Кияүгә чыгасың икән, чын иргә чыгарга кирәк. Мужик дип авыз тутырып әйтерлек булсын. Шулай бит, Туфан Абдуллович?

Кайбер хатыннар әйтә, ирем табак-савыт юарга булышмый, кер юарга булышмый, ди. Мин андый түгел. Кер юган ир белән тормыйм да мин. Мин юарлык кере дә булмагач, ир була димени ул. Ник торыйм мин андый ир белән. Шулай бит, Туфан Абдуллович?

Бервакыт, яшьрәк чакта, мин дә әйттем мужигыма, өлгерә алмыйм, булышмыйсың да, дидем. Чынлап әйттем, дөресен әйттем. Балабыз туган чак иде, бөтенесенә ничек өлгерәсең. Булышырга тотынды мужигым. Бала чүпрәкләрен юарга тотынды. Карап торам моның кыланышын. Ходаем!.. Әллә ничек булып китте. Мужигым хатын-кыз булып күренә башлады бит күземә. Кич белән янына ята алмый азапландым. Кочакламакчы булган иде, чирканып читкә тайпылдым. Көчкә ияләштем. Керләр янына якын барма, кухняга ашарга пешкәч кенә кер, дидем.

Кайчакларда ашыгам, Туфан Абдуллович, табак-савыт юарга да вакыт калмый. Өеп калдырам табак-савытны, кайткач юам, аны якын китермим. Үз эшеңне эшлә, син — мужик, дим. Шулай бит, Туфан Абдуллович.

Мужиқымның кулына мин сиктки, сумка тоттырып базарга чыгармыйм. Ситкы ул ирләр өчен чыгарылмаган. Күтәрә икән, дурт потлы капчык күтәрсен. Өч бәрәңге салынган ситкы селкетеп йөрмәсен. Кибеткә барып чират та тормасын. Җыен карчык-корчык арасында. Карчыклар белән бергә чиратта торган ир вакчыл була ул. Шулай бит, Туфан Абдуллович?

Вакчыл ирләрне җенем сөйми. Синең пудыр алган акчаңны да санап торган мужик мужикмыни ул?

Ирем усал дигән хатыннарга карап та аптырыйм. Юаш ир бозау ич ул. Усал да булсын ул мужик. Явыз гына булмасын. Ирең кайтып кергәндә аны сагынып әзрәк кенә куркып та тормагач, нәрсә инде. Мужигың синнән куркып торса, ничек аның янына ятмак кирәк? Шулай бит, Туфан Абдуллович?

Тыңлыйм мин, әйеме, хатыннар: — өлгерә алмыйбыз, диләр. Ирләребез өйдә булышмый, диләр. Берәүсе әйтә, ирем гел диванда гәҗит укып ята, ди. Ятсын. Гәҗит тә укымагач, ирмени ул. Нәрсә, мин гәҗит укып ятып, ул ашарга пешерсенмени? Гәҗитне бит аны ирләр өчен чыгаралар. Өлгерә алмыйм, имеш. Йөгерербрәк йөр өлгерә алмасаң. Кияүгә чыкма өлгерә алмасаң. Үзеңне генә тәрбияләп, ялгыз яшә өлгерә алмасаң. Шулай бит, Туфан Абдуллович.

**8 июль, 1995 ел.**

# Нәсел

**Уйланып ятканда әнинең әлкән абыйсы — Яшь бабай искә төште. Әнинең мин белгән өч туганы арасында Яшь бабай күңелгә ныграк кереп урнашкан. Тегеяки бу уңай белән мин аны еш искә төшерәм. Күрәсең, безнең холкыбызда нинди дә уртаклык бар.**

Горур иде ул. Үз кадерен үзе белүче кеше иде. Ләкин беркайчан да тәкәббер булмады. Авылда гына түгел, тирә-як авылларда да исеме билгеле кеше иде.

**Нәсел дигән сүзне еш искә ала иде Яшь бабай. Туганнарыбыз арасыннан берәвебез ярамаган эш эшләсә, нәселдә булмаганны кыланды бит, дип әзгәләнә иде. Хәтерлим, аның улы Хәсән абый, автомашинасы белән капланып, хөкемгә тартылгач, нәселебездә төрмәгә утырган кеше юк иде, дип әллә ничә ел онытмады.**

Исемдә, үземә дә бер тапкыр әләкте аңардан. Ни өчен икәнен әйтмим инде. Якадан әләктереп алды да: «Кем нәселеннән икәнеңне оныттыңмы әллә, маңка, тапкансың эчеп йөрергә причин», — дип яңакка бик шәпләп сылады. Айнып киттем.

Үләр алдыннан, җәй көне генә үлсәм ярар иде, дип еш кабатлый иде. «Туфан да машина белән кайтыр иде җирләргә, Мөнир дә, Хәсән дә. Зират янында әллә ничә люгковой машина тезелеп торыр иде. Юлдан үтүчеләр, кемне шулай бик зурлап күмәләр, дип туктап карап торырлар иде. Гатаны күмәләр ич, аларның нәселе шундый ич, ни җитте генә нәсел түгел, дип әйтерләр иде сораган кешегә», — дия иде.

Хәер, бер Яшь бабай гына түгел, әни дә, бүтән туганнар да горурланалар иде нәсел белән. Гомумән, нәсел белән горурлану татар халкына хас сыйфат инде ул. Хәзер бу сыйфат әкренләп югала бара бугай. Нәселен белмәүчеләр арттканнан-арта бара. Кем баласы икәнен белмәүчеләр һәм белергә дә теләмәүчеләр дөнья тулы. Шуңа күрә дә дөньяның рәте китте. Чөнки нәсел белән горурлану үз-үзеңне тәрбияләүнең иң камил формасыдыр ул. Үзеңне һәрвакыт яхшы, уңган, тәртипле, итагатьле нәселдәшләреӊ белән чагыштырып, аларга охшарга, аларның йөзләренә кызыллык китермәскә тырышасың.

Нәселен белмәгән кешегә диңгез тубыктан бит аңа. Оялтучы кеше юк. Нәселнең данын саткан өчен яңаклаучы да юк — теләсәң нишләп йөр урам эте шикелле.

Әйе, «Урам этләре» күбәйгән саен дөньясы да эт оясына охшап бара. Татар икәнен кычкырып әйтергә оялган бәндәләргә карыйм да имәнеп китәм. Ходаем, үзең сакла, дим.

Гадәттә, яманаты чыккан нәселнең токымы гына үз нәселен яшерүчән була. Әллә соң без татарлар тарихта яманатыбыз чыгарлык эш кылдыкмы? Үзара талашып дәүләтебезне саклый алмаганыбыз өчен беребездән-беребез оялабызмы? Без татар түгел дигән булып, кем алдындадыр акланырга телибезме? Күңелемә шундый ямьсез уйлар килгән өчен бер Ходаем кичерә күрсен. Чөнки минем татар булганым белән үзем дә горурланасым, бүтәннәрнең дә горурлангның ишетәсем-күрәсем килә. Чөнки минем нәселем — горурланырлык нәсел. Татар нәселе. Яшь бабайлар нәселе.

**13 июль, 1995 ел.**

# Кыйбла кайсы якта

Былтыргы уку елы башлангач, яныма бишенче сыйныфлар өчен чыгарылган урыс әдәбияты дәреслеген тотып оныгым килде:

— Менә, бабай, быел без нәрсә укыячакбыз, — дип дәреслектәге «Библия для детей» дигән бүлекне күрсәтте.

Укып чыктым. Йа, Хода! Чиркәү школалары өчен чыгарылган дәреслектән күчереп алынган бүлек ич. 1896 елда Санкт-Петербург побы Соколов төзегән дәреслек. Һәм шуны мөселман традицияләрендә тәрбияләнүче оныгыма укытачаклар. Мәҗбүр итеп укытачаклар.

Оныгым укый торган мәктәп — урыс мәктәбе. Ләкин анда бер сыйныф татар балаларыннан гына тора. Татар телен тирәннәнрәк укыту өчен махсус оештырылган сыйныф. Оныгым шунда укый.

Мин, әлбәттә, мәктәпкә чаптым. Җае туры килде — бишенче сыйныфта укучыларның ата-аналары җыелган көн иде. Утыздан артык татар кешесе.

Бик озак итеп акча турында сөйләштеләр. Тегенең өчен акча түләргә кирәк икән, монысына акча җитми икән. Ата-аналар фәлән кадәр акча җыярга тиешләр икән.

Бу сөйләшүне котым очып тыңлап утырдым. Хәерче хәленә калган лабаса мәктәпләребез. Куркыныч нәрсә — белем алу, уку һәм укыту, тәрбия турында сөйләшәсе урынга без кесәләребезне капшап барлы-юклы акчабызны мәктәпкә бирергә мәҗбүрбез. Кая китә без түләгән салымнар? Кемнәрне ашатырга китә? Кемнәрне үтерергә китә?

Акча санап таралышырга җыенганда дәреслектәге «Библия...» турында сүз кузгаттым.

— Бу эшкә ничек карыйсыз? — дидем.

Һәм шунда гаҗәеп бер күренеш булып алды. Ата-аналар томана сарыкка караган сыман миңа карап тордылар. Мин янә аңлатырга тырыштым. Ниһаять, сүзнең ни турында барганын аңладылар да мине тәрбияләргә тотындылар. Әлбәттә инде, татар хатыннары (ир-атлар юк иде диярлек) урысча сөйләп тәрбияләделәр мине.

— Библия очень умная книга, она учит только хорошему, — диделәр.

— Библия — акыллы китап, әмма акыллы китаплар арасында ул бер генә түгел. Минем өчен Коръән иң акыллысы, дидем. Гомумән, дөньяда акыллы китаплар бик күп, барысын берьюлы 10 яшьлек балаларга мәҗбүри укытырга ярамый. Аларның аңы андый китапларны дөрес аңлап үзләштерергә әзер түгел, — дидем.

Тыңлаучы, колак салучы булмады. Татар хатыннары миңа Фәүзия Бәйрәмовага караган сыман чырайларын сытып карадылар да урысча сөйләшә-сөйләшә таралыштылар.

## «КЫЗЫЛ ТЫШЛЫ ДӘФТӘР»ДӘН ЯҢА СӘХИФӘЛӘР

Миңа бик авыр булды ул көнне. Юк, мин әлеге ата-аналарны гаепләмәдем. Алар — яшьләр. Аларны үстергән-тәрбияләгәннәрне кызгандым мин. Ягъни үземнең тиңдәшләремне. Теленнән, дененнән биздереп тәрбияләгән икәнбез ләбаса балаларыбызны. Кыйблаларын югалтканнар икән ич балаларыбыз. Димәк, безне аңгыра, томана итеп калыпка утыртканнар икән.

Әкренләп тынычландым. Утыз-кырык татар ул әле бөтен милләт түгел, ашыгыч нәтиҗә ясарга ярамас, дидем дә Татарстан Республикасының Халык мәгарифе министрлыгына киттем. Алар, янәсе, ничек карыйлар икән бу мәсьәләгә.

Күп еллар дәвамында ата-аналар теләге дип алдашып, Мәскәү кушуын төгәл үтәп, татар мәктәпләрен япкан министрлык бит инде ул. Билгеле, бүген элеккеге министрлар икенче төрлерәк сөйлиләр. Ата-ана теләге димиләр, Мәскәүне гаеплиләр. Татар мәктәпләрен саклап калырга тырыштык, диләр. Сүзем юк, тырышканнардыр. Ләкин көрәшмәделәр. Мин, мәсәлән, бер генә министрның да мәктәпләрне урыслаштыру сәясәте белән килешмичә отставкага киткәнен хәтерләмим.

Бүген бүтән заман, дибез. Суверен республика, дибез. Үз сүзебезне дә әйтә алабыз, дибез. Мәгариф министрлыгы ничек икән? Үз сүзе бар микән? Уку-укыту буенча мөстәкыйль милли сәясәте бар микән?

Аллага шөкер, бар икән. Библияне мәктәптә татар балаларына укыту килешеп үк бетми торган нәрсә икәнен беләләр икән. Ләкин белгәннәрен тормышка ашырырга өч тиенлек тә көчләре юк булып чыкты. Чара күрербез, дип мине ышандырсалар да, берни эшләмәделәр. Укыттылар татар балаларына «Библия для детей»ны.

Уку елы тәмамлангач, оныгым тагын әйтә:

— Бабай, җәйге ял вакытында «Библия для детей» дигән китапны укып килергә куштылар, — ди.

Димәк, дәреслектәге бүлек кенә аз, китапның үзен үк укырга кирәк икән.

Министр урынбасарына шалтыраттым. Чара күрербез, дигән булды. Карап карарбыз инде, күрерләрме чара.

Югыйсә, чара күреп торасы юк. Конституцияне (Россиянекен һәм үзебезнекен) төгәл генә үтәргә кирәк. Анда акка кара белән дин дәүләттән аерылган, диелгән. Мәскәү үзе кабул иткән Конституцияне чабата олтырагына әйләндереп бетерде инде. Бу очракта да дәүләт, мәктәпләрендә дин сабагы укытып, миссионерлык белән шөгыльләнә. Канашевич, Ильминскийлар чукындыра алмаган татарны иманыннан яздыру — бүгенге Мәскәүнең дә сәясәте ул.

Ә без ни карыйбыз, министр әфәнделәр? Әллә без дә «Библия»нең иң акыллы китап икәнлегенә ышана башладыкмы?

Шушы урында туктап алып, мин христиан динен тотучыларга бер-ике сүз әйтергә тиешмен. Алар дөрес аңласыннар, мин һич кенә дә Библияне хурларга җыенмыйм. Аллам сакласын. Христианнарның изге китабына тел тидерү мөселманнар өчен дә гөнаһ. Әмма минем өчен изге китап — Коръән-Кәрим. Мин үземне мөселман традицияләрендә тәрбияләнгән, хак мөселман дип саныйм, һәм үз баламның, һәм оныкларымның да шул традицияне дәвам иттерүләрен телим. Ләкин, шуңа карамастан, Ислам диненә өндәү христиан диненә өндәү кебек үк дәүләт мәктәпләрендә барырга тиеш түгел дип саныйм. Аның өчен чиркәү бар, мәчет бар. Чөнки дин тоту һәркемнең вөҗдан эше. Аны ирексезләп бәрәүгә дә тагарга ярамый. Дәүләт мәктәпләрендә исә программага кергән фәннәр мәҗбүри өйрәтелә. Моны министрлыкта беләләрдер, шәт. Ә мәктәпләрдә белмәгән өчен дә, белгәненңне эшләмәгән өчен дә «икеле» куялар.

Инде Библияне иң акыллы китап диючe мөселман һәм атеист татар хатыннарына берничә сүз. Алар Библия укытуны өстәмә белем бирү дип кенә уйлап ялгышалар. Әгәр аерым-аерым сорасаң, берсе дә христиан динен тотарга ризалык бирмәс иде, балаларының да чукынуын теләмәс иде. Югыйсә, балаларын татар сыйныфына бирмәгән булырлар иде.

Шуңа күрә мин аларга үзем шаһит булган бер гыйбрәтле вакыйганы сөйлим.

Күптән түгел генә туганнарымның бакчасында йөргәндә туфрак өеп куелган һәм шуның өстенә агач тәре утыртылган бер урынга тап булдык. Ни-нәрсә икән бу, дип аптырап калдык. Туганымның хатыныннан сораштык.

— Малай, үлгән тавык чебиен күмәбез, дип йөри иде, әллә шул микән? — ди.

Шул булып чыкты. Казандагы урыс мәктәбендә бишенче сыйныфны тәмамлаган уникe яшьлек татар малае чебине җирләгән дә, бик матур иттереп килештереп тәре ясап, чеби каберенә кадап куйган. Әти-әниләре ах иттеләр.

Менә сиңа акыллы китап укыган баланың кылган эше.

Ата-ана, Ватан, кыйбласын бутаган адәми затларның фаҗигале һәм куркыныч бәндәгә әверелгәнен акыллы кешеләр гасырлар буе әйтеп торалар. Шуны истән чыгармаска иде. Аны белмәүчеләргә министрлыкларда халык язмышын хәл итеп утыручылар аңлатсын иде.

Кыйбла дигәннән, Татарстан радиосы җитәкчеләренә дә сүзем бар.

Күпләр ишетә, һәр пәнҗешәмбе көн радионың беренче программасы аша иртәнге сәгать тугызда кришна дип аталган дин тармагын пропагандалыйлар.

Әйтик, Библияне пропагандалаганда республикада христиан динен тотучылар күп дип әйтсеннәр, ди. Ә кришна нәрсә? Кем өчен, ни өчен өндиләр ул дингә дәүләт радиосы аша?

Бу хакта радио җитәкчеләренә әйтеп карадым. Әйе, алар да ярамаган эш эшләгәннәрен аңлыйлар. Мәскәүгә сылтыйлар. Янәсе, ул — Мәскәү тапшыруы. Аклануның иң җиңел юлы. Мәскәүгә төртеп күрсәтәләр дә — вәссәлам.

Ә Мәскәү нишли? Мәскәү ул үз эшен бик белеп эшли. Мәскәүгә кешенең кыйбласын бутарга кирәк. Кыйбласы буталган сарык көтүе белән идарә итүе җиңел бит.

Безгә буталырга ярамый. Болай да инде шактый буталганбыз.

**28 июль, 1995 ел.**

● **Туфан Миңнуллин әсәре буенча куелган «Әбиләр һәм бәбиләр» спектакленнән бер күренеш.**

## ӘДИП ТУРЫНДА ЗАМАНДАШЛАРЫ

# Эшләпә

Минем «Чаян» журналында эшләп яткан чак. Килгән хатларны укыйм, бастырырлык әсәрләр сайлыйм. Соңыннан, искә төшереп сөйләшкәнгәме, башка хатларга охшамагангамы, берсен бик яхшы хәтерлим.

*«Абзыйлар!*

*Мәскәүдә бер татар студентының ачтан үлүен теләмәсәгез, «Эшләпә» исемле шигыремне бастырып чыгара күрегез.*

*Туфан Миңнуллин».*

Шигыренә караганда студентның сүзләре күбрәк ошаганга күрә, шигырьне журналда бастырып, Мәскәүгә гонорарын җибәрдем. Төшеп кала торганнардан түгел егетем, әнә бит тормышка ничек ябышып ята, хәйләкәр алдыра, дип уйлап та куйдым.

Тиздән Туфан үзе дә килеп чыкты. Ишекне киң ачып, кулын сузып, елмаепмы елмаеп керә, аннары нык итеп кулны кыса, хәл-әхвәлләр сораша — әйтерсең лә мин аның белән йөз ел таныш...

— «Чаян» ярдәме белән менә исән-сау калдым әле, шул шатлыктан тагын ике шигырь китердем, чыпчык борыны хәтле генә шигырьләр... Берсе «Гадел куян», икенчесе — «Изге Ибраһим» дип атала. «Эшләпә»дән артык җирләре юк югын, алай да китереп карадым әле.

Тагын уйлап куйдым: югалмас бу егет, кара син кешегә ничек ошарга тырыша. Елмаюы, үз итеп шаяртуы белән сихерли алуын белә, хәйләкәр...

Аның бу шигырьләре дә журналда басылды. Шул очрашудан соң күп еллар үтте. Без еш күрешә, әңгәмәләшә торган булдык. Туфан үзе дә «Чаян»да эшләп алды. Аннары драматургиягә күчте. Язганнарын башта миңа укыта иде. Без инде күптәнге дуслар. Өстәвенә хатыны Нәҗибә ханым минем күрше авыл кызы булып чыкты. Нәҗибә Туфанның үзеннән дә ихласрак, аннан да уздырып елмаюы белән барыбызның да мәхәббәтен казанып өлгерде.

Ә Туфан яңа язган пьесасын суза да: «Берара вакыт табып укып чыкмассыңмикән, үземә бик ошап бетми бетүен», — ди. Үзе студент чагындагы кебек ихлас елмая. Мин аның турында инде болай уйлыйм: хәйләсез, риясыз егет. Аның эчкерсез елмаюы да, шаянлыгы да — үз табигате, үз холкы. Туфан гомумән башкача була алмый.

**Альберт ЯХИН,**
филология фәннәре докторы.

# Өч тетрәнү

Моннан кырык ел элек без, Мәскәүгә барып, Луначарский исемендәге театр институтының башкорт студиясендә бер ел укыгач, Щепкин училищесына татар егетләре, кызлары килгәнлеген белдек. Җитмәсә, без яшәгән тулай торак аларныкына каршы гына булып чыкты. Мин читтән генә карап йөрим. Араларында Туфан исемле егет тә бар. Башкалардан әллә ни аерылып тормаган гади генә авыл егете. Безгә бик катнашып та китми иде ул. Мин үзем дә бик аралашырга яратучылардан түгел.

Еллар үтте. Язмыш һәркайсыбызны үз урынына куйды. Без, укып кайтып, Башкорт академия драма театрында эшли башладык. Ул вакытта без матбугат аша бер-беребезне күзәтеп бара идек. Гәзитләрдә чыккан мәкаләләрдә татар студиясен тәмамлап кайткан актерларның исемнәрен очратып шатланабыз, ә менә Туфанның исеме, нишләптер, күренми.

Көннәрнең берендә безнең труппага «Үзебез сайлаган язмыш» исемле пьеса тәкъдим иттеләр. Авторның бу пьесада фикер йөртүенең гадәти түгеллеге мине җәлеп итте. Темасы яңа да түгел кебек, әмма персонажлар язмышы белән хәл ителүе бик кызыклы тоелды. Авторы кем, дип кызыксынгач, Туфан Миңнуллин, диделәр. Мин шунда ук уйлап куйдым: «Кара әле, теге гади генә егет шундый пьеса язган!».

Драматургия бит ул катлаулы жанр. Теләсә нинди язучының теше үтми аңа. Ә Туфан язган! Ничек кенә язган әле! Сюжет борылышын, диалогларны шундый оста корган! Минем өчен бу бер ачыш булды. Мин шулай Миңнуллинны ачтым.

Туфан Миңнуллин белән минем үзара очрашып сөйләшкәнем булмады. Мин аны күбрәк пьесалары буенча беләм. Шулай бер елны Казанда командировкада чакта «Әлдермештән Әлмәндәр» спектаклен карап хәйран калдым. Туфанның зур әдип булуына инандым. Үзем артист бит инде, беләм моның спектакль икәнен дә. Шулай да башыннан азагына кадәр дөньямны онытып елап утырдым.

Әле бу гынамы! Камал театры Уфага гастрольгә килгәч, Туфан Миңнуллинның янә бер әсәрен — «Моңлы бер җыр» спектаклен карап, тетрәнеп утырдым. Тирән фәлсәфи спектакль. Нигезендә бүгенге проблемалар ята. Шул спектакльдән соң мин үз иҗатыма әйләнеп карадым. Туфанның иҗаты минем өчен үзе бер ориентирга әйләнде.

Өченче тапкыр тетрәнү кичерүем — «Хушыгыз!» спектаклен карагач булды. Бу әсәре белән Туфан үз тормышына, узган елларына йомгак ясаган кебек тоелды миңа. Ул мине тагын үз тормышыма борылып карарга мәҗбүр итте. Шуның өчен бик рәхмәтлемен мин Туфанга. Бәхеткә, шул спектакльдәге төп образны үземә дә уйнарга насыйп булды.

**Гөлли МӨБАРӘКОВА,**
СССРның халык артисткасы.
Уфа.

# Татарстан үрнәге дөньяга танылды

**Рафаэль ХӘКИМ,**
**Татарстан Президентының дәүләт киңәшчесе**

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Шул ук вакытта аларга актив реклама да бирелде. Ә безнең предприятиеләрнең күпчелеге банкротлык хәленә төште.

Шулай итеп, дөнья базары безнең йортка үтеп керде һәм «Россиянең бердәм икътисади пространствосын» үзенә интеграцияләде. Без исә аңа чыга алмадык. Хәер, моңа әллә ни омтылмадык та бит. Ник дигәндә, эчке ихтыяҗлар товарларның конкурентлыкка сәләтле булмавын компенсацияләр дип уйлый идек. Ә эчке базар явыз шаярып алды. Бүген үзебездә эшләнгән телевизорларны, көнкүреш техникасын, косметиканы һ.б. товарларны бик азлар гына сатып ала. Кайбер товарлар буенча (мәсәлән, автомобильләр) протекционистик чаралар кертелде. Әмма алар барыбер дә вакытлыча характерда һәм гомуми хәлне үзгәртә алмыйлар. Яңа парадигманың мәгънәсе бөтендөнья икътисади һәм мәдәни яссылыгына юнәлеш тотудан гыйбарәт.

Татарстан — дөньяның аерылгысыз бер өлеше һәм безнең миебез. Тормышчан икътисади һәм башка төрле мөнәсәбәтләр дөнья мәдәнияте таләпләренә туры килергә тиеш. Тимер пәрдә артында яшәгән чорда без СССР дип аталган ябык яссылыкта яшәдек һәм бөтен икътисад дәүләт планы тарафыннан югарыдан көйләнде. Базар мөнәсәбәтләренә күчү, тышкы сәүдәне һәм сәяси системаны либеральләштерү белән безнең җәмгыять ачык җәмгыятькә әверелә башлады. Мөнәсәбәтләр үзгәрде, ә фикер йөртү рәвеше элеккечә калды. Без һаман да үзебезне чорнап алган дөнья яссылыгын күрмәмешкә салышып, Татарстан һәм Россия базары күзлегеннән карап фикер йөртәбез. «Өлкә дәрәҗәсендә» фикер йөртүгә өстенлек бирелә һәм бу икътисади яктан көчсезләнә баруның сәбәбе булып тора. Республика дистәләрчә еллар нефть, химия промышлениостен үстерү турындагы лозунглар белән яшәде. Башта Татарстанны икенче Баку, аннары икенче Кувәйт дип атадылар. Бу мәсьәләләргә дөнья тенденцияләре күзлегеннән карыйк әле.

Беренчедән, нык үскән илләр нефть белән сәүдә итмиләр, алар катлаулы әйберләр, технологияләр, белемнәр белән сәүдә итәләр. Алар чимал ресурсларын сатып алалар һәм югары технологияле продукция саталар. Шул ук вакытта фән, мәгариф системасы үсеше өчен акча кызганмыйлар. Кешеләрнең квалификациясен күтәрү зыян китерми торган бердәнбер өлкә булып санала. Нефть илләре эшчеләрнең түбән хезмәт хакы, Кувәйтнең чәчәк атуы хисабына яшиләр. Элек аз үскән илләр рәтенә кергән Көньяк Корея, Тайвань, Сингапур илләренә күз салыйк. Бу илләрнең уңышка ирешүләренең сере нәрсәдә? Аларның бит чимал чыганаклары юк. Көньяк Корея 30 ел элек иң хәерче илләрдән санала иде. Моннан 15 ел элек бернәрсә дә җитештермәгән Сингапур бүген дөньядагы барча компьютерларны да үзенең дисководлары белән тәэмин итә. Барча илләрнең кибет киштәләрендә Тайвань продукциясе ята. Бу илләр артыннан ук дөнья аренасына Малайзия, Индонезия, Гонконг илләре чыкты. Аларның чәчәк атуына китергән берничә сәбәпне күрсәтеп узарга мөмкин. Әлеге илләр дөньядагы иң югары зәвыклы кулланучыларга юнәлеш тоттылар. Алар, производствоны бер йодрыкка туплап, катлаулы товарлар җитештерүгә күп көч куйдылар. Ниһаять, мәгарифкә һәм заманча технологияләрне сатып алуга да акчаларын кызганмадылар. Валютаны «Сникерслар» һәм «Баунти»ларга сарыф итмичә, аны эшмәкәрләрнең халыкара үзәкләрендә яшьләрне әзерләүгә, заманча технологияләргә лицензияләр сатып алуга сарыф иттеләр. Татарстан нәрсәгә исәп тотарга мөмкин? Продукциянең арзан булуынамы? Италиялеләрнекенә караганда яхшырак аяк киемнәре, «Азия тигрлары»на караганда заманчарак электроника әйберләре, немецларга караганда юньлерәк автомобильләр җитештерү бик авырга туры килер. Шуңа күрә дә бер генә юл кала — кытайлылар җитештерә алмый торган катлаулы продукция җитештерә башларга кирәк. Бу очракта алар Аурупадагыга караганда күпкә арзан булырга тиешләр. Мондый стратегиягә күчеш стратегиясе дип карарга кирәк һәм ул дөнья базарында үз урыныбызны тапканчыга һәм товарларыбыз конкурентлык итәргә сәләтле булганчыга кадәр дәвам итәргә тиеш. Нефть кебек чималга ия булу, аны эшкәртеп әзер продукция сыйфатында сатканда, безгә өстенлек бирергә мөмкин. Әйтик, без ул продукцияне «КамАЗ» машиналары өчен шин һәм башка әйберләр (әкиләчәктә Алабуга заводы автомобильләре өчен дә) рәвешендә җитештерә алабыз. Куәтле нефть-химия комплексы һәм Казандагы көчле фәнни химия мәктәбенә ия булу бу юнәлешне перспективалы һәм приоритетлы итә.

Татарстан икътисадындагы төрле тармакларның гомум «идеология» нигезендә үзара тыгыз бәйләнешен булдыру товарның конкурентлык сәләтен үстерү шарты булып тора. «КамАЗ»га һәм башка шундый эре машина төзү комплексларына заказларны Татарстан туфрагында булдыру максатка ярашлырак булыр кебек. Чөнки бердәм административ яссылыкта продукциянең конкурентлык сәләтен үстерү мәсьәләләре буенча консенсуска ирешү һәм сыйфатның бердәм стандартын булдыру җиңелрәк. Бу исә товарларны «Татарстанда эшләнде» дигән билге белән чыгарырга мөмкинлек бирер. Республика хөкүмәтенә, үз чиратында, Татарстанда эшләнә торган продукциянең конкурентлык сәләтен үстерү буенча чаралар булдыра башларга вакыт. Озак вакытка исәпләнгән стратегия күзлегеннән генә түгел, агымдагы бурычлар күзлегеннән караганда да бик мөһим мәсьәлә бу.

Эш хакын вакытында бирмәү гадәти халгә әверелгән Россия базарыннан аермалы буларак, экспорт продукциясенә акча түләнә, шуның өстенә экспорт белән шөгыльләнүче предприятиеләрдә үз вакытында бирелгән хезмәт хакы эчке базарның сатып алу мөмкинлеген арттыра һәм җирле җитештерүчеләр өчен өстәмә стимул булып тора. Республиканың конкурентлык сәләте үсү аны гомумдөнья стандартларына яраклашырга мәҗбүр итәчәк. Ни генә кылма, Көнбатыш менталитетына һәм Көнбатыш мәдәниятенә юнәлеш тотарга туры килер. Бу — милли традицияләрнең юкка чыгуына китермәсме? Бик урынлы сорау. Әлбәттә, акыллы уйланган һәм күпләр тарафыннан хупланган кайбер стандартларны кабул итәргә туры килер. Әмма Татарстан, максималь рәвештә тарихи традицияләрне һәм милли үзенчәлекләрне кулланган очракта гына, дөнья базарында үз урынын ала алачак. Дөньяда катлаулы продукция җитештерү буенча лидерлардан саналган предприятиеләр мәдәниятне унификацияләү хисабына түгел, киресенчә, аның кабатланмаслыгы һәм үзенчәлеклелеге хисабына беренчелекне саклыйлар.

Австриядә булганда мине бер нәрсә таң калдырды. Чагыштырмача кечкенә генә илдә милли генә түгел, төбәкләрдәге традицияләр дә саклана. Зальцбургта һәр тарафта Моцарт сулышы сизелә, аның белән олысы да, кечесе дә горурлана. Бар җирдә аның көйләрен уйныйлар, аның җырларын җырлыйлар, аның сувенирларын, портретларын саталар. Майка, шоколад кебек әйберләрдә дә аның портреты. Монда бөек исемне үзенчәлекле «эксплуатацияләү» бара, чөнки Зальцбург җире өчен аннан да яхшырак реклама була алмый. Чит ил кешеләре миннән еш кына: «Шаляпинның Казанда тууы дөресме? Аның йортын күрергә, сувенирлар сатып алырга буламы?» — дип сорыйлар. Һәркемнең фәкать Казанда булган нәрсәне истәлек итеп алып китәсе килә. Алар Казанда Лобачевский эшләгәнен, университетта Толстой укыганын, Шаляпинның Казанда җырлый башлаганын белгәч, Татарстанга ихтирам белән карый башлыйлар. Мөселман илләреннән килгән кунакларны үзенең демократик булуы белән үзенчәлекле «Җәдитлек» фәлсәфәсе сокландыра. Ә без, аларның республикабыз турында мөмкин кадәр күбрәк белергә теләүләрен канәгатьләндерәсе урында, «Адидас» майкалары һәм «Красная шапочка» кәнфитләрен генә тәкъдим итә алабыз. Әлегә без Татарстанның гомумдөнья ярышында өстенлек бирүче үзенчәлеген бәяли белмибез. Безнең өстенлегебез нефтьтә түгел, кешеләрдә. Алар һәм фәкать алар гына үзләрендә үзенчәлекле мәдәниятне, этник традицияләрне һәм әхлак нормаларын йөртәләр. «Татарстан моделе» турында уйланганда, ирексездән, бер принципиаль сорау килеп туа. Ярый, Татарстан икътисадны үстерүдә уңышка даирешсен, ди, әмма ул сум зонасында тора һәм Россия сәясәтенә бәйле. Ә аның иртәгә нәрсә эшләсен беркем дә әйтә алмый. Мондый аңлаешсыз хәлдә стратегия төзеп буламы соң? Чыннан да, Мәскәүдә тотрыклылык һәм кабул ителгән карарларда аныклык булмаганда, икътисад үсешен планлаштыруы бик авыр. Шуңа да карамастан, конкурентлык өстенлекләре барыбер дә төбәкләр дәрәҗәсендә булдырыла. Икътисади яктан алдынгы урында торган илдә артка калган провинция булырга мөмкин, әмма нәкъ шулай ук икътисади яктан зәгыйфь дәүләттә чәчәк атып килүче провинция дә булып калырга мөмкин. Моңа мисаллар җитәрлек. Нәрсә генә булмасын, Россиядәге гомум хәл үзеннән-үзе республикалар хәлендә чагылыш тапмый. Россиядә хәтта бер дигән икътисади сәясәт алып барылса да, ул Татарстан предприятиеләренә уңыш гарантияли алмый. Чөнки конкурентлык өстенлекләре төбәкләр дәрәҗәсендә булдырыла. Италиядә дә нәкъ шул хәл күзәтелә. Анда иң яхшы дизайнерлар илнең төньягында тупланган. Германиядә һәм Швейцариядә дә шулай. Мәсәлән, АКШның Айова штатында дөньядагы иң яхшы сортлы кукуруз үстерелә. Ул үзенә күрә бер кукуруз империясе булып тора. Кешеләрнең бөтен дәрманы һәм акыл көче бердәнбер культураны яхшыртуга юнәлдерелгән. Аның каравы, дөньядагы иң яхшы сортлы Айова кукурузын бөтен кыйтгаларга да озаталар. Бу АКШ түгел, ә конкрет штат ирешкән казаныш.

Татарстанның икътисади моделенең конкурентлык сәләте берничә фактор белән билгеләнәчәк: хөкүмәтнең катлаулы продукция җитештерү өчен шартлар тудыру буенча озак вакытка исәпләнгән стратегия булдыруы, фән һәм мәгарифне үстерү программасы, географик хәлне файдалану.

Икътисад чәчәк атсын өчен республика җитәкчелеге аңлаешлы сәясәт алып барырга бурычлы. Ул эшмәкәрләр тарафыннан һичбер икеләнмичә кабул ителергә һәм озак вакытка исәпләнгән проектларга таяныч булырга тиеш. Шул ук вакытта хөкүмәт республиканың кыска вакытлы өстенлекләренә (мәсәлән, нефтькә) түгел, озак вакытлы приоритетларга (машина төзү комплексы һ.б.) юнәлеш тотсын иде.

Хөкүмәтнең максаты, минем уйлавымча, конкурентлык сәләте буенча «идеология», базар турында гомумкүзаллаулар булдырудан, халыкны мөһим иҗтимагый максатлар тирәсенә туплаудан һәм экспортка озатылучы товарларны җитештерү өчен шартлар тудыруда дәүләт рычагын файдаланудан гыйбарәт булырга тиеш. 1995 елның гыйнвар ахырында Стенфорд университеты (Калифорния) чакыруы буенча мина конференциядә Россиянең федератив төзелеше турында чыгыш ясарга туры килгән иде. Стенфорд университеты — бик үзенчәлекле уку йорты, аерым алганда, барча компьютер техникасы яңалыклары эшләнгән «Силиконлы үзәк» бөтен дөньяга мәгълүм.

Интеграль схемалар, компьютерлар һәм математик тәэмин итүне булдыручы иң эре компанияләр дистәләрчә хезмәт күрсәтүче банклар һәм фирмалар белән бергә университет территориясендә урнашалар. Һәм болар барысы да университетның интеллектуаль хисабына булдырыла.

Күп кенә илләрдә «Силиконлы үзәк» үрнәге буенча фән һәм техниканың приоритетлы тармакларында әйдәп баруын тәэмин итүче технологияләр булдырылган. Кулга-кул тотынышып эшләгән фән һәм техника конкурентлык сәләтенең нигезе булып торалар. АКШта кешеләрнең университетлар хезмәткәрләренә карата ихтирамлы мөнәсәбәте сокландыра. Юкса, алар әллә ни күп хезмәт хакы ала торган хезмәткәрләр дә түгел бит. Минем Сан-Францискодагы татар общинасы вәкилләре белән очрашуым бик тәэсирле булды. Алар М.Шәймиев белән горурланулары турында сөйләделәр. Президентыбызның Гарвард университетында ясаган чыгышы махсус гомумамерика телеканаллары аша трансляцияләнде. Көнбатышта университетларның чыгыш ясау һәм уртак эш алып бару максатында чакырулары бик дәрәҗәле нәрсә дип санала. Һәм моның өчен нигез дә бар. Университетлар бөтен дөньяда дәүләт учреждениеләренә хезмәткәрләр сайлап алу (әйтик, Гарвард яисә Стенфорд профессоры дәүләт структураларындагы иң дәрәҗәле урыннарга исәп тотарга мөмкин) база булып торалар. Алар шулай ук икътисади һәм сәяси карарлар кабул итү, техник прогрессның яңа юнәлешләре эшләнмәләрен булдыру базасы да.

Мин безнең республикада университетларның һәм институтларның әһәмиятен аңлап җиткермиләрдер, дип уйламыйм. Көнбатышта фәнгә ихтирам белән карыйлар. Чөнки ул үзен-үзе аклый. Анда тормыш теоретик мәсләкләрнең кырыс тәнкыйтьчесе булып тора. Һәм практикларның өметләрен акламаган галим хезмәттәшлек итүне дәвам итүгә исәп тота алмый. Безнең фән һәм мәгариф системасы мондый прагматик юлдан ерак торалар һәм еш кына үз тормышлары белән яшиләр. Әмма монда гаепләләрне эзләп тору кирәк тә түгелдер. Төптән уйлаганда, бу безнең уртак фаҗигабез. Аннан котылу юлы берәү генә. Ул — дәүләтләрнең, предприятиеләрнең һәм фәнни учреждениеләрнең бергә-бергә эшләве. Географик фактор геосәяси хәлгә һәрвакыт үзенчәлек һәм аннан өстенлек алу мөмкинлеге кертә. Татарстан белән булган хәл мондый: төрле су, коры җир, тимер юллары һәм авиатрассалар чатлары. Без Идел-Урал төбәгенең үзәгендә торабыз һәм моннан максималь файдалана алырга кирәк.

Татарстан куәтле машина төзү комплексына, перспективалы фәнни базага, күп профильле мәгариф системасына, югары квалификацияле кадрларга һәм уңайлы географик хәлгә ия. Болар барысы да киләчәк уңышның нигезе булып торалар.

# УНӨЧЕНЧЕ БИТ




КӨлсәң — көл, көлмәсәң — ела!

## Тарихи д~~ә~~өреслек

Өйе, килде-керде, гадәтенчә кул биреп исәнләште. Бераз тынып торгач, туп-туры карап әйтте:

— Ну, энекәш, әйт син миңа, дөреслек кайда?

— Нинди дөреслек?! — дидем мин каушабрак. Авылдаш агаең да дөреслек эзләп килгәч, бөтте баш, бер-бер катмарлы хәлгә кереп китүчегеңне көт тә тор. Дөреслек эзләп килүчеләр болай да буа буарлык. Табып бетер син аларга дөреслекне! Тик агай үзе үк мине кыен хәлдән чыгарды:

— Тарихи дөреслек турында әйтүем, — диде ул, «тарихи» сүзенә басым ясап. — Йә, әйт син миңа, кайда ул тарихи дөреслек?!

Мин исә җиңел сулап куйдым. Тарих мәсьәләсендә мин инде шөп йөзәм. Тарихи дөреслекне, кирәк икән, табабыз аны! Агай бүгенге дөреслекне генә таптырмасын.

— Менә, сезнең гәзиттә укыдым, — диде агай, бармагын өскә күтәреп. — Берәү үз бабасының йорт-җирен сорап яза. Аны авылдан, кулак дип, законсыз куганнар, хәзер капитализм кире кайтты, бабайның җирен миңа кайтарыгыз, тарихи дөреслек булсын, ди. Расмы бу?

Агай сорауны каты куя, җавапсыз калмау йөзеннән, мин дә:

— Соң, ни инде, кирәктер инде, кем, агай, — дим.

— Вәт менә шул! — ди агай, урындыгын якынрак тарта төшеп. — Менә минем малай Әмерикәдә шпион булып эшли иде. Әмерикә белән дуслашып, бездә дә капитализм башлангач, минем малайга эш калмады. Балалары ач утыра, дөреслекме бу? Кайда тарихи дөреслек?! Пример, беләсең килсә, минем бик борынгы маймыл бабамның кулыннан икенче бер маймыл алты штук бананын тартып алган булган. Менә хәзер, бөтен Казаныгыз маймыл ризыгы белән тулгач, шуны миңа бүген акчага саталар. Ә шул алты банан орлыгыннан, саный китсәң, минем якынрак бабайлар күпме банан үстергән булыр иде?! Нигә бүген миңа бананны сатып бирәләр, нигә бушка бирмиләр? Кайтарсыннар минем бананны! Тарихи дөреслек кире кайтарылсын! Расмы сүзем?

— Соң, агай, әле ул бананның нәкъ менә синең ерак бабаңныкы икәнлеген, аны кем, ягъни кайсы маймыл кайчан тартып алганлыгын беләсе-исбатлыйсы бар бит, — минәйтәм. Үзем эчтән генә шүрлим: тәки маймыл хәленә калдыра бит авылдаш агай. Авылга кайтыр, әйтер: укытучы Әкмәлевнең гәзиттә эшләүче малаена дөреслек эзләп барган идем, ярдәм дә итмәде, дияр. Йә булмаса, юл капчыгыннан күренеп торган бананын өстәлемә ыргытыр да:

— Шул тарихи дөреслекне дә белмәгәч, нишләп йөрисең соң син язучы саналып? — дияр.

Юк, ул алай итмәде. Урыныннан әкрен генә кузгалды да, юл капчыгын иңенә асты:

— Ярар, авылдаш, мин китим әле, Камчаткага барып җитәсе бар, — диде.

— Камчаткага?! Әле юлың бик ерак икән, агай! — дидем мин, җиңел сулап. — Анда ни йомыш соң?

Агай, уфтанып, кул гына селтәде:

— Соң шул инде, тарихи дөреслекне эзләп йөреш, — диде. — Минем иң якын бабам тегермәнче булган бит. Бервакыт, хатынының, ягъни минем әбинең он иләгәнен карап-карап торган да, яңалык уйлап чыгарган: иләкне селкетеп кул ардырганчы, зур бер иләк ясарга да, җир тетри торган урынга илтеп куярга. Җир тетрәп тора, оны иләнә тора. Шушы яңалыгын ул Камчаткага язып җибәргән. Ә анда җир гел тетрәнә, димәк, он илиләр. Бабай бу ачышы өчен акчасын ала алмый калды, үлеп китте, мәрхүм. Менә, шуның акчасын юллап йөрешем. Тарихи дөреслекне кайтарырга теләп...

Авылдаш агай китте. Мин эш бүлмәмдә берүзем калдым. Башымда иләс-миләс уйлар, каршымда шикәрсез-нисез, сыек кына ясалган салкын чәй иде. «Тукта! — дигән уй көйдереп үтте минем башны. — Минем дә бабайлар булган ич! Аларның да кайчандыр, кайдадыр, ким дигәндә, берәр аты, йә булмаса берәр сыеры, һич югында кәҗәсе булган! Кайда тарихи дөреслек?! Кайда миңа дигән ат, кайда сыер?! Кайда ул миңа дигән кәҗә?!»

**Нияз АКМАЛ.**

**Гамил АФЗАЛ**

### Дөнья матур да...

Сөйләшәләр, киңәшәләр
Җитәкчеләр төркем-төркем,
Дан-дәрәҗә өләшәләр,
Эшләргә теләми беркем.
Демократия киңәйгән,
Дөнья матур, дөнья иркен...

### Туктаган сәгать

Ил көч җыя, үрләр яулый сәнгать,
Шомлы таң аттыра.
Ленин үлгәч туктап калган сәгать
Һаман туктап тора.

### Талантлы халык

Шат мәзәкче сөйли көлә-көлә,
Зирәк акылларга сокланып:
— Электр утын да урлый белә,
Әй, талантлы инде бу халык!




## Кыз урлау гадәте кайда сакланган?

Татарстан Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте хәбәрләренә күз салсак, андый гадәт беркайда да сакланмаган. Киресенчә, авыл хуҗалыгы продуктларын урлау күбәеп бара. Әйтик, урып-җыю эшләре башланганнан бирле мондый урлашуда 887 кеше тотылган, 47 тонна яңа ашлык, 37 тонна терлек азыгы, 10 тонна яшелчә хуҗалыкларга кире кайтарылган. Әлеге хокук бозулар өчен 402 кеше җинаять җаваплылыгына, 485 кеше административ җаваплылыкка тартылган. 261 җинаять эше кузгатылган.

* * *

Хәер, кыз урлау дигәннән. Кызларны аларны, урласалар да, берәмтекләп кенә урлыйлар иде. Ә менә бодайны-бәрәңгене капчыклап-капчыклап ташыйлар, имеш. Татарстан хөкүмәтенең яңа уңышны республикадан читкә чыгаруны тыйган күрсәтмәсе булуга карамастан, бу «төшемле эш»кә атлыгып торучылар җитәрлек. Әйтик, Лаеш районының «Россия» совхозыннан һәм «Агропромхимия» ярдәмче хуҗалыгыннан Чувашстанга таба китеп барган 12 тонна печән тоткарланган. Зеленодол шәһәрендәге «Лина» берләшмәсе хезмәткәрләре «Овощевод» совхозыннан алынган 9000 килограмм бәрәңгене Пермь өлкәсенә озатмакчы булганнар. Кама Тамагы районының «Камско-Устьинский» коллектив предприятиесе исә 24744 литр дизель ягулыгын нәкъ шул ук Пермь өлкәсендә төзү материалларына алыштырган... Кыскасы, урлашабыз, җәмәгать!

Кыз урласаң ни була? Туй була! Ә менә ашлык урласаң... башыңда уй була. Авыр уй...

## Күлмәк белән туганнар бәхетлеме?

Юк, монда һич тә баш ватып торасы юк: һәркем үзенчә аңлар да, һәркем үзенчә гөман кылыр. Әйтик, бу — аз санлы халыкларның уртак эмблемасы, уртак туграсы түгел микән? Күп еллар дәвамында югалтулар кичергән кардәшләребез — Кырым татарлары, бу соңгы канкоешта гына да күпме ирләрне, балаларны җуйган чечен кардәшләр... Табигатебезнең чисталыгы турында борчылып уйланган галимнәр. Инде килеп, туган телнең ана карынында ук яралуы хакында уйлануларыбыз. Бәлки, бу безнең мөстәкыйльлегебез яралгысының бер билгеседер? Ни генә булмасын, «Мәдәни җомга» кием тегү осталарына әнә шундый рәсемле күлмәкләр тегәргә тәкъдим итә. Ә «күлмәк белән туган» бала бәхетле була, диләр...

## ПАР(О!)ДӨЯ

**Рәшит ЯКТАШ**

*Бетәрләнеп яткан җәнлек төсле*
*Йоклый урман куе тынлыкта.*
*Һич ышанмыйм урман ешлыгында*
*Биниһая тылсым юклыкка.*

***Госман САДӘ.***

**Сез, иптәшләр, юкны сөйләмәгез,**
**Ни әйтсәм дә — минем иркемдә:**
**Бу урманда гөмбә юклыгына**
**Ышандырмас мине беркем дә!**

**Шулай дим дә... Үзем як-ягыма**
**Карангалап куям юк-юкта.**
**Һич ышанмыйм урман ешлыгында**
**Үземдәй ач бүре юклыкка...**

# Гыйсъянчы

Солтан ШӘМСИ

(Ахыры. Башы 5 нче санда).

Чыннан да, бу юлы Сарай шәһәре Хаҗи Чиркәс хан кулына төшә. Чыганаклардан аның моңарчы Хаҗитархан хакиме булуы билгеле. Күренә ки, бу вакытта үзен Бату, Үзбәк ханнардан калган асыл тәхеткә лаеклы санаучылар җитәрлек булган. Шунысын да әйтергә кирәк, Хаҗи Чиркәс белән беррәттән Хәсән дигән берәү дә Мамай мирзага каршы көрәш башлый. Бу бәрелешләрдә Хәсән җиңеп чыга һәм тәхеткә утыра. Әйткәнебезчә, әлеге вакыйгаларны тарихчылар 1368 ел белән билгеләли.

Бу очракта Хәсән хан турында киңрәк сөйләү дә үзен аклар дип уйлыйм. Эш шунда, әлеге затның эшчәнлеге турыдан-туры Казан ханлыгы тарихы белән бәйле. Күптән түгел әдәбиятчы һәм тарихчы Марсель Әхмәтҗанов борынгы шәҗәрәләр, сугылган тәңкәләргә нигезләнеп, 1368 елда Сарай тәхетенә утырган Хәсән ханның Казан ханлыгына «нигез салучы» Олы Мөхәммәт ханның атасы булуын ачыклады. Урыс елъязмалары бу затны «болгар кенәзе» дип кенә искә алалар. Чыннан да, тагын бер елдан (1369) Хәсән хан фетнәчеләр оясына әверелгән Сарай шәһәреннән качып китә дә, Болгар олысының мөстәкыйльлеген торгызып, шунда идарә итә башлый. Әлеге факт күп нәрсә хакында сөйли. Димәк, әле Олы Мөхәммәт хан Казан ханлыгына «нигез салганчы» ук (1437 елда) Алтын Урда татарлары Болгар олысында идарә иткәннәр. Ә Олы Мөхәммәт ханның үзенә килгәндә, ул да башта 17 ел дәвамында Сарай ханы була, хәлләр катлауланып китү аркасында гына аннан китә һәм соңгы 8 ел гомерен Казан тәхетендә үткәрә. Моннан без Казан ханлыгын оештыручы, аны дәүләт буларак яңа баскычка күтәрүчеләрнең татарлар икәнен күрәбез. Шул сәбәпле, Казан ханлыгын Алтын Урда дәүләтеннән аерып карау һич тә мөмкин түгел. Бу ике дәүләт арасында туганлык җепләре, дәвамлылык гаять нык булган. Казан ханлыгына «нигез салучы» Олы Мөхәммәт хан соңрак бары тик атасы тәхетенә генә утырган (1437).

1368 елда, икенче тапкыр Сарайны ташлап чыкканнан соң, Мамай мирза белән Габдулла хан арасыннан кара мәче йөгереп узган булса кирәк. Бәлки, Габдулла хан үзе көчле мирзаның «кесә ханы» булып йөрүдән туйгандыр, мөстәкыйль яшисе килеп, аның белән араны өзгәндер. Юллар аерылышуның сәбәбе шулай ук Мамай мирзаның үзеннән чыгуы да бик мөмкин. Үзен сәясәткә багышлаган кеше килеп туган вазгыятьне исәпкә алмыйча булдыра алмый. Еш кына үз җырының «бугазына басарга» да мәҗбүр була. Соңгы еллардагы уңышсызлыклар аркасында аның Габдулла ханнан хан исеменнән идарә итә башлый. Әлбәттә инде, тәңкәләр дә Мөхәммәт Бүләк хан исеменнән сугыла. Бу вакытта Мамай мирзаның Урду каласында яшәве билгеле. Урду дигән кала борын-борыннан ханнар урдасы урнашкан җирдә үсеп чыккан булса кирәк. Шулай тора-бара «урда» сүзе кала исеменә дә күчкән булырга мөмкин.

Билгеле, Мамай мирза Сарайны ташлап киткәч тә, анда ыгы-зыгы тукталмаган. Ханнар бер-берсен алыштыра торган, тәкыткa туры килә. Зур ихтыяр көченә ия, инициативалы, тәвәккәл, батыр йөрәкле Мамай мирза татарның, ятып калганчы атып кал, дигән мәкаленә тугрылык саклагандай, өлешсез калмас өчен иң әүвәл, Кырымнан килеп, Азак каласын кулына төшерә, аннан соң катлаулы көрәш стихиясенә кереп чума һәм, тырыша торгач, үзе белән килгән Габдулла ханны ике тапкыр Сарайның алтын тәхетенә утыртуга ирешә. Икенче төрле әйткәндә, Мамай мирза бу елларда тормыяра-эз калдыргандыр. Җиңелгәндә, уңышсызлыкка дучар булганда якын дусларың, аркадашларың да еш кына синнән йөз чөерә башлый, тырнак астыннан кер эзләп, төрле гаеп тага. Бу очракта да Мамай мирзага кайберәүләрнең үзенә карата суынуын тоярга туры килгәндер. Шуның аркасында сәяси вазгыятьнең дә үзгәреп китүе бик ихтимал. Моны шул вакытта Мамай мирза белән Габдулла ханның арасы өзелүе дә раслый кебек.

Шулай итеп, Мамай гайрәте чигүе дә бар. Һәрхәлдә, алар арасында бу вакытта ниндидер каршылык килеп чыкканга охшый, чөнки 1369-1370 елларда Мамай мирза үз урдасында Мәмәт солтан дигән берәүне хан итеп күтәртә (Мөхәммәт Бүләк хан).

М.Әхмәтҗанов фикеренчә, 1368 елдан соң Габдулла хан үтереш-суешлардан, фетнәләрдән, тәхет дауларыннан ераграк торган Җаек (Урал), Сакмар елгалары тирәсенә барып урнашкан булырга тиеш. Чөнки татар шәҗәрәләреннән аның Кырымнан соң (Мамай мирза урдасы шул төбәктә була) Сакмар буйларында яшәве күренә икән. Мамай мирза үзе дә шушы хәлләрдән соң Кырымга әйләнеп кайта, Мөхәммәт Бүләк



хет өчен туктаусыз көрәш барган. Ярый, ханнар талаша, тәхет бүлешә торсын, ә без шул арада Мамай мирзаның тормыш юлын тагын бер кат күздән кичерик әле.

Мамай мирза — Габдулла хан берлегенең икенче кат Сарайдан куылуы белән Мамай мирза тормышында зур бер дәвер төгәлләнә кебек. Аның моңа кадәрге тормышын ике өлешкә бүлеп карарга мөмкиндер. Беренчесенә яшьлек еллары, егет чагы, Бирдебәк хан кызына өйләнеп, горур хан кияве булып яшәве, аннан төмән башы, ханның өлкән әмире сыйфатында төрле гайрәтлекләр күрсәтүе керсә, икенче өлеше Бирдебәк хан үтерелеп, илдә зур башбаштаклыклар, тәхет даулары башланган вакытта үз урынын эзли, шуның өчен аяусыз көрәш алып бара. Сер түгел, гаярь табигатьле, дан-шөһрәт сөючән мирза үз урынын фәкать дәүләт башкаласы Сарайда, илнең мөнбәрендә генә күрә. Аның гомерен җентекләп барлый башлагач, бу затның күңелендә гомерлек фаҗига ятканын ачык аңлыйсың. Күкрәк читлегендә горур ханнар йөрәге тибә торып та, тәхеткә утырырга хакың булмау — фаҗига түгелмени?! Бу шәхес тормышта үзен күпләрдән өстен тойган, кешеләр белән идарә итү гыйлемен бик әйбәт үзләштергән. Тик һәр заманның аерым шәхес кенә җимерә алмый торган катгый кануннары була, шуңа күрә дә, йөрәгендә җиде арыслан гайрәте талпынган Мамай мирзага гомере буе үз янында уенчык ханнар тотарга, аларны тәхеткә меңгереп-төшереп мәшәкатьләнергә, киңәшкән төс чыгарып яшәргә туры килә.

Әлбәттә, Сарай хакиме булу — аның күңеленә кереп урнашкан алтын хыял, бер идеал булган. Чыннан да, тормыш аны тәхеткә бик якын куя, хан кияве булып туй-мәҗлесләрдә дә ул ханга бик якын утыра. Ә инде йөрәгендә бетмәс-төкәнмәс көч-дәрт сизгән затның яшертен генә биек тәхет турында хыяллануы — гаеп эшмени! Ләкин Мамай мирза яхшы белгән — бу мәңге тормышка ашмаслык хыял гына. Шуңа күрә ул бөтен гомерен әлеге хыялга мөмкин кадәр якын килү өчен сарыф итә. Тәхеткә утыра алмаса да, анда үзе теләгән ханнарны куя, шуннан канәгатьләнү таба.

Әлбәттә, Сарайдан икенче кат куылу аның өчен гади вакыйга булмаган, күңелендә тирән мирза Сарай өчен алып барган мәшәкатьле даулардан соң үз олысы — Кырымга кайтып төшә, шуның белән аның тормышында бер әһәмиятле дәвер тәмамланган сыман була.

* * *

Фәкать көчле шәхес кенә үз идеалы өчен гомер буе көрәшә. Дөрес, ул вакыйгалар барышына буйсынып, күпмедер вакыт актив тормыштан читкә китеп торырга да мөмкин. Ләкин бу әле тынычлану түгел. Уңай шартлар туу белән аның күңелендә пыскып яткан күмерләр кабат җанлана, ялкын чәчә башлый һәм, күп тә үтми, аның бөтен вөҗүден көрәш уты чолгап ала. Шәхес үз стихиясенә әйләнеп кайта. Гайрәтле йөрәге аны яңа тәвәккәллекләргә этәрә.

Әйе, илдә низаглар купкач, мирза үзен-үзе белештермичә көрәшкә ташлана, соңгы елларда ару-талуны белмичә гел хәрәкәттә була. Әйләнеп карасаң, ун ел вакыт үтеп тә киткән икән! Ә нәтиҗә шул ук -- ул кабат үз олысы — Кырымга кайтып төшә. Әйе, ул гомер буе язмыш әзерләп куйган кысаларга сыя алмый, йөрәкле адәм була. Мескен, вак җанлы ханнарга баш иеп яши белми. Бәлки, аның бөтен фаҗигасе дә шундадыр... Инде менә урдасында яңа ханны — Мөхәммәт Бүләкне тәхеткә утырта...

Сарайда да ныклап тамыр җибәрә алмый ул.Анда җиде яктан җитмеш җиде дошман аңа чокыр казый, дөнья тәмам болгана, иреннәрендә сөт тә кипмәгән күпме малай-шалай биек тәхет турында хыяллана, аларны арттан котыртып, үсендереп торучылар да җитәрлек. Ярар, дөнья бит Сарайдан гына тормый. Җи-

# мирза

тмәсә, ул Иделнең көнчыгыш ярында урнашкан. Ике арада зур су — Идел ага. Ярның бу ягына чыксаң, күпме җирләр, калалар бар, яшел далалар җәйрәп ята. Идел белән Кырым арасында кылыч уйнатсаң, шул биләмәләргә урыс кенәзлекләрен дә китереп кушсаң - тагын ни кирәк?! Һәм Мамай мирза чыннан да Иделдән көнбатышта яткан җирләрдә үз хакимиятен ныгытырга керешә.

Инде 1370 елда ук, ягъни Сарайны ташлап китүенә ике ел тулар-тулмас, Мамай мирза Суздаль һәм Нижний Новгород кенәзе Дмитрий Константиновичны Болгар олысына яу белән җибәрә. Яуга җибәрерлек булгач, алар Мамай мирза кул астында яшәгәннәр, дигән сүз. Гомумән, урыс кенәзләре, ышанычсыз Сарай ханнарына таянуга караганда, гайрәтле Мамай мирза белән эш йөртүне, салымнарын аңа түләүне кулайрак күрәләр.

Бу вакытта Болгар олысы үзәге инде Казанга күчкән була, чөнки Болгар урыс яуларыннан соң кабат күтәрелә алмый. 1369 елда Сарайны ташлап качкан Хәсән хан Казанга барып урнаша, аны ныгыта, кальга төзи. Шулай да аның әле яу белән килгән урыс гаскәренә каршы торырга көче җитми. Чыганаклардан күренгәнчә, ул кенәз Дмитрий Константиновичка зур йолым түләргә һәм бүләкләр бирергә мәҗбүр була. Мамай мирза әмере буенча, урыслар Казанда Хәсән солтан белән аның улы яшь Мөхәммәт угланны да идарәче итеп куялар. Шулай Казанда берьюлы ике хаким пәйда була. Мамай мирза, мөгаен, моны Хәсән солтанга үч итеп юри эшләгәндер, чөнки ике ел гына элек (1368) Хәсән солтан, Габдулла хан белән аны Сарайдан куып җибәреп, үзе тәхеткә утыра. Ә бер ел үтүгә үзе үк шул хәлгә төшә.

Бу очракта Мамай мирза үзен бик нечкә психолог буларак күрсәтә, ул дошманы Хәсән солтанның улы Мөхәммәт угланны атасы белән тигез куя, шул рәвешле аннан үч ала. Улы белән Казан тәхетен бүлешү Хәсән солтанга җиңел булмагандыр.

Кыскасы, 1369-1377 елларда Мамай мирза Иделдән көнбатышта яткан җирләрдә үз хакимиятен ныгыту белән шөгыльләнә. Шул исәптән урыс кенәзлекләре тормышына да актив катнаша, төрлечә басым ясап, аларны үз канаты астына алырга омтыла. Ләкин бу процесс бер яклы гына бармый. Сарайда тотрыклы хакимият булмаудан файдаланып, урыс кенәзләре дә Идел буендагы олысларга һөҗүм итүне ешайталар, отыры батырая баралар.

Мәсәлән, 1374 елда Нижний Новгород халкы Мамай мирзаның илчеләрен саклар өчен җибәрелгән 1,5 мең кешелек отрядын юк итә, ә баш илче Сары Айка иптәшләре белән кулга алына. Ләкин татарлар ничектер зинданнан чыгу юлын табалар да, кулга корал тотып, урыслар белән җан-фәрманга сугышалар. Шунда барысы да ятып кала. Әлеге хәлләр Мамай мирза белән урыс кенәзлекләре арасында тартышу барганлыгын күрсәтә.

Ә Сарайда бу вакыт эчендә тагын берничә хан алышына. Хәсән ханнан соң тәхеткә Тулунбик хан, Алибик хан, Каганбик хан, ә 1375 елда Гарәпшаһ ханнар утыра. Соңгысы чыгышы белән Себер якларыннан була. 1377 елда аңа Күк Урдадан чыккан Ырыс хан белән бик нык бәрелешергә туры килә, ахыр чиктә Сарай Ырыс хан кулына төшә, Гарәпшаһка качып котылырга туры килә. Ул Иделнең урта агымына - - мордва җирләренә килеп урнаша, анда урыслар белән бик зәһәр сугыша. Бераздан Нижний Новгородка килеп, аны да яндыра, Рәзәнгә яу чаба. Әлбәттә, Иделнең уңъяк ярында тагын бер солтанның үзенә олыс яулап маташуы Мамай мирзаның ниятенә һич тә туры килми, шуңа күрә ул Гарәпшаһ белән көрәш башлый. Бер ел үтәр-үтмәс аны куып та җибәрә. Шуның белән Гарәпшаһның исеме тарихтан төшеп кала. Әлеге бәрелешләрнең берсендә ул һәлак булгандыр, күрәсең.

Сарай тәхетенә Ырыс хан чыккач, Алтын Урда дәүләте ике капма-каршы өлешкә бүленә дә куя. Көнчыгышта Ырыс хан хөкем сөрсә, көнбатыштагы җирләрдә Мамай мирза хуҗа булып кала. Идел исә Жучи олысын (Алтын Урда) икегә бүлүче чиккә әверелә.

Ырыс хан биләмәләренә, Сарай каласы белән беррәттән, Мангышлак киңлекләре, Арал диңгезе буйлары, Сыр-Дәрья тирәсендәге калалар (Сыгнак, Йаса, Отрар), киң далалар керә. Бары тик Харәзем олысы гына аңа буйсынмыйча мөстәкыйль яши.

Мөхәммәт Бүләк хан исеменнән идарә иткән Мамай мирза биләмәләренә исә Кырым, Төньяк Кавказ, Кубан, Дон буйлары, Азак белән Мажар калалары, Идел буеның байтак өлеше керә. Урыс елъязмачылары бу вакытта Мамай мирзаны «царь Волжский» дип йөртәләр, чөнки ул Иделнең уңъяк ярындагы иң көчле хакимгә әверелә. Шулай Алтын Урда дәүләтенең бер канаты аның кулында кала. Шуңа да карамастан, Мамай мирза өчен хәл ителмәгән бер мәсьәлә һаман яши бирә — ул да булса, урыс кенәзлекләренең язмышы, аларның статусы. Соңгы елларда барган үзара низаглар аркасында урыслар артык иркен сулый башлыйлар. Вак-төякне инде әйткән дә юк, хәтта Мамай мирзаның илчесе Сары Айканы да үтерергә җөрьәт итәләр.Ә 1376 елда Мәскәүнең олуг кенәзе Дмитрий Иванович Болгар олысының Казан каласына яу җибәрә. Бу хәл Казан ханының йолым түләве белән тәгалләнә. Гомумән, соңгы вакытта урысларда нindидер ирәю, бер сүзгә килү, үзара якынаю галәмәтләре нык сизелә. Әле 1372 елда ук Мамай мирза Рәзән кенәзлегенә олуг кенәз итеп Олег Ивановичны билгеләгән була. Тора-бара ул да Мәскәүнең олуг кенәзе белән якыная, аны үзенең «өлкән туганы» дип таный, сүз берләшә. Димәк, Мамай мирза кул астыннан чыгарга җай эзли. Инде менә Мәскәү кенәзе дә еллык дань-салымның күләмен киметү турында сүз кузгата, зарлана, канәгатьсезлек белдерә. Эшләр болай барса, урысларның бөтенләй кулдан ычкынып куюлары бар.

Бу хәтәр күренешләр Мамай мирзаны урыс кенәзлекләре белән ныклап торып шөгыльләнергә кирәк, дигән фикергә этәрә. 1377 елда ул, мордваларның урыслардан зарлануына, яклау соравына колак салып, Пьяна елгасында берләштерелгән Суздаль-Мәскәү гаскәрен туздырып ташлый, аннан Нижний Новгородка ук барып чыга, каланың үзеннән һәм әйләнә-тирәсеннән шактый мал алып кайта. Шушы ук юнәлештә хәрәкәт итеп, Мәскәүнең олуг кенәзе Дмитрий Ивановичка каршы Бигеч мирзаны яу белән җибәрә. Тик аның бу адымы уңышсызлыкка дучар була. Дмитрий Ивановичның гаскәре татарларны Рәзән кенәзлеге туфрагыннан аккан Вожа суы буенда каршы ала. 1378 елның 11 августында Бигеч мирза сугышчылары елганы кичкән чакта урысларның бик көчле һөҗүменә дучар була. Бу бәрелеш татарлар өчен зур фаҗигагә әверелә. Каршы ярга чыгып сафларга тезелеп өлгерә алмаган татар гаскәре зур югалту кичерә. Шушы бәрелештә Бигеч мирза, Хаҗи бәй, Кабырга, Карабелек, Костров мирзалар һәлак була.

Әлеге югалтуны Мамай мирза бик авыр кичерә. Тынгысыз тормышында аның төрле хәлләргә юлыкканы бар - – күп тапкырлар дошманнан өстен чыкканы да, шулай ук җиңелү ачысын татырга да туры килгәне бар аңа. Әмма моңа хәтле аның әле бер тапкыр да урыслардан җиңелгәне юк иде. Хурлык, хурлык... Кеше күзенә күтәрелеп карарга оят. Әлбәттә, бу хәлне ул татарның данын-абруен төшерә торган вакыйга буларак кабул итә. Ә бит мирза инде Үзбәк хан заманнарын кире кайтару, олысларны туплау, бу башбаштаклыкларны бетерү турында ук хыяллана башлаган иде.

Нәкъ шул көннәрдә аның урдасына килеп ирешкән хәбәрләр вакыйгаларга икенчерәк төсмер бирә, Мамай мирзаның авыр кичерешләрен бераз җиңеләйтеп җибәргәндәй була. Анда, Кояш чыгышындагы олысларда, Туктамыш белән барган көрәштә Ырыс хан һәлак булган, дигән хәбәр тиз арада далага таралып өлгерә. Инде менә аталары үчен кайтарырга Ырыс хан уллары Тактакыя белән Тимермәлик угланнар Туктамышка каршы күтәрелгән. Димәк, тиз генә тынычлана алмаячаклар. Бу инде Мамай мирзаның артында, Иделнең сулъяк ярында, әлегә көчле дошман тормаячак, дигән сүз. Болай булгач, Мамай мирза зур көч җыеп урыс кенәзләренә яу чаба алачак. Әйе, аңа да Вожа суы өчен, шул сугышта шәһит киткән мирзалары өчен үч кайтармый калу ярамас.

Һичшиксез, кайтарырга кирәк булыр. Аннан соң аңа халык алдында абруен ныгыта төшү дә комачауламас. Юкса, соңгы вакытта кайберәүләр аңардан күзен яшерә башладылар. Әйтеп бетермәгән уйлары бар, димәк... Әлбәттә, беренче эш итеп аңа урысның олуг кенәзе Дмитрий Ивановичны үз урынына утыртырга кирәк. Мәскәү тез чүксә, башкалары үзләре үк баш иеп киләчәк.

Шулай Мамай мирза урыс кенәзлекләренә каршы зур яу оештыру эшенә керешә. Ләкин тарихка «Куликово сугышы» булып кереп калган әлеге орыш аның өчен нинди фаҗига белән тәмамланасын ул, әлбәттә, башына да китерә алмый. Кеше тәкъдир тактасында ниләр язылганын алдан белми шул...



**Васил ГАЙФУЛЛИН:**

# Теле барлар халык булган, теле юклар балык булган

*Тиздән, балаларны мәктәпләргә чакырып, көмеш телле кыңгырау чыңы аваз салыр. Иң матур киемнәрен кигән, кулларына чәчәкләр тоткан балаларны ялт иткән чиста, якты мәктәпләр һәм бусагадан ук яраткан укытучылары каршылар. Балалар каникулда чакта армый-талмый, үз куллары белән ремонт ясаган укытучылар, мәктәп төзергә акча каян табыйм, дип баш ваткан хакимият җитәкчеләре, төзелеш кирәк-яраклары артыннан көн-төн чапкан мәктәп директорлары, төзүчеләр һәм уку-укыту эшләрен алга җибәрү өчен төн йокыларын калдырган мәгариф хезмәткәрләренең киеренке эшләре — барысы-барысы 1 сентябрьдә яңгыраячак кыңгырау чыңы хөрмәтенә. Әмма балалар моны белми, һәм алар шуның белән бәхетле дә.*

*Педагогия фәннәре докторы, профессор, Татарстан мәгариф министры Васил Габдулла улы ГАЙФУЛЛИН белән әңгәмәбез мәгариф, югары һәм урта мәктәпләр, яңа уку елы һәм укытучылар алдына куелган бурычлар турында.*

**— Васил әфәнде, Дәүләт Советы сессияләренең берсендә республикадагы югары уку йортларын Татарстан Мәгариф министрлыгы карамагына күчерү турында сүз барды. Бу җәһәттән нәрсәләр эшләнә?**

— Мәсьәлә бик күпкырлы. Югары мәктәпләр төрле ведомство, министрлыкларга карый. Авыл хуҗалыгы, ветеринария академияләре Русия авыл хуҗалыгы, педагогик вузлар — мәга-

> ***Татарстанда 2455 мәктәп бар, аларда 560 мең бала укый. 120 гә якын һөнәр училищесында 60 мең укучы һөнәр һәм өлгергәнлек аттестаты алачак.***

риф министрлыклары карамагында иде. Үз өстебезгә ниндидер вәкаләтләр алганчы, һәр вузның ректораты белән бу мәсьәләне төрле яктан тикшереп, уртак фикергә килергә һәм Ректорлар советында зур сөйләшү үткәрергә кирәк. Без яңа положение эшләдек һәм аны югары мәктәпләргә житкердек. Әле аны ныклап өйрәнәсе бар. Ә педагогик вузларны без тулысынча министрлык карамагына алырга әзер.

**— Татарстанның мөстәкыйльлеге турындагы Декларация кабул ителүгә биш ел тулды. Җөмһүриятебезнең эш-гамәлләрендә һәм шәхсән үз тормышыгызда Декларациянең йогынтысы сизеләме?**

— Минемчә, мәгариф өлкәсендә соңгы елларда ирешкән уңышларыбыз тулысы белән әлеге Декларациягә бәйле. 80 нче еллар ахырында Казанда бер татар мәктәбе булып, анда да күп фәннәр урысча укытыла иде. Хәзер 30 га якын татар мәктәбе һәм гимназия бар. Быел җитмешкә якын урыс мәктәбендә татар сыйныфлары ачыла. Киләчәктә бу саннар, һичшиксез, артачак.

Ә инде телләр турындагы Законны мәгариф челтәре шактый уңышлы гамәлгә ашыра, диярге саллы дәлилләребез бар.

**— Шулай да урыс телле укытучылар арасында ниндидер курку, шикләнү дә юк түгел. Татар һәм башка милләт балалары үз телләрендә белем алса, без эшсез калабыз, диючеләр барлыгын тәгаен беләм. Казандагы 42 нче мәктәптә купкан җәнҗал — шуңа ачык мисал...**

— Бу очракта урыс телле укытучыларның борчылуы нигезсез: мәктәп яшендәге балаларның яртысы диярлек урыс балалары. Элегрәк андый шик-шөбһәләр сирәк очрый иде, хәзер психологик барьер күпкә кимеде.

**— Югары уку йортларында татар егет-кызларын туган телләрендә укытуга карашыгыз ничек?**

— Моннан алты ел элек педагогия университетының физика факультетында әлеге эшне мин башлап җибәргән идем. Хәзер менә техник вузларда, аерым алганда Казан авыл хуҗалыгы, архитектура-төзелеш академияләрендә, КамПИда һәм башка кайбер югары мәктәпләрдә бу эш җайга салынып килә. Хәерле юл телим аларга. Бала теләсә нинди вузга имтиханны үз телендә биреп керергә һәм белем алырга тиеш. Бу — телләр турындагы Законны тормышка ашыруда төп юнәлешләрнең берсе дип саныйм. Бәлки, һәр югары мәктәптә татар теле кафедрала-

> ***Татар гимназияләренең саны 90 га җитте. Яңа уку елында тагын 36 татар мәктәбе ачыла.***

ры ачу максатка ярашлы булыр.

**— Укытучылар Сез язган физика дәреслеген бик яратып кабул итте. Китап язарга һәм министр вазифаларын да башкарырга каян вакыт җиткерәсез, Васил әфәнде?**

— Миң үзем татар мәктәбендә укыдым һәм 40 ел эш стажым бар. Дәреслекләрнең төрлесен күрдек. Аларның уңай яклары да, кимчелекләре дә җитәрлек булды. 7 нче класслар өчен физика дәреслеген язганда мин ул кимчелекләрдән арынырга тырыштым. Китап хәтта үземә дә ошады. 8 нче класс өчен физика китабын нәшриятка тапшырдым, ә 9 нчы класс дәреслеген хәзер язып утырам. Алар барысы да ял сәгатьләре, йокы, чираттагы ял исәбенә эшләнде. Элегрәк үз-үземә атнасына 20 сәгать эшләү бурычын куя идем, хәзер 15 сәгать чамасы вакыт кала.

**— Дәреслекләр бастыру өчен махсус «Мәгариф» нәшрияты ачылды. Аның эшчәнлегеннән Сез канәгатьме?**

— «Мәгариф» нәшрияты ике министрлыкка карый — безгә һәм Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгына. Дәреслекләрнең күбесе «Мәгариф»тә басыла. Без җентекләп нәшрият планын тикшерәбез һәм китаплар басу өчен акча табып бирүдә булышабыз. Алда хәл итәсе уртак мәсьәләләр күп. Әйтик, башка төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезгә дәреслекләр белән булышу. Бу — шактый катлаулы эш. Аны без эшләмәсәк, кем башкарыр. Бу — безнең уртак эшебез, уртак бурычыбыз.

**— Татар мәктәпләре, гимназияләр ачылу укытучыларга икенче сулыш өрде шикелле...**

— Бу чыннан да шулай. Гимназияләрдә бөтенләй икенче мохит, икенче тормыш. Һәр гимназиянең үз йөзе, үз традицияләре, үз бәйрәмнәре барлыкка килде. Бер гимназия чит телләрне тирәнтен өйрәнсә, икенчесе — географияне, тарихны яисә химияне яхшы үзләштерә. Кукмара районының Зур Сәрдек лицее, мәсәлән, укытучылар әзерли. Аларның юнәлешләре төрле-төрле, ә таләпләр барысы өчен дә бер:

- балалар гимназиягә сайлап алына;
- сайлап алынган балаларның үсешен тәэмин итәрдәй сәләтле, инициативалы укытучылар шулай ук конкурс нигезендә алына;
- гимназистлар үзләренең белем дәрәҗәсе, тәрбияләнелеге белән гомуми мәктәп укучыларыннан аерылып торырга тиеш;
- гимназияне тәмамлаганда бала, дәүләт телләреннән башка, кимендә ике чит телдә сөйләшә белергә тиеш;
- укучы теләсә нинди вузга конкурстан үтеп керергә сәләтле булырга тиеш.

Бу җәһәттән Казан дәүләт педагогия университеты каршындагы төрек-татар гимназиясен мактап телгә аласы килә. Быел анда икенче чыгарылыш булды. Укучыларның барысы да теләсә кайсы югары мәктәпкә керергә әзерлекле. Аларның тугызы Төркиягә барып, андагы югары уку йортларына берниндн таныш-белешсез, кода-кодагыйсыз дигәндәй, имтиханнарын уңышлы тапшырдылар. Шулай ук 2 нче, Галимҗан Ибраһимов исемендәге, 4 нче, 15 нче гимназияләр эшчәнлеге игътибарга лаек.

**— Димәк, Татарстанның мәгариф системасы Аурупа стандартыннан ким түгел?**

— Моны раслау өчен берничә мисал китерәм. Русия күләмендә 100 мәктәп иң яхшылар рәтенә кертелгән, шуларның унысы — Татарстаннан. Казанның 122, 131 нче мәктәпләре, Бөгелмәдәге 6, Зеленодолдагы 1, Балык Бистәсендәге 1, Чаллыдагы 3, 26 нчы, Кукмара районы Зур Сәрдек лицее һ.б. Русиядә 89 өлкә һәм Мәскәүнең үзендә генә дә меңнән артык мәктәп барын исәпләсәң, бу күрсәткеч, минемчә, бер дә начар түгел.

Америка гуманисты һәм экономисты Соросс үзенең шәхси премиясен булдырды. Илледән артык укытучыбыз шул премияне ала. Узган ел экология буенча Бөтендөнья олимпиадасында төрек лицееннән ике укучыбыз икен-

> ***Мәгариф министрлыгына караган 2500 гә якын балалар бакчасында 350 меңнән артык бала тәрбияләнә.***

че урынны алып кайтты. Русия олимпиадаларында бик күп балаларыбыз җиңү яулый. Саба районы, Шәмәрдән урта мәктәбе укучысы Минһаҗев ике тапкыр дөнья олимпиадасында икенче урынны алды.

**— Васил әфәнде, соңгы елларда Мәгариф министрлыгы башлангычы белән күп кенә кызыклы чаралар уздырыла. Мәсәлән, «Ел укытучысы», алдынгы методика белән эшләүче педагоглар конкурсы. Мондый чаралар, һичшиксез, иҗади эшкә этәргеч булып тора.**

— Уку планнарын үзебез әзерлибез. Бу хакта Русия белән килешү төзедек. Татарстан белән бәйле булган география, тарих кебек фәннәр дәреслеккә туры килми. Татар теле һәм әдәбияты, җыр, хезмәт, физик культура һ.б. фәннәрне укыту өчен иң яхшы программага конкурс игълан иткән идек. Шул ук хезмәт дәресләрен генә алыйк. Эш сөючән татар халкының бик матур күн, агач, тимер, бакыр белән эшләү, тегү, чигү үрнәкләре бар. Алтын, көмеш, ука белән нинди матур чигү үрнәкләре саклана! Болар — безнең рухи мирасыбыз. Укытучылар бу эштә гаҗәеп активлык күрсәтте. Казандагы 4 нче гимназиядән берьюлы ике укытучы республикада иң яхшы программа авторлары дип табылды; алар — география укытучысы, гимназия директоры Җәүдәт Хөсәенов һәм җыр укытучысы Раил Сәйфуллин. Ә алдынгы методика буенча эшләүчеләр бәйгесендә катнашучылар саны 200дән артты. Шуларның утызын сайлап алдык, һәм аларның эш тәҗрибәсен пропагандалаячакбыз.

**— Хәзер урыс мәктәпләрендә дә 15-20 мең татар теле укытучысы эшли, аларга ярдәм итү өчен махсус директор урынбасары штаты да каралган. Димәк, белгечләргә кытлык зур. Аннан соң укытучыларның шактые урыс телле, урысча фикерли. Бу кыен хәлдән чыгу юлы бармы?**

— Безнең карамакта 12 педагогик уку йорты бар. Алар ел саен 200-250 укытучы әзерли, ә безгә кимендә 1500-2000 кеше кирәк. Шуңа күрә министрлык каршында тагын бер колледж ачарга булдык. Ул Яңа Савин районында, район мәктәпләре өчен чит тел, шәһәр мәктәпләре өчен татар теле һәм әдәбияты укытучылары әзерләячәк. Укытучыларның белемен һәм квалификациясен күтәрү институты да бу өлкәдә үз өлешен кертә. Физика, химия, математика, биология кебек фәннәрне татар телендә укытучылар өчен махсус курслар ача.

**— Васил әфәнде, яңа уку елы кай ягы белән үзенчәлекле булачак?**

— Хәзер мәктәпләр төрледән-төрле. Фәннәрне балалар, ничек кенә теләмәсен, ничек кенә тырышмасын, тигез үз-

> ***Мәгариф өлкәсендә 50 меңнән артык укытучы эшли, барлык хезмәткәрләр саны Татарстан халкының өчтән берен тәшкил итә.***

ләштерә алмый. Аерым фәннәрне тирәнтен өйрәтүче 260 тан артык шундый юнәлешле мәктәп бар. Авылларда андый мәктәпләр ачу нигездә мөмкин түгел. Шулай да сәләтле балаларга тирәнтен белем бирү өчен мөмкинлек таптык: программадан тыш махсус региональ сәгатьләр бирәбез. Алар атнага бәлки 6-7, бәлки 8 сәгать булыр. Һәр мәктәп үз белгечләренең сәләтенә карап эш итәчәк. Безнең бурыч — авыл балаларының югары мәктәп конкурсларында җиңү сәләтен арттыру.

**— Яңа уку елында балаларны яңа мәктәпләр, яңа биналар белән куандырырсызмы?**

— 1 сентябрьгә 8000 урынлы 21 яңа мәктәп бинасы өлгерәчәк. Ә үзгәртеп корулар, реконструкцияләр бар. Күп гимназияләр кысан биналарда интегә. Казандагы 3 нче гимназияне берничә ел өйдәш итеп торган 10 нчы мәктәп үзе татар мәктәбе итеп үзгәртелә. Ә 2 нче Горкида өченче гимназия өчен салына башлаган бина проектын үзгәртеп, аны 1996 елның 1 сентябренә тапшырачакбыз. 39 нчы кварталда яңа татар мәктәбе яисә гимназия ачыла, анда чит телләрне тирәнтен өйрәнүгә игътибар зур булачак. 82 нче мәктәптә реконструкция була, ә 21 нче башлангыч татар мәктәбе тулы булмаган урта мәктәпкә әйләнәчәк. 87, 115, 116, 121 нче мәктәпләр татар-урыс мәктәпләре итеп үзгәртелә. Яңа Савин районында татар-төрек икътисади лицеен ачу күздә тотыла. Идел буе районында 110, 307, 396 нчы балалар бакчаларына йөрүчеләр туган телләрендә тәрбияләнәчәк һ.б.

**— Районнарда шундый җанга якын үзгәрешләр күтеләме?**

— Балтач районында бик матур гимназия бинасы әзер. Октябрь, Яңа Чишмә районнарында берничә мәктәп-гимназия ачылачак.

**— Укытучылар өчен нинди күңелле хәбәрләр әйтерсез икән?**

— Күптән түгел Президентыбыз мәгариф хезмәткәрләре белән очрашты. Ул безне куандырырдай сүзләр әйтте: халкыбыз киләчәген — яшь буынны тәрбияләүче укытучы, тәрбиячеләрнең эш хакы хезмәтләренә тәңгәл килергә тиеш, диде. Ә мин үз чиратымда «Мәдәни җомга» аша шуны вәгъдә итә алам: укытучыларга ике айлык премия

> ***Бакча яшендәге балаларның 58, укучыларның 42 проценты татар телендә белем ала. Казанда бу сан — 20, Чаллыда 36 процент тәшкил итә.***

һәм бер айлык хезмәт хакы кадәр матди ярдәм, ягъни елына 15 хезмәт хакы түләнәчәк.

**— Беренче сентябрь — мәгариф хезмәткәрләренең изге көне, яңа уку елы башы. Сез аларга нинди теләкләр телисез?**

— Укытучыларга теләгем шул: еллар авыр булса да, күңелегезне төшермәгез. Гаиләгездә татулык, сәламәтлек, иминлек телим. Ә укучыларга шуны әйтәсем килә: киләчәк буын белемле кешеләр буыны булыр. Тәпле белем алыгыз, кешеләрдә булган иң уңай сыйфатларны үзегездә тәрбияләгез.

**Әңгәмәне**
**Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА**
**оештырды.**

● **Алексей СПОРИУС,**
архитектор:

**— Минем әтием, бабам, немец булсалар да, Татарстанда туып үскәннәр. Бабамның бабасы биредә граверлык эшен җайга салган, хәтта шәмаилләр дә ясаган. Бабам рәссам, медицина белгече булып, муляжлар эшләү белән шөгыльләнгән. Әтием исә, архитектор буларак, Казандагы күп кенә биналарны төзешкән. Үзем дә мәркәзебезне бизәүдә гомерем буе бөтен көчемне биреп эшләдем. Шулай булгач, Татарстан — минем чын Туган илем, ә үземне аның милләтпәрвәредер дип беләм. Гомерем буе бирелдәге халык белән тирәнтен аралашып, дус булып яшәдем. Татарстанның мөстәкыйльлеге турындагы Декларация кабул ителгән елда мин лаеклы ялга чыктым һәм, әйтергә кирәк, бу олы вакыйганы шатланып һәм беркадәр сагаеп каршы алдым. Мөстәкыйльлек турында Декларация мин көткәннәрне бирде кебек. Иҗатта яңа темалар барлыкка килде, ирек бирелде. Мине соңгы елларда татар мәдәниятенең күтәрелүе, телгә игътибар арту бик сөендерә. Үземнең оныгым да татар телен өйрәнә башлады.**

**Сүземнең ахырында шунысын да әйтәсем килә: мине Россиядәге патриотик-фашистик хәрәкәт бик тә борчый һәм бу беркемгә дә бер нәрсәгә дә кирәкми. Илләрдә иминлек, тынычлык булсын!**



# Безгә бәйсезлек нигә кирәк?

Бик тә урынсыз сорау бу, җәмәгать, чөнки татарлар Русиядә генә түгел, БДБ илләрендә дә яши. Алай гына да түгел, 1989 елда халык санын алганнан соң күренгәнчә, Русиядәге биш миллион ярым татардан ике миллионга якыны гына Татарстанда гомер итә. Нишләп болай килеп чыккан бу?

Татарлар туган җирләреннән 1552 елның 2 октябреннән — Казанны Явыз Иван басып алган көннән башлап — гасырлар дәвамында күчеп китә торганнар.

Татарларны көчләп чукындыруны дүрт зур кампаниягә бүлеп карарга мөмкин. Беренчесе Казанны басып алуга ук башлана. Икенчесе — Явыз Иванның улы Федор Иоаннович чорында; бу патша 1593 елда: «Казан җирендәге барлык мәчетләрне туздырып ташларга, Казан шәһәренә бер татарны да кертмәскә», дигән фәрман чыгара. Урыслаштыруның өченче чоры XYIII гасырның беренче яртысында үткәрелә. Бу вакытта Петр I нең чит халыкларны чукындыру турында фәрманы индерелә. Дүртенчесе шул ук гасырда, Елизавета Петровна хөкүмәте белән килешенеп, Казан епископы Лука Канашевич тарафыннан тормышка ашырыла. Ул бәндә үзенең кансызлыгы белән татар халкының күңеленә Явыз Иван кебек ук кабахәт бер зат булып кереп калган. Татарлар үз ватаннарын ташлап китеп, мөмкин кадәр ераккарак — Уралга, Себергә, Казакъстанга, Урта Азиягә барып урнашканнар.

Бик күп татарларның Татарстанда яшәмәвенә тагын бер сәбәп бар. Татарстанның суверенлыгына каршы кешеләрнең йә кайсысы түбәндәге сорауга тәгаен җавап бирә алыр икән: әйтик, Явыз Иван басып алганчы ук Түбән Иделдә һәм Каспий буйларында яшәгән Әстерхан татарлары ни өчен хәзер Татарстанда яшәргә тиеш әле? Сорауны болай кую дөресме соң? Ни өчен XYI гасырда Ермак тарафыннан буйсындырылганчы йөзләрчә еллар буена Иртыш белән Обь буйларында яшәгән Себер татарлары хәзер Татарстан гражданнарына әйләнергә тиеш? Мантыйгы бармы бу сорауның? Казан татарлары белән Әстерхан татарлары, Себер татарлары, Кырым татарлары этнографик яктан бер-берсеннән аерылып торалар бит.

Халыкны соңгы тапкыр исәнкә алгандагы мәгълүмат буенча, Русиядә 120 миллион урыс яши, татарлар, әйткәнемчә, 5,5 миллион чамасы. Бу кадәр зур аерманың сәбәбе нәрсәдә? Әлеге этносларның табигый яшәү шартлары бертөрле ләбаса! Русиядә сан ягыннан икенче урында торган халык күбрәк булырга тиеш, югыйсә. Моның сәбәбе бик гади: урыслардан аермалы буларак, татарлар инде дүрт гасырдан артыграк үзләренең дәүләтчелегеннән мәхрүм ителгән килеш яшиләр, ә дәүләтчелеге булмаган халык белән теләсә нишләргә мөмкин. 1920 елда большевиклар татарларга өтек автономия кыяфәтендәге «дәүләт» бирергә карар иткәч, бу автономиянең чикләрен ленинчыл БҮБК билгели. Нәтиҗәдә татарлар күпләп яши торган тулы бер районнар (ул чакта өязләр) Татарстаннан читтә торып кала. Шуңа күрә бүген миллионнан артык татарның — Башкортстанда, ярты миллионга якынының Татарстан чикләре буенда яшәве бер дә гаҗәп түгел.

1944 елның маенда бер төн эчендә Кырым татарларының туган илләреннән куылуы мәгълүм. Ә менә сугыш алдыннан һәм сугыштан соң Литва татарларының депортацияләнүен күпме генә кеше белә икән? Ә 1953 елда Казан татарларын Себергә сөрү турында карар әзерләнгәнен Татарстаннан читтә яшәүчеләрнең берсе дә белми торгандыр әле. Тиранның үлеме генә коткарып калды безне мондый афәттән.

Безнең дәүләттә яши торган халыкларның хокукына Русиянең яңа Конституциясендә бик аз игътибар ителгән, «инородецлар» турында исә сүз арасында гына искә алына. Бәс, әгәр шулай икән, без янә «өлкән агай» ихтыярына бәйле булып, яңадан да урыслар өчен «чаплашка» һәм «татарская морда» булып калабыз түгелме соң?!

Менә ни өчен Татарстанга бәйсезлек кирәк. Әгәр дә без, Татарстанда яши торган татарлар, юкка чыгабыз икән (ә бу хәлнең булуы бик тә мөмкин), ул вакытта Русиянең төрле төбәкләрендә яшәүче башка милләттәшләребез дә юкка чыгачак. Русия белән чын-чыннан ассоциацияләшкән һәм дөнья җәмәгатьчелеге тарафыннан танылган үз дәүләтчелегебез булса гына без киләчәгебезгә ышанып яши алачакбыз.

**Илдар СИБГАТУЛЛИН.**
**(«Новое время»).**

# «Куркыныч» китап



*** Алишев С.Х. Казань и Москва: межгосударственные отношения в XY-XYI вв. Казань, Татарское книжное издательство, 1995. 180 стр.**

**Соңгы вакытларда Татарстан китап нәшриятында киң җәмәгатьчелекне, тарих белән кызыксынучыларны, галимнәрне үзләренең саллылыгы, мәсьәләгә төрле яктан яңача килүе белән куандырган байтак китаплар дөнья күрде. Шундый китапларның берсе — танылган галим, тарих фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең Тел, әдәбият һәм тарих институтының тарих бүлеге мөдире Сәлам Алишев тарафыннан иҗат ителгән.* Хезмәтне нәшрият мөхәррире Рәсим Әмирханов редакцияләгән һәм бу эшкә байтак өлеш керткән.**

**Бу китапны М.Худяковның моннан 70 еллар элек басылып чыккан «Очерки по истории Казанского ханства» (1923) исемле китабыннан соң урысча язылган һәм дөнья күргән иң берәгәйле хезмәтләрнең берсе, диярга мөмкиндер.**

**Чор таләпләренә төрлечә җавап бирсәләр дә, аларның һәр икесенә ниндидер бер гомуми кыйбла, рухи уртаклык хас.**

**Әйтергә кирәк, С.Алишев, башка җитди мәсьәләләр белән беррәттән, күп еллар дәвамында үтә четерекле, хәтта ки «куркыныч» саналган әлеге тема буенча инде чирек гасырдан артык эшли. Шушы чор эчендә аңа, бу темага бәйле рәвештә, бихисап кыенлыклар кичерергә, рәнҗетүләргә дучар булырга туры килде. Төрле утырышларда күп кыйналды, типкәләнде бу галим. Сәбәбе бер — тикшеренүченең әлеге мәсьәләгә карашы, аны чишү алымнары рәсми даирәләрдә фатиха алган официоз концепция кысаларына сыймый иде. Әгәр без күзәтә торган китапта кайбер мәгънәви чатаклыклар очрый икән, ихтимал ки, алар үзләренең табигатьләре белән шушы «ярамый» сабакларына бурычлыдыр.**

Үзенең иҗат процессында галим әлеге темага кагылышлы күп хезмәтләрне (революциягә чаклы булсын, совет чоры тикшеренүчеләренеке булсын), төрле җыентыкларны, гайре рәсми язмаларны җентекләп барлаган, өйрәнгән. Бу яктан аның бигрәк тә беренчел чыганакларга, аерым алганда, урыс елъязмаларына турыдан-туры мөрәҗәгать итүе хуплауга лаек. Ул гына да түгел, Сәлам Хатыйп улы Казан—Мәскәү мөнәсәбәтләренә багышланган, мәсьәләгә төрле тарафтан килгән хезмәтләргә җентекле күзәтү ясаган, аларда хөкем сөргән фикер аерымлыкларын шәрехләгән, үзенең төгәл позициясен ачыклап биргән.

Проблеманың төп юнәлешләрен күзәтеп, автор татарның дәүләтчелек тарихын гасырлар дәвамында чалыш көзгедә күрсәтеп килгән рәсми-империячел карашларга тәнкыйди анализ ясаган, «Казан дәүләте — Алтын Урда кыйпылчыгы» дигән теорияне фаш иткән, әзлеклелек чылбырын Болгар—Алтын Урда—Казан ханлыгы «божра»сы аркылы уздырган, Казан белән Мәскәү арасындагы дәүләтара мөнәсәбәтләрне төрле этапларга бүлеп карауны асыл принципларның берсе итеп алган.

Мәскәү—Казан мөнәсәбәтләренең хәлиткеч механизмын ачып, Казанны яулау максатындагы сугышның башлануын галим 1545, ә аны алуга тәмам карар кылынуын 1549 елның язы белән бәйләгән, шул агрессив максатның тормышка ашырыла башлавын үтемле дәлилләр белән ныгыткан, Зөя кальгасын салу, Тау ягын буйсындыру хәлләрен бәйнә-бәйнә тасвирлаган, Казанны тыныч юл белән басып, Касыйм кебек урыс биләмәсенә әйләндерергә омтылышларга, бу мәсьәлә тирәсендәге сәяси-хәрби ыгы-зыгыга этрафлы тукталган.

Хезмәттә Казан иленең бәйсезлеге, иминлеге өчен канкойгыч, дәһшәтле сугыш бөтен нечкәлекләре белән тасвирланган, бабаларыбызның фидаилеге, илбасарлар белән җан аямыйча якалашуының барлык детальләре чагылыш тапкан. Әмма татар һәм әүвәлге ханлыкның башка халыклары әле Казан егылганнан соң да дәүләтне торгызу, үз бәйсезлекләре өчен алты ел дәвамында (1552-1557) фидакярләрчә көрәшәләр, каһарманлыкның гүзәл үрнәген күрсәтәләр. Автор хаклы рәвештә билгеләп үткәнчә, «Казанны байтак көннәр буена саклау, бәйсезлек өчен көрәш, дәүләтнең мөстәкыйльлеген торгызырга омтылыш бабаларыбызның какшамас рухын чагылдыра, без горурланырга хаклы һәм өлгә итәргә лаеклы бөек үрнәк булып тора».

Әйе, хезмәт документаль җирлектә язылуы, фәнни яктан дәлиллелеге, мәсьәләгә төрле яктан килүе җәһәтеннән уңай тәэсир калдыра. Шулай да үткәнебезнең иң мөһим чорына багышланган кызыклы һәм гыйбрәтле бу әсәр кимчелекләрдән дә хали түгел. Әйтик, галим аерым очракларда урыс елъязмаларына кирәгеннән артык ышаныч күрсәтеп куя сыман. Шуңа күрә Сафа Гәрәйгә, кырымлыларга, Гали Әкрамга һ.б. биргән бәяләрендә беркадәр шөбһәләнер урыннар бар. Урыс патшаларының яу чабуы кайбер җирләрдә мәскәүлеләр каланчасыннан торып язылган, дигәнрәк тәэсир калдыргалый, «басып алу» сүзе булмаса да, «кушып кую» кебек күптән тарих чүплегенә ташланырлык тәгъбирләр, кызганычка, китапта әле һаман да очрап куйгалый. 1552-1557 елгы каһарманнарча орышларның «Ватан сугышы» дәрәҗәсендә бәяләнмәве дә аяныч, әлбәттә.

Ләкин, тулаем алганда, әлеге китап — җөмһүриятебезнең иҗтимагый-гуманитар хәятында бер вакыйга, тарихыбызның тирән катламнарына үтеп керү юлында сизелерлек казаныш.

**Равил ӘМИРХАН,**
**тарих фәннәре кандидаты.**

# 25 август — җәлилчеләрне искә алу көне

— Мин җәлилчеләр турында тулырак мәгълүматны Ташкентта яшәгәндә ишеттем, — ди рәссам Рифкать Вахитов. — Алар хакында «Белем» җәмгыятендә журналист-галим Исхак Зәбиров сөйләде. Шунда мин аның белән танышып киттем. Үз чиратында ул мине Ватаннарына исән-имин кайткан җәлилчеләр — Рушад Хисаметдинов һәм Гарәф Фәхретдинов белән таныштырды. Без гаилә дуслары булып киттек. Аларның сәнгатькә гашыйк икәнен мәҗлесләрдә күрдем. Ә бит алар әсирлектә чакта Муса Җәлил оештырган концерт төркемендә булган. Рушад — пианинода, ә Гарәф баянда уйный. Икесе дә бик матур җырлый. Остаханәмдә җәлилчеләрне сурәткә төшергәндә, мин алардан бик күп җырлар ишеттем. Һәр икесенең рәсемен 70 нче елларда ясадым. Бу рәсемнәр хәзер Чаллы сәнгать училищесында саклана. Муса Җәлил рәсеме исә Казандагы остаханәмдә тора. Аның белән республика күргәзмәләрендә катнаштым.

Мөнәсәбәт

## 1. Русия Конституциясе конституционмы?

Сталин Конституциясендә дә, Брежневныкында да, милләтләрнең СССРдан аерылып чыгуларына кадәр үзбилгеләнүгә хокуклары турында формаль генә булса да, аерым маддә бар иде. Халыкта «Ельцин Конституциясе» дип ат алган соңгы Конституциядәге бу маддә шактый сыгылмалы итеп төзелгән. Анда Русиянең бөтенлеге нигездә Президент өстенә йөкләнә. Мәсьәләнең болай куелышы Русия Президентын барлык «энекәш»ләрнең (милли азчылыкларның) иң югары абзасы итеп таный. Һәм мондый шартларда Президентның яңа китабы «Минем сугышым» («Майн кампф») дип аталса, бер дә гаҗәпкә каласы юк.

Русиянең Ичкериягә коралды һөҗүме Русия Конституциясенә туры килми торган гамәл булды. Һәрхәлдә, Ельцинның 2166 нчы яшерен фәрманының законсыз булуы Рәсәйнең Конституцион суды протестында да ачык чагылды. Яшертенлеге һәм кансызлыгы ягыннан бу фәрман хәтта «Барбаросс» планыннан да калышмый торгандыр. Русиянең яңа Конституциясе илне нацменнар өчен конституцион төрмәгә әйләндерде дә куйды. Аның буенча, милли республикаларның суверенлашуы чыгып качуга исәпләнә. Нәтиҗәдә — башкаларга сабак булсын өчен — махсус урыс гаскәрләренең Ичкериядә кылган вәхшилекләре немец гаскәрләренең Бөек Ватан сугышындагы ерткычлыкларыннан күпкә узып китте. Әгәр дә Бөек Ватан сугышында берәр партизан отряды, Буденновскида Басаев отряды кебек, террор акты ясаган булса, Сталин аның җитәкчесенә бер генә түгел, берьюлы өч Алтын Йолдыз таккан булыр иде. Ә Мәскәү үз халкын һәм үз җирен яклап сугышкан һәм урыслар кырган гаиләсе өчен дә үч алган Басаевны бандит дип атый. Алай булгач, Бөек Ватан сугышы партизаннарына да шундый_ук ярлык тагып була торгандыр. Аларның да бит немецлар басып алган территориядәге һәрбер террор актыннан соң бер гөнаһсыз күпме кеше тоткыннар (заложник) хәлендә кала иде.

Коммунизм да, фашизм да үзләренең кансызлыклары ягыннан бер-берсенән калышмады. Ләкин фашизмның бер үзенчәлеге бар иде — ул дингә һәм хосусый милеккә ирек куйды, шуның белән үзен коммунизмга караганда көчсезрәк итте. Әгәр дә Гитлер үзенең дусты Сталинга хыянәт итмәгән булса, алар дөнья хакимлегенә бергә-бергә култыклашып барган булырлар иде. Кагыйдә буларак, мафия (тоталитаризм һәрвакыт мафиячел була һәм шунлыктан анда башка мафияләр булмый) хыянәтне гафу итми һәм шуңа күрә Сталин соңгы көннәренә кадәр Гитлерның көйгән сөякләрен «юып» утырды. Менә шул, әгәр Президент Ельцин «энекәш» халыкларны тотып тору өчен үз иленең ун меңнәрчә улларының гомерен бирергә әзер икән, теге вакытта аңа партбилетын чыгарып саласы юк иде, чөнки аның кансызлыгы нацистларныкыннан да, коммунистларныкыннан да берние белән дә аерылмый.

## 2. Балкан табышмагы

Берара вакыт элеккеге Югославиядәге Босния серблары җитәкчесе Родаван Караджичны күпләр аңлый алмыйча интекте. Үзара дошманлашып яшәгән көчләр инде күптән килештеләр. Ә ул һич тә килешергә теләми. Күрәсең, аңа Балкан халыкларының бер-берсен бугазлап бетерүләре кирәктер. Шулай да Караджич, Мәскәүгә килеп, Рәсәй Язучылар берлегеннән М.Шолохов исемендәге дәүләт бүләген алгач, бу табышмак чишелә башлады кебек. Ул шагыйрь кеше икән, күптән түгел генә аның шигырьләрен радиодан укыдылар. Мөселман дөньясына нәфрәт, христиан дөньясына мәдхия җырлана ул шигырьләрдә. Һәм Рәсәй җитәкчеләренең ни өчен сербларны шулай яклаулары аңлашыла бара. Тапшыру алдыннан әдипнең иҗат хыяллары тормышка ашуы турында да әйтергә онытмаганнар. Янәсе, ул хәзер Рәсәйдә дә шагыйрь буларак танылачак икән. Сүз уңаеннан шуны әйтеп үтәсем килә: Гитлер үзенең «Майн кампф» дигән мәшһүр явыз китабын инде яшь вакытта ук яза башлаган, әмма үз хыялын өлкән яшьтә генә тормышка ашыра алган. Яшьлектә Сталин да шагыйрь булган бит. Хәтта Берия дә шигырьләр китабы бастырып чыгарырга җыенган, диләр. Бу исемнәрне бер рәткә тезеп чыксаң, менә дигән юлбашчы шагыйрьләр исемлеге барлыкка килә.

Монда СССР Югары Советының элекке спикеры А.Лукьяновны да искә алып узмыйча булмый. Берничә ай буе «Матросская тишина»да ял иткән бу кеше Осенев псевдонимы белән саллы гына шигырьләр китабы нәшер итте. Күп кенә шагыйрьләр өчен мондый җыентык чыгару матур хыял гына булып кала. Хәзер Осенев-Лукьянов дигән шагыйрьне бөтен дөнья белә. Ул БДБдә явызлык империясен торгызу өчен теләсә кайсы вакытта гражданнар сугышын башлап җибәрергә әзер. Россиядә хөкүмәткә каршы үткәрелә торган бер генә форум да аңардан башка узмый. Юкса, шагыйрь кеше явыз булырга да тиеш түгел кебек.

Илдә кайчан да булса икътисади тотрыклылык урнашачагына өметләнү бик авыр. Ник дигәндә, Россия Федерациясенең Дәүләт Думасында ике кешенең берсе коммунист бит. Һәм аларның һәркайсы «никадәр начар, шуның кадәр яхшырак» дигән принцип буенча эш итә. Минем карашка, киләчәктә сайлаулар бюллетененә депутатлыкка кандидатның шигырь язуга сәләте булу-булмавы турындагы графа да кертергә кирәктер. Чөнки тарихи тәҗрибә күрсәткәнчә, шагыйрьләрдән беркайчан да яхшы җитәкчеләр чыкмый. Бер татар шагыйре дә юкка гына: «И Ходаем, хур итәргә теләмәсәң, шагыйрьләргә байлык бирмә, власть бирмә» дип юкка гына язмагандыр. Ә Осенев-Лукьянов кебек шагыйрьләр шундый куәтле атом-төш кораллары булган Рәсәйне инде күптән упкынга китереп җиткерерләр иде. Хәтта күз алдына да китерүе куркыныч. Бу мәсьәләдә атом-төш коралы булмаган кайнар Балкан ярымутравы һәм анда халыкларны болгатып ятучы шагыйрь Караджич кечкенә генә бер бетчә булып тоела.

**Локман ЗАКИР.**

Әхмәт РӘШИТ



Шагыйрь нечкәлек билгесе белән языла

## Мөһәҗирләр

Кирәк чакта гел-гел соңга калдык,
Кирәкмәгән мәлдә ашыктык;
Тәкъдирләргә ниләр язылса да,
Без тормышка мәңге гашыйктыр.

Гүзәллеген, камиллеген эзләп
Камиллеге качкан җиһанның
Кайсы кыйтгасына сугылмадык,
Урый-урый аның һәр ягын.

Иңгә сарган Гоби тузаннары,
Саванналар кергән йөрәккә;
«Сибелә чәчәк» җырын көйли-көйли,
Сибелгәнбез ерак-еракка.

Мөһәҗирлек мәллә канга сеңгән,
Ризык мәллә шулай йөртә?!
Ата-баба каберләрен сагынып
Уфтанабыз, шөкер, кич-иртә.

Ят итсә дә кайчак туган туфрак,
Ят итмәдек татар уйларын —
Амазонка ярларына барып,
Бәйрәм иттек Сабан туйларын.

Кайсы кыйтгаларга күз салсаң да,
Моңаеп һәм яшереп ярасын,
Күпме чит-ят кавем арасыннан
Карап торыр татар баласы.

Кая барсаң да бер кояш түгел,
Чәчәк үсмәсә дә юлында,
Солтан булмаса да, олтан булмас —
Татар өчен канун шул гына.

Кояшлардан ары кояшлар бар,
Туган илдән ары илләр бар,
Язмышларны сукбай дуңгәләктәй
Тәгәрәтеп йөрткән җилләр бар.

## Казан Кремле

Дамбадан барам. Каршымда —
Ярымай, тәре, йолдыз;
Өч символда — өч фәлсәфә,
Кайсы чит тә, кайсы үз.

Кайсына кемнәр табынган,
Табынган кайсы чордан?
Барыбер түгелмени, дип,
Манкортлар авыз ерган.

Казанның шанлы үткәне
Бүгенгә сыярмыни —
Шундый бит хәлләр, дип Кремль,
Әйтерсең, үрти мине.

Ә кайда таҗик чокыры
Һәм Колшәриф мәчете?
Юк иткән мәллә кимереп
Замананың ач эте?

Ә кайда безнең бабайлар
Калдырган асыл тарих?
Бик күпкә лаек идек бит —
Тагарак нигә ярык?

Сораулар күп — җаваплар юк,
Фаразлар — тоташ томан.
Үрдәге кальга үзе дә
Йоклаган хәтер сыман.

Гыйбрәтле безнең язмышлар,
Яралы үткәнебез;
Дәгъва итә мәңгелеккә
Ярымай, тәре, йолдыз...

## Исхакый китабы чыккач...

Киек казлар илгә кайта иде —
Каңгылдаулар күккә эленеп калды;
Офыкларга сары сагыш кунды —
Парә-парә бәгырь теленеп алды.

Югыйсә бит ул көн бәйрәм иде —
Рәнҗеп китми иде беркем илдән.
Җыелдык без ул көн дәррәү кубып
Очрашырга аның рухы белән,

Кемнәргәдер үпкә белдерергә
Милләт кальбендәге аһлар өчен;
Тәүбә итәргә дип үткәндәге
Дөньякүләм зур гөнаһлар өчен.

Казан суы кандай кызыл иде —
Таш байрактан төшкән шомлы шәүлә.
Ә без ихлас идек... сабыйларча...
Алдаса да заман, корып хәйлә.

Ябырылды халык китапларга —
(Зинданнардан чыккан «Зиндан» томы!)
Ниһаять, без... күпме гомердән соң
Кулга алдык бөек Исхакыйны.

Таныйк алдык, байрак итеп алдык —
Киләчәккә барыр юллар озын;
Дога итеп ятлар әле халык
Исхакыйның пәйгамбәрчә сүзен.

И, шатланды милләт, көлеп, елап,
Үзен шунда кеше итеп тойды.
Күпләп-күпләп алдык китапларны —
Кабат тыярлар, дип, Исхакыйны.

Мемориал — гомер булмаганны! —
Халык белән шыгрым тулы иде.
Җырлап-биеп бәйрәм иттек ул көн,
Сөенечтән йөрәк елый иде.

Газиз кешебезгә мөнбәр даулап,
Чор капкасын кага иде язлар...
Тантанада иде ул көн татар,
Илгә кайта иде... киек казлар.

## Милли хисләр

Тат та түгел, ар да түгел,
Милләтем аты — татар,
Шуның аркасында татыйм
Күпме әр һәм күпме зар.

Кирәксә, кирәкмәсә дә
Үткәннән берәр дәлил,
Яманлап безнең тарихны
«Фәнни эш» яза җаһил.

Югыйсә... нәсел-нәсәпләр
Юньле, дип, булсын бары,
Киленне алган татардан
Борынгы бабалары.

Кенәзе-фәлән дисеңме,
Я галим-голәмасы...
Актарып баксаң чын-чынлап,
Урыс соң аның кайсы?!

Ә тия җиде бабама,
Матлатып, кат-катлап
Йөртәсе иде мәртәтне
Шәҗәрәсен ятлатып.

Кирәксә асыл сыйфатлар
Кемнеңдер милләтенә,
Кызыга безнең татарның
Килеш вә килбәтенә.

Кызыга уңганлыгына,
Сүзендә торуына,
Кызыга батырлыгына,
Моңына, җыруына.

Бәс, шулай булгач, ис китми,
Сүзенә ятларның да,
Без җавап бирә белербез
Урысча матларына.

Дөмбәсләп өйрәтте дөнья
Сабагын яшәешнең.
Олылап язйык тарихка
Татарның гамәл-эшен.

«Азатлык» сүзе мәйданнар
Өстендә чыңлап тора;
Замана инде безнең дә
Уйларны тыңлап тора.

## Татарстан нинди ул?

Матурдан матур кем матур?
Газиз әнкәм матур.
Батырдан батыр кем батыр?
Газиз әткәм батыр.

Татлыдан татлы ни татлы?
Туган телем татлы.
Затлыдан затлы ни затлы?
Динем, йолам затлы.

Моңлыдан моңлы ни моңлы?
Халкым җыры моңлы;
Әткәм-әнкәм телендә ул
Васыять булып чыңлый.

Алкыннан алкын ни алкын?
Идел суы алкын.
Якыннан якын ни якын?
Газиз туфрак якын.

Шушы туфракта бабайлар
Безгә Ватан тоткан,
Иген иккән, мал караган,
Күмәк учак яккан.

Дошман килсә ил яуларга,
Илдә батыр булган.
Матурлыкта ярышырга
Илдә матур булган.

Җире-суы бәрәкәтле,
Матур анда һәр таң.
Шушы җирдә чәчәк атсын
Азат Татарстан.

## *Якты яз фасылы һәм олуг Богра ханга мәдхия*

63. Исә башлады шәрекътан яз җиле,
Ачты җиһанга бизәк, оҗмах юлы.

64. Хуш исләр тулды җиргә, кафур* китеп,
Бизәнмәк теләр дөнья матур итеп.

65. Җәфалы кышны язгы җилләр сөрде,
Нурлы яз янә үз дәүләтен корды.

66. Кояш та әйләнеп кайтты урнына:
Балык койрыгыннан — бәрән борнына.

67. Корыган агачлар яшелдән киенде,
Ал, кызыл, сары төсләргә тиенде.

68. Яшел ефәккә төренде җир өсте —
Кытай кәрваны белән килгән төсле.

69. Дала, тау, кыр бөркәнде яшел шәлне,
Җиргә аллы-гөлле түшәк түшәлде.

70. Мең төрле чәчәкләр ачылды көлеп,
Җафар исләре берлә дөнья тулып.

71. Саба җилләре куйды шунда исеп,
Таратып җиһанга канәфер исен.

72. Каз-үрдәкләр, аккошлар шатланыша,
Каңгылдашып югары-түбән оча.

73. Кайсы —төшеп кунар, күр, кайсы — очар,
Кайсысы — йөзәр, күр, кайсы — су эчәр.

74. Күкләрне яңрата торналар таушы,
Тезелешеп очканда, каңгылдашып.

75. Кыр тавыгы оп салды, дәшеп парын,
Сылу кыз чакырган күк сөйгән ярын.

76. Хахылдап көлеп куйды ләкләк кошы —
Кызыл авызы — кан күк, кап-кара кашы.

77. Кара чыпчык чутылдата томшыгын,
Өне назлы кыз өненә охшаган.

78. Чәчәклектән сандугач салыр өнен,
Укыр Әбре сүрәсен көн һәм төнен.

79. Кыр кәҗәләре уйнап чабышалар,
Парлашып, берсен-берсе табышалар.

80. Каш җыерды күк — күзеннән яшь акты.
Елмаеп, гөлләр бер-беренә бакты.

81. Бу вакыт җиһан үз-үзенә багар,
Куанып-сөенеп, байлыгын барлар.

82. Күз атып мица, ачар дөнья сүзен.
Әйтер: күрмәдеңме бу Хакан** йөзен?

83. Әгәр йоклаган булсаң, тор, ач күзең,
Ишетми калган булсаң, ишет сүзем.

84. Йөз ел инде сулган йөзле тол идем,
Тол тунын салып, асыл күлмәк кидем.

85. Бизәндем — бәгем олуг хан булганга,
Кабул кылса, җаным фидадыр аңа.

86. Күк күкрәде — орды хан барабаны,
Яшьнәде яшен — гүя хан байрагы.

87. Берсе чыкса кыннан — күрсәтер кодрәт,
Берсе — таратыр дөньяга шан-шөһрәт.

88. Бу заманда җиһан тотты Богра хан.
Ике дөньяда да алсын шөһрәт-дан.

89. Әй, дип гыйззәте — таяныч дәүләткә,
Милләткә таҗ ул, терәк — шәригатькә.

90. Кабул булды барча теләгән теләк,
Бирсен Хода сиңа мең дә бер теләк.

**Җиде буын ядкаре**

**Йосыф хас-Хаҗиб БАЛАСАГУНЛЫ:**

# МИНЕМ БҮЛӘГЕМДЕР — «КОТАДГУ БЕЛЕК»

*«Мәдәни җомга»ны укып баручы хөрмәтле дусларым! Мин сезнең игътибарга моннан мең ел чамасы элек язылган борынгы төрки мирасыбыз — атаклы Йосыф хас-Хаҗиб Баласагунлының «Котадгу белек» исемле мәшһүр әсәреннән бер бүлекне уйгур теленнән тәрҗемә кылып тәкъдим итәргә булдым. Бу китап «Бәхетле булу белеме» дигәнне аңлата. Шул ук вакытта мин аны патшалар, ханнар китабы, дип тә әйтер идем. Чөнки ул нәкъ менә патша-ханнарга мәдхия вә киңәшләр, гыйбрәтләр рәвешендә язылган.*

*Бу көннәрдә Татарстанның мөстәкыйльлеге турындагы Декларация кабул ителүгә биш ел тулу бәйрәм төсендә билгеләп үтелә. Шушы кыска гына вакыт эчендә җөмһүриятебез күпмедер уңышларга ирешкән икән, аларда Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиевнең дә өлеше зур. Һәм мин бу тәрҗемә – хезмәтемне дә Президентыбызга багышлыйм. Ошбу зирәк һәм хикмәтле әсәрдән бер өзек аңа халкыбыз исеменнән ирештерелгән бәйрәм котлавы булсын!*

***Ихтирам белән, Лена ШАГЫЙРЬҖАН.***

91. Әй, дөньяның күрке — олуглык нуры,
Әй, муллык нурыдыр — бәхет чылбыры.

92. Заман бирде сиңа дәүләт вә тәхет.
Тота күрсен Тәңре тәхетеңдә бәхет.

93. Дөнья тынды, менгәч хакан тәхтенә,
Дөнья сузды бүләк — хакан бәхтенә.

94. Очып килгән җәннәт кошлары сайрый,
Кайсы — һинди шунда,
кайсы — Кайсари.***

95. Сыздыралар берсен-берсе уздырып,
Куанышып, үзәкләрне өздереп.

96. Тау битләре, үзән-кырлар һәм дала
Шау чәчәккә баткан — гүзәл манзара.

97. Кайсы — йөзе берлә көнгә табыныр,
Кайсы — гүзәл манзарага багыныр.

98. Кайсы — кулларны сузып торыр ханга,
Кайсы — хуш ис аңкытыр киң җиһанга.

99. Кайсы — көнчыгыштан сузар мең бүләк,
Кайсы — көнбатыштан, бульшмак теләп.

100. Бәхет кошы капкага кунган хәзер.
Капкага кунганы — хезмәткә әзер.

101. Буйсынды аңа, язның бар дошманы,
Үтәп торды аның һәрбер кушканын.

102. Хаканның данын бөтен дөнья күрде.
Йокы качкан күзләргә йокы керде.

103. Төзәлде кануннар, тын алды җиһан,
Канун белән дан казанды ошбу хан.

104. Кем ни күрмәгән булса юмарт йөзен,
Килеп күрсен хакан йөзенең үзен.

105. Җәфасыз тормышны теләгән кешең,
Йөзен күрсен ханның, вафалы эшен.

106. Зарарсыз мәнфәгать күрим дисәң, гәр,
Бире кил, табын, күңел бир син аңар.

107. Холкы сабыр, күңле киң, мәрхәмәтле.
Күрим дисәң, килеп күр син бу ханны.

108. Әй, саф ыруг, затлы орлык, пакь нәсел,
Дөнья синнән коры кала күрмәсен!

109. Хода бирде сиңа бәхетнең чынын,
Мең догалар кыл аңа, әй, лачыным!

110. Иске сүз бар — мәсәлләрдән укылган:
Ата урыны, аты калыр угылга.

111. Аты калды, урыны сиңа — атаңның.
Арта барсын мең-мең тапкыр шул даның.

112. Зур бүләкләр суздылар сиңа килеп,
Минем бүләгемдер — «Котадгу белек».

113. Аларның бүләге килер дә китәр,
Минем бу бүләгем мәңгегә җитәр.

114. Җыйган дөнья байлыклары таралыр,
Язылган сүз җиһанда мәңге калыр.

115. Китапка бу ханның исемен беркеттем,
Бу ат мәңге калыр җирдә, бөркетем!

116. Йа, раббым, арттыр дәүләтен — шул теләк,
Барча эштә бул аңа арка-терәк.

117. Дусларын исән тот, күз-яшь түкмәсен,
Сөенечләрен тулы тот — кот китмәсен.

118. Явып торсын яңгыр, чәчәк язылсын,
Корыган агачларда бөре ачылсын.

119. Вакыт тәгәрмәче әйләнеп торсын,
Дошман башы түбән иелеп торсын, —

120. Коңгырт җир, бакыр күк кызыл булганчы,****
Йә уттан яшел гөл шытып чыкканчы.

121. Мәңге яшә, бәхетле бул, әй, лачын!
Хөсетленең күзе вә эче янсын.

122. Тагы да булсын сиңа шул изге догам:
Калам җирдә теләп мәңгелек дәвам.

123. Хозур торсын мәңгегә бу Хан җире,
Яшәсен вә яшьнәсен Локман иле!!

..................................

* Кафур — ак төстәге төелмә (порошок) карның метафорасы.

** Хакан — хан.

*** Кайсари — Һиндстандагы төбәк (ходай кошы, асыл кош мәгънәсендә).

**** Кыяматкә кадәр дигән мәгънәне аңлата.

## ДҮШӘМБЕ

### 28 АВГУСТ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 19.20 Мультфильм: «Остров сокровищ». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». Тапшыру анонслары. 19.40 «Түгәрәк өстәл». 20.20 «Әлли-бәлли-бәү». 20.30 «Осталык». Бөтенроссия машина белән сыер саву конкурсыннан репортаж. 21.00 «Мәрәтхуҗа малае». Язучы Туфан Миңнуллин турында документаль фильм. 21.30 Эстрада концерты. 21.55 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Ограбление по...» 7.30 «КиноМеню». 8.00, 10.50, 0.15 — «Юл патруле». 8.10, 11.30 — «Даруханә». 9.15, 13.35 — «90х60х90». 9.30 Мультсериал: «Еноты». 9.55 Нәфис фильм: «Старая крепость». 11.05 Сәбәпсез спорт. 11.45, 23.55 — «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.05 Нәфис фильм: «Рожденная революцией». 5 нче серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 Атна һәлакәтләре. 15.05 «Фитиль». 15.15 Нәфис фильм: «Последняя жертва». 17.00 «Минем йолдыз». Ирина Аллегрова. 17.30 Нәфис фильм: «Осенний марафон». 19.15, 23.45 — «Эфирда — музыка». 19.25 «Башлык» акционерлар җәмгыяте тәкъдим итә. 19.35 «Видеомода». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 23.20 — «Шәһәр» информацион программасы. 20.45 «Телеэкспресс». 21.10 «Мөстәкыйльлек: яшәргә күнеллерәк». 21.35 Нәфис фильм: «Вкус» (Австралия). 1 нче кисәк. 0.25 Европадан — 20.

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.35 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Могҗизалар кыры». 11.00 «Кеше һәм закон». 11.25 Мультфильм: «Сова». 11.35 «Ел әйләнәсендә — яшелчә бакчасы». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Нәфис фильм: «В моей смерти прошу винить Клаву К.» 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның жиде көне». 16.00 Мультсериал: «Отверженные». 16.25 «Йолдызлар сәгате». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр сериалы: «Элен и ребята». 17.30 «Ышаныч» телевидениесе. 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.00 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Әгәр». В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.50 Тапшырулар программасы. 21.55 Телесериал: «Таверна «Ямайка» (Бөекбритания). Соңгы серия. 22.50 «Юрамалар». 23.10 «Футбол күзәтү». 23.40 «Россия алтыны».

#### «РОССИЯ»

7.30 Эшлекле кешеләр вакыты. 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 Клип-антракт. Н.Ветлицкая. 9.00 Өй экраны. Нәфис фильм: «Она выбирает романтику» (АКШ). 10.35 Документаль фильм: «Успение Пресвятой Богородицы». 10.55 Телегазета. 11.05 «Самолетлар... канаты астында». Авиасалон-95. 11.20 Милиция хроникасы. 11.30 Музыкаль экспромт. 11.45 Ура, каникуллар! Мультсериал: «Мечи свободы. Поход каталонцев» (АКШ). 12.15, 17.20 — «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 Мульти-пульти: «Медвежонок Римцимци», «Сундук». 17.50 «Алыргамы — алмаскамы». 18.00 Сезне «Савва» фирмасы чакыра. 18.15 «Коткару-911». 19.10 Р.В.Фассбиндер. «Кино тормыштан олырак». 19.25 «Сабый авызыннан». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Дүшәмбе саен детектив. «Инспектор Морс» сериалыннан нәфис фильм: «Обманный удар» (Бөекбритания). 21.40 Репортер. 22.00 «Бизәүсез». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Төнге телесериал. Нәфис фильм: «Берлин, Александрплатц».

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». 11.15 «Коллекционерлар». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15 Телефильм: «Натюрморт с лишними предметами». 13.45, 15.40, 19.00 — «Музыка мизгеле». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30, 19.55 — Телефильм: «Мануэла». 122 нче серия. 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 19.30, 22,40 — «ТВ мәгълүматлары». 15.45 Безнең кино. Нәфис фильм: «Житие Александра Невского». 17.05 Музыкаль телефильм: «Агриппина Ваганова». 18.10 Мультфильм: «Самый уважаемый». 18.20 «Әкият арты әкият». «Соловей». 19.05 «Телеблиц». 19.10 Мультфильм: «Кладезь мудрости». 19.48 Спорт яңалыклары. 20.40 «Иминлек телехезмәте». 20.50 «Шәһәр эшләре». 21.05 Нәфис фильм: «Человек, который не хотел умирать» (Италия). 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Парадлар парады». Музыкаль-шоу.

## СИШӘМБЕ

### 29 АВГУСТ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.00 Н.Дәүли. «Җырлап узган җәй». Курчак театры спектакле. 18.45 «Тукталыш». 3 нче тапшыру. 19.00 «Татарстан». 19.30 Татарстан Республикасының дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул итүгә 5 ел тулуга багышланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Дәүләт Советының берләштерелгән тантаналы җыелышы. Ахырдан сәнгать осталары концерты.

#### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7.10 Мультфильм: «Фильм, фильм, фильм...» 7.30, 20.20, 23.05 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (28 август тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (МТЖ). 8.55, 13.35 — «90х60х90». 9.10 Мультсериал: «Еноты». 9.30 Нәфис фильм: «Старая крепость». 3 нче серия. 10.45, 0.05 — «Юл патруле». 11.00 Атналык фаразлар. 11.30 «Даруханә». 11.45, 23.45 — «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 12.05 Нәфис фильм: «Рожденная революцией». 6 нчы серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Минем кино». Валерий Тодоровский. 15.05 «Музыка һәм матбугат». «Каләм осталары» — «Мегаполис» группасы. 15.55 Театраль хроника. Кече театр спектакле: «Ярмарка тщеславия». 18.30 Мультфильм: «Легенда о Григе». 18.30 «Кыюлар һәм матурлар». 19.20 Декларация кабул итүгә 5 ел: нәтиҗәләр һәм киләчәк. Президент М.Ш.Шәймиев белән әңгәмә. 20.40 «Спорт-ревю». 20.55 «Телеэкспресс». 21.15 «Коммерция әйләнмәсе». 21.40 Нәфис

# АТНАЛЫК МАНЗАРА TV

фильм: «Вкус». 2 нче кисәк. 23.30 «Эфирда — музыка». 0.15 «Альтернатива» (МТЖ).

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 1.00 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Исемнәрегез нәрсә аңлата». 11.25 Хайваннар дөньясында. 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Большая перемена». 14.05 Мультсериал: «КОАПП». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның жиде көне». 16.00 «Кара, тыңла». 16.20 «Тутый кош артыннан». 16.40 «Марафон-15». 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Джем». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 «Беренче куллардан». 22.05 Алексей Баталов «Дело Румянцева» фильмында. 23.55 «Юрамалар». 0.10 «Останкино» хит-парады.

#### «РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 10.55 «Телегазета». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 Документаль фильм: «Остров». 11.40 «Карарга ашыгыгыз!» Мультфильм: «Оловянный солдатик» (Канада). 12.05 Клип-антракт. Линда. 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Рост» студиясе. 16.45 «Беркем дә онытылмаган». 16.50 «Ай тотучы». 17.20 «Яңа тармак». «Нижнийдан карагaнда». 17.50 Музыкаль программа: «Без хушлашабыз...» 17.20 Әдәби-публицистик цикл премьерасы: «Россия. Мәхәббәттә аңлашу». 18.55 Популяр булмаган тема. 19.10 «L» клубы. 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телеэкран премьерасы. О.Иоселиани фильмы: «Охота на бабочек». 22.40 Криминаль хәбәрләр экраны. 22.40 Клип-антракт. В.Цыганова. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Төнге телесериал. Нәфис фильм: «Берлин. Александрплатц» (ФРГ).

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 10.00 «Төш юрау». 10.45 «Кумирлар». 11.15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15 «Әкият арты әкият». 13.50, 15.40, 19.00 — «Музыка мизгеле». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30, 19.55 — Телефильм: «Мануэла». 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 19.30, 22.40 — «ТВ мәгълүматлары». 15.45 «Көз» киноканалы. Нәфис фильм: «Два долгих гудка в тумане». 17.10 В.Виноградов фильмы: «Метро, метро» (Лентелефильм, 1977). 17.35 «Бөтен Россия буйлап». 17.45 Авыл хуҗалыгы. «Ычкындырылган мөмкинлекләр». 18.15 «Троицк күпере». 18.25 3 нче теле-рок-фестиваль: «Күгәргән үткәргечләр». 1 нче кисәк. 19.05 «Телеблиц». 19.10 Фәнни-популяр телефильм: «Телескопы». 1 нче фильм. 19.48 Спорт яңалыклары. 20.45 «Иминлек телехезмәте». 21.05 «Телисеңме? Кара...» Юмористик программа. 21.50 «Кичегезне бүләк итегез». Евгений Кемеровский. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Г.Ибсен. Телеспектакль: «Привидения». Режиссер Ю.Маляцкий.

## ЧӘРШӘМБЕ

### 30 АВГУСТ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. Программада — Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевнең Республиканың туган көне белән котлавы. 18.00 Мультфильмнар. 18.35 «Без бит бергә — шунысы шатлык». «Айгөл» балалар вокаль ансамбле башкара. Чаллы шәһәре. 19.00 Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевнең Республиканың туган көне белән котлавы. 19.15 «Татарстан». 19.40 Мөстәкыйльлек: кичә, бүген, иртәгә. 20.10 «Әлли-бәлли-бәү». 20.20 «Бәйрәм белән, дуслар!» Публицистик-музыкаль программа. 22.55 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Лабиринт». 7.30, 20.20, 23.15 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (29 август тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (МТЖ). 9.10, 13.35 — «90х60х90». 9.25 Мультсериал: «Еноты». 9.50 Нәфис фильм: «Старая крепость». 4 нче серия. 11.00, 0.05 — «Юл патруле». 11.15 «Атна низаглары». 11.40 «Даруханә». 11.55, 23.45 — «ПОСТ» — музыка яңалыклары». 15.15 Нәфис фильм: «Рожденная революцией». 7 нче серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Минем йолдыз». Ирина Аллегрова. 15.05 Нәфис фильм: «Стиви», 17.00 Рей Бредбери: «Һәм күк күкрәде». 17.25 Детектив сериал: «Таггерт». 18.20 Нәфис фильм: «Четыре сезона шампанского». 18.50 «Эфирда — музыка». 18.55 «Бәхетле балачак» ансамбле концерты. 19.25 «Поза». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 «Enter club». 21.35 «Туган көнең белән, республика!» Казан мэры К.Ш.Исхаков чыгышы. 21.45 Фантастик боевик: «Абраксас — хранитель Вселенной» (АКШ). 0.15 «Хит-лист Королевства».

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.40 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Тема». 10.50 «Ак попугай» клубы. 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Большая перемена». 2 нче серия. 14.05 «Мультсериал: «КОАПП». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның жиде көне». 16.00 «Күңелле ноталар». 16.20 «Ник һәм нигә?» 16.50 «Фэн-клуб». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.30 «Тин-тоник». 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 Суперфутбол. Чемпионнар лигасы матчлары. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Клаудиа Карденале «Либера, любовь моя» фильмында. 23.55 «Юрамалар». 0.15«Паузасыз».

#### «РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Төп мизгел». 9.05 XX гасыр кадрда һәм кадр артында. «Когда-нибудь мы вспомним это...» 9.50 Өй экраны. Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 Милиция хроникасы. 11.15 «Балетның тылсымлы дөньясы». Ю.Махалина. 12.10 Клип-антракт. 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Кем ягы?» 17.20 «Яңа тармак». Ерак Көнчыгыш. 17.50 Телегазета. 17.55 Документаль фильм: «Але, привет...» 18.15 Губернаторлар клубы. 18.15, 20.35 — Футбол. Россия чемпионаты. «Спартак» (Мәскәү) — «Динамо» (Мәскәү). 1 нче һәм 2 нче таймнар. «Лужники» стадионыннан трансляция. 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 21.30 «Үз уены». 22.00 Өй экраны. «Телесериал: «Санта-Барбара». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 Экранда — «Дебют». Кыска метражлы нәфис фильмнар: «Неизвестная», «Мой бедный Пьеро».

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 Балалар өчен. 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Такмаклар». 11.15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00 «ТВ — мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15 Мультфильм: «Кладезь мудрости». 13.30 Телефильм: «Петровский портрет». 13.45, 15.40, 19.00 — «Музыка мизгеле». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30, 19.55 — Телефильм: «Мануэла». 124 нче серия. 15.20 Бакчачыларга киңәшләр. 15.30, 19.30, 22.40 — «ТВ — мәгълүматлары». 15.45 Г.Ибсен. Телеспектакль: «Привидения». Режиссер Ю.Маляцкий. 17.30 Хатирәләребез җырлары. 17.45 «Гыйбадәтханә». 18.15 Р.Глиэр. Романслар. Россиянең халык артисткасы Евгения Алтухова башкара. 18.25 3 нче теле-рок-фестиваль. «Күгәргән үткәргечләр» 2 нче кисәк. 19.05 Телеблиц. 19.10 Фәнни-популяр телефильм: «Телескопы». 2 нче фильм. 19.48 Спорт яңалыклары. 20.45 Иминлек телехезмәте. 21.00 Футбол. ФИФА җыелма командасы — дөнья җыелма командасы. Кобе (Япония) шәһәреннән трансляция. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Блеф-клуб». 23.45 О.Ерышев фильмнары. «Все, что на сердце у меня» (Лентелефильм, 1978).

## ПӘНҖЕШӘМБЕ

### 31 АВГУСТ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.25 Балалар өчен концерт. 18.50 «ГАИ» мәгълүматлары. 19.00 «Татарстан». 19.30 «Хөкүмәт сәгате». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 «Хатирәләр...» Октябрь районының Колбай Мораса мәктәбенә 400 ел. 20.45 Татарстан Республикасының дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул итүгә 5 ел тулуга багышланган халыкара спорт фестивалендә.

#### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Прометей». 7.30, 20.20, 0.00 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (30 август тапшыруын кабатлау). 8.20 «Сул аяктан!» (МТЖ). 8.50, 13.35 — «90х60х90». 9.15 Мультсериал: «Еноты». 9.30 Нәфис фильм: «Старая крепость». 5 нче серия. 10.40 «Юл патруле». 10.55 CNN. «Стиль». 11.20 «Даруханә». 11.30 «ПОСТ» — музыка яңалыклары. 11.55 Нәфис фильм: «Рожденная революцией». 8 нче серия. 13.50 «Валюта бәясе». 14.00 Яңа уку елы башлануга багышланган телемарафон. 15.05 «Көнгер боз мәгарәсе». 15.20 «Барысын да белергә телим». 15.30 Мультфильмнар: «Малыш и Карлсон», «Ванюша и великан». 16.00 «Ток-шоу». «Мин үзем». «Хатын-кыз руль артында». 16.55 Нәфис фильм: «Мелочи жизни». 18.10 Сериал: «Таггерт». 18.45, 21.05 — «Эфирда — музыка». 18.50 «Видеогид». 19.10 «Минем пейджерым бар. Һәм мин тыныч!» 19.15 «Коммерция әйләнмәсе». 19.40 «Кыюлар һәм матурлар». 21.10 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә. 20.45 «Телеэкспресс». 21.15 «Турыдан-туры элемтә». Студиядә Казан мэры К.Ш.Исхаков. Тема: «Шәһәр сәүдә челтәре эше». 22.20 Атна фильмы: «Все золото мира» (Франция). 0.25 «Red Wave» тәкъдим итә. Jot Shout.

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00 — «Яңалыклар». 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Золушкада балда». Уку елы башлануга карата тапшыру. 10.35 Телеуен: «Мине аңла». 10.50 «Сәяхәтчеләр клубы». 12.20 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Большая перемена». 3 нче серия. 14.05 Мультсериал: «КОАПП». 14.00 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидров...» 15.20 «Спортның жиде көне». 16.00 Мультитроллия. 16.20 «Яшь талантлар конкурсы». 16.40 «Компьютер-холл». 17.00 Кыска яңалыклар. 17.05 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята». 17.30 «16 яшькә кадәр һәм өлкәнрәкләр...» 18.00, 21.00 — «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 «Лотто-миллион». 20.00 «Көмеш шар». А.Годунов, В.Вульф алып бара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 «Мәскәү-Кремль». 22.15 Тарихи боевик: «Колонна».

#### «РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Төп мизгел». 9.05 Антреприза». 9.50 Өй экраны. Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Беркем дә онытылмаган». 11.10 «Милиция хроникасы». 11.20 Телегазета. 11.25 Безнең хәбәрчедән. «Базар ябылган чакта». 11.45, 17.50 — «Карарга ашыгыгыз!». Мультсериал: «Камень сновидений» (Бөекбритания). 12.10 Клип-антракт. 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Өмет стартлары». 17.20 «Яңа тармак». Бишкек. 18.15 Клип-антракт. С.Лазарева. 18.20 «Җиңү адымнары» телемарафоны. Сталинград реквиемы. 19.15 «Сезнең партнер». «Россиянең тимер юллары». 19.20 «Алты сутый». 19.40 «Кайнар унлык». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Өй экраны. Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Әйдәп баручы фаразы». 22.00 Клип-антракт. А.Буйнов. 22.05 «Ике катлы портрет». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 «Хроно». Авто һәм мотоспорт дөньясында. 0.15 Криминаль хәбәрләр экраны.

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 8.15 «Әдәплелек». 8.45 «Оборона». 10.15 Төш юрау. 11.15 «Аукцион». 12.15 «Спартак». 12.40 «Кунак». 13.30 «ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны». 13.15 Р.Глиэр. Романслар. Россиянең халык артисткасы Евгения Алтухова башкара. 13.25 Телефильм: «Сорок первый — наш год призывной». 13.55, 15.40, 19.00 — «Музыка мизгеле». 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.00, 19.55 — Телесериал: «Мануэла». 125 нче серия. 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 19.30, 22.40 — «ТВ мәгълүматлары». 15.45 Кино йорты. Отар Иоселиани: «Кино турында гына түгел». 16.45 Телефильм-концерт: «И снова музыка». 17.25 Телемарафон. Мәскәүдән тапшыру. 18.25 3 нче теле-рок-фестиваль. «Күгәргән үткәргечләр». 3 нче кисәк. 19.05 «Телеблиц». 19.10 Фәнни-популяр телефильм: «Телескопы». 3 нче фильм. 19.20 «Бөтен Россия буйлап». 19.48 «Спорт яңалыклары». 20.45 «Иминлек телехезмәте». 21.00 Ура, комедия! Нәфис фильм: «Таксист в Нью-Йорке». 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 «Наубом: Галина Мезенцева». 23.25 Гармония яратучылар. Санкт-Петербург филармониясе җәмгыяте.

## ҖОМГА

### 1 СЕНТЯБРЬ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 17.25 Балалар өчен «Тамчы». 17.40 Балаларга фильм: «Внимание, черепаха». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Видеоспорт». 19.45 «ТАТЕХ -- уңышны тәкъдир итү». Нефть табу һәм тирә-юнь мохитне саклау буенча уртак Русия—Америка предприятиесе коллективының яңа шартларда эшләве турында. 20.05 «Әлли-бәлли-бәү». 20.15 «Ислам чакыруы». 20.25 «Җомга көн кич белән». Альманах. 21.25 Клара Хәйретдинова җырлый. 21.55 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 Мультфильм: «Кошкин дом». 7.30, 20.20, 22.05 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 «Турыдан-туры элемтә» (31 август тапшыруын кабатлау). 9.00 «Телеэкспресс» (31 август тапшыруын кабатлау). 9.20 Мультсериал: «Еноты». 9.45 Нәфис фильм: «Старая крепость». 6 нчы серия. 10.55, 18.40 Юл патруле. 11.05 «Атнага бер тапкыр» юмористик программасы. 11.35 «Даруханә». 11.50, 18.20 ПОСТ — музыка яңалыклары. 12.10 Нәфис фильм: «Рожденная революцией». 9 нчы серия. 13.35 «90х60х90». 13.50 Валюта бәясе. 14.00 CNN. Бизнес яңалыклары. 14.30 «Нью-Йорк, Нью-Йорк». 15.05 Нәфис фильм: «Верхом на смерче». 16.35 «Кешеләр дөньясында». Эдуард Сагалаев программасы. 17.20 «Таггерт». 3 нче серия. 18.50 «На грани» (МТЖ). 19.30 «Суперспорт». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 Телеэкспресс. 21.05 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.30 Детектив: «Бег зайца по полям». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 1.05 Нәфис фильм: «Эммануэль-2: антидевственница».

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 «Иртә». 9.00, 12.00, 15.00, 0.55 -- Яңалыклар. 9.20 Телесериал: «Тропиканка». 10.10 «Көмеш шар». А.Годунов. Тапшыруны В.Вульф алып бара. 10.50 «Иртәнге йолдыз». 11.35 Телеуен: «Мине аңла». 12.20 Эфирда -- «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 13.00 Телесериал: «Большая перемена». 4 нче серия. 14.10 «Экслибрис». 14.20 Информацион-күңел ачу программасы: «Иванов, Петров, Сидоров...» 15.20 «Спортның җиде көне». 16.00 «Сәлам, укучылар!» 16.10 Балалар өчен телесериал: «Белый клык». 16.35 «Яңа чынбарлык». 17.00 «Шпаргалка». 17.05 «Рок-дәрес». 18.00, 21.00 -- «Вакыт». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Кыргый кыр». 19.25 «Кеше һәм закон». 19.55 «Могҗизалар кыры». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Телесериал: «Гиганты второй мировой». 1 нче серия. 22.55 «Юрамалар». 23.15 «Караш». 0.10 Музыкаль күзәтү.

#### «РОССИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Кирәк... кирәк...» 8.55 «Үтә яшерен». 9.45 «Телегазета». 9.50 Телесериал: «Санта-Барбара». 10.40 «Крестьян мәсьәләсе». 11.05 «Милиция хроникасы». 11.15 Документаль фильм: «Отечество нам -- Царское село». 11.35 «Ле Монти» сәүдә йорты. 11.50 Карарга ашыгыгыз! Мультфильм: «Соловей» (Канада). 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 -- «Эшлекле Россия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Онытылган көн». 16.50 «Ай тотучы». 17.20 Яңа тармак. «Тиздән мәктәптә үзең белерсең...» 17.50 Җомга саен Дисней. Нәфис фильм: «Свет в лесу». 19.25 Вертикаль. «Хөкүмәтнең эш көннәре». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Рек-тайм». 22.05 «К-2» күрсәтә: Василий Лановой «Ию» программасында. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.45 Төнге сеанс. П.Манфреди Э.Сколның «Страшные, грязные, злые» фильмында.

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 «Тәҗрибә». 8.15 «Киңәшче». 8.45 «Балалар өчен». 9.20 «Гүзәллек». 10.15 «Төш юрау». 10.40 «Кумирлар». 10.45 Такмаклар. 11.15 «Коллекционерлар». 12.10 Джаз. 12.40 «Кунак». 13.00 ТВ мәгълүматлары — немец дулкыны. 13.30 Телефильм: «Пластилин». 14.05 «Ашыгыч ярдәм». 14.30, 19.55 Күп серияле нәфис телефильм премьерасы: «Мануэла» (Италия). 126 нчы серия. 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр». 15.30, 19.30, 22.40 ТВ мәгълүматлары. 15.40. 20.55 Музыка мизгеле. 15.45 Ура, комедия! Нәфис фильм: «Таксист в Нью-Йорке». 17.15 Документаль фильм: «Южная Африка: природа в наследство». 17.25, 19.30, 22.40 ТВ мәгълүматлары. Европа калейдоскобы. 17.55 «Борылып кара һәм уйла». 18.30 «Яңа ел телевизион такылдыклары». 18.45 «Иң кечкенә йолдызчыклар». 18.55 «Телеблиц». 19.15 «Зур фестиваль». 19.48 Спорт яңалыклары. 20.45 Иминлек телехезмәте. 21.00 Фильмоскоп. Нәфис фильм: «Ариэль». 22.20 «Бәллүр ачкыч». Музыкаль клиплар фестивале. 22.55 «Спорт, спорт, спорт...» 23.10 Чит ил киносы антологиясе. Нәфис фильм: «Орел в клетке» (Бөекбритания).

## ШИМБӘ

### 2 СЕНТЯБРЬ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00- 8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.15 «Мин зур үскәч...» Ирина Болтикова. 18.30 Мультфильмнар. 19.00 «Татарстан». 19.30 «7 нче стиль». 20.00 «Әлли-бәлли-бәү». 20.10 Тамашачылар соравы буенча. Нәфис фильм: «Волга-Волга». 21.50 Динарт Закиров җырлый. 21.05 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

7.00 Эфирда -- музыка. 7.30 «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (1 сентябрь тапшыруын кабатлау). 8.10 «Коммерция әйләнмәсе» (29 август көнендәге тапшыруны кабатлау). 8.35 «Спорт-ревю». 8.45 «Дублик-бублик». 9.10 «700 нче клуб: җаваплар». 9.40 Мультсериал: «Д'Артаньгав и три пса-мушкетера». 10.10 Нәфис фильм: «Там, на неведомых дорожках». 11.20 «Чаплиниада». «Хатын-кыз». 11.45 Хәрби телевидение. 12.20 «Сәбәпсез спорт». 12.50 «Следствие ведут знатоки». 1 нче, 2 нче серияләр. 14.30 Нәфис фильм: «Розовая Чекита». 16.25 Телесериал: «Тропическая жара». 17.20 Телесериал: «Детективы на полставки». 18.15 Балалар өчен маҗаралы сериал: «Секретная миссия». 18.40 Көлкеле тапшыру: «Замочная скважина». 19.00 «Исәнмесез!». 21.00 «Мавыгулар дөньясы». 21.30 Сериал: «Сирены» (АКШ). 22.30 Red Wave тәкъдим итә: Джулиан Леннон. 23.00 «Музыкага чикләр юк». Тапшыру премьерасы. 0.00 Төнге сеанс. «Символ крови» (АКШ).

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 8.45 «Пастырь сүзе». Митрополит Кирилл. 9.00, 15.00, 0.40 -- Яңалыклар. 9.20 «Лего-го!» 9.50 Балаларга фильм: «Секреты моего лета». 10.25 «Иртәнге почта». 11.00 «Татлы». 11.30 «Сәламәтлек». 11.45 Провинция. «Рус тармагы». 12.15 «Бомонд». 12.40 Михаил Ульянов һәм Элина Быстрицкая катнашында фильм: «Добровольцы». 14.25 «Көзге». 15.20 «Зур залда». Икенче бөтендөнья сугышында һәлак булучылар истәлегенә багышлана... 16.05 «Зур узышлар». 16.30 «Хайваннар дөньясында». 17.10 «Көлкеле манзара». Тапшыруны Е.Петросян алып бара. 18.25 Дөньяның иң яхшы автомобильләре Мәскәүдә. 18.50 Нәфис фильм: «Отдел по расследованию убийств». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.55 Телесериал: «Гиганты второй мировой». 2 нче серия. 22.55 «Брейн-ринг». 23.45 «Россиям, син генә булдырдың». Л.Зыкина җырлый.

#### «РОССИЯ»

8.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Шөрептән башлап». 8.45 «Мазай бабай кунакханәсе». 9.00 «Шәп авыл». 9.30 «Пилигрим. Россиянең сәяхәтләр бюросы». 10.15 Клип-антракт. О.Ходочинская. 10.20 Провинция җәүһәрләре. «Иске Русса — яңа танышу». 10.50 А.Гуриов. «Саф инглизчә репортаж». 11.00 «Мәскәүгә -- ерак». 11.45 Көндезге сеанс. Нәфис фильм: «Зов предков» (Италия, Бөекбритания). 13.25 Клип-антракт. Клементия. 13.30 «Алтын шпора». 14.20 «Де факто». 14.35 Өй экраны. «Мегрэ и церковный служка». «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм. 1 нче кисәк. 15.35 Сәнгать мәйданы. «Зур вальс». 16.10 Документаль фильм: «Сколько в России нефти и умных людей?» 1 нче кисәк. 17.00 «Тайны животных» телесериалыннан документаль фильм: «Здесь живут драконы» (Бөекбритания). 17.55 «Сентябрьдә кино». 18.10 Дэвид Копперфильд тылсымы. «Ниагара шарлавыгы үзгәрергә тиеш» 19.05 В.Гафт. «Чит язмышны үземнеке кебек уйныйм». 20.25 Телеэкран премьерасы. Нәфис фильм: «Мой лучший друг -- генерал Василий, сын Иосифа». 22.13 Киноафиша. 22.25 Джентльмен-шоу. 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «А» программасы. 0.40 «Төнге сөйләшү».

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.30 «Христос -- бөтен дөньяда». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан-туры элемтә». 10.00 Фильмоскоп. Нәфис фильм: «Ариэль». 11.25 Объектив. «Мой убегающий герой». (СДФ СПБ, 1992 ел). «Все прекрасно» («Лентелефильм», 1991 ел). 12.30 «Минем музыкам». Сева Новгородцев. 13.10 «Теледоктор». 13.30 Календарь. Сентябрь. «Тарихи альманах» циклыннан. 14.00 Тест. «Эшкә урнаштыру телевизион хезмәте». 14.15 Мультфильм: «Самый уважаемый». 14.25 «Көз» киноканалы. Нәфис фильм: «Пэпо». 16.00 Футбол. Россия чемпионаты. «Лада» (Тольятти) — «Зенит» (СПБ). Тольяттидан трансляция. 16.45 «Антре». Санкт-Петербургта шапито циркын ачу. 17.00 Футбол. Россия чемпионаты. «Лада» (Тольятти) -- «Зенит» (СПБ). Тольяттидан репортажның дәвамы. 17.45 Чайковскийның балачак альбомы. 1 нче тапшыру. 18.10 Чарли Чаплин фильмы музыкасына язылган фильм-балет: «Чаплиниана». 19.15 «Зур фестиваль». 19.30, 22.40 ТВ мәгълүматлары. 19.50 Телеэкранда детектив. Нәфис фильм: «Солдаты удачи». 21.25 Экспресс-кино. 21.35 «Оранж-ТВ» «Теләмәсәң — карама» каналы тәкъдим итә: «Самое», «Хлопушка», «Чистый звук». 22.25 «Теле-граф». 23.00 Нәфис фильм: «Гробница Мореллы» (АКШ).

## ЯКШӘМБЕ

### 3 СЕНТЯБРЬ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00-8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.10 Мультфильмнар. 18.40 «Бүген — Нефть һәм газ промышленносте хезмәтчәннәре көне». Тапшыруда «Татнефть» акционерлык җәмгыяте директоры-президенты Р.Г.Галиев катнаша. 19.00 «ТОН» (атналык телекүзәтү). 19.35 «Автокалейдоскоп». 19.50 «Программа-2». 20.05 Телебуклет. Тапшырулар анонсы. 20.15 «Әлли-бәлли-бәү». 20.20 Т.Миннуллин. «Әлдермештән Әлмәндәр». Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры спектакле. 22.45 Эльвира Хәйруллина җырлый. 22.55 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

7.00 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау). 8.35 Коммерция әйләнмәсе (31 август тапшыруын кабатлау). 9.00 Enter club. 9.30 Мультсериал: «Д'Артаньгав и три пса-мушкетера». 9.55 Нәфис фильм: «Мальчишка --- двойной агент». 11.35 «Чаплиниада». 12.00 «Кино музыкасы». 12.20 Нәфис фильм: «Приключения Кроша». 13.45 «Нью-Йорк, Нью-Йорк». 14.15 «Вояджер». 15.10 «Атна һәлакәтләре». 15.40 «Фитиль». 15.50 Нәфис фильм: «Неуловимые мстители». 17.15 Мультфильмнар. 17.35 Телесериал: «Тропическая жара». 18.35 «Минем пейджерым бар. Һәм мин тыныч!» 18.45 Телесериал: «Детективы на полставки». 19.45 «КиноМеню». 20.15 «Җирле вакыт». Информацион программа. 20.45 Триллер: «Сихерче тактасы» (АКШ). 22.25 Юл патруле. 22.40 Шәхси кичә: «Академия кабаре-дуэты». 23.45 «Исәнмесез!» (2 сентябрь тапшыруын кабатлау).

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 «Иртә». 9.00, 15.00, 0.40 -- Яңалыклар. 9.20 «Иртә таңнан». 9.50 Мультфильм: «Ошибка дядюшки Ау». 10.10 «Бар да өйдә чакта». 10.45 «Иртәнге йолдыз». 11.30 «Россиягә хезмәт итәм». 12.00 Телесериал: «Лики Земли». 1 нче фильм. «Поророка на Амазонке» (Япония). 12.50 «Бөтен Россия». «Үткән һәм киләчәк арасында». 13.15 «Уйна, гармун». Геннадий Заволокин «Бәхетле кеше» программасында. Нижний Новгородтан тапшыру. 13.45 «50 ел элек бу көннәрдә». Соңгы тапшыру. 14.00 «Пи» билгесе астында. 14.40 «Волгоград. Әрем...» 15.20 «Хыял вокзалы». Ю.Башмет. 16.10 «Сәяхәтчеләр клубы». 17.05 «Европага тәрәзә». Тапшыруны Д.Киселев алып бара. 17.35 Мультсериал: «Приключения капитана Врунгеля». 5 нче һәм 6 нчы серияләр. 18.00 Вакыт. 18.20 «Алтын кадр». Ираклий Андроников. 19.05 «Күзгә-күз». А.Любимов алып бара. 19.30 «Кумирлар, кумирлар...» «Наутилус Помпилиус». 20.15 Луи де Фюнес «На древо взгромоздясь» кинокомедиясендә (Франция — Италия, 1971 ел). 22.00 «Якшәмбе». 23.00 Телесериал: «Гиганты второй мировой». 3 нче серия. 0.05 «Бер күрүдә ярату».

#### «РОССИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Беренче дубль». 8.45 «Алтын ачкыч». 9.00 В.Беляев повесте буенча музыкаль спектакль: «Человек-амфибия». 9.40 «Футболга чикләр юк». 10.25 «Хәерле иртә, Европа!» 10.55 «Аты, баты...» 11.25 «Консолидация». 11.30 «Рус лотосы». 12.15 Мульти-пульти: «Пластилиновая ворона». 12.25 Көндезге сеанс. Нәфис фильм: «Дневник директора школы». 13.45 К.Мажейка. «Параллельләр». 14.20 «Кисеп бетерә алмаслык...». 14.35 Өй экраны. «Мегрэ и церковный служка». «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм. 2 нче кисәк. 15.25 «Синең мөмкинлекләрең, кеше!» 15.55 «Музыкаль экспромт». 16.05 «Фаэтон». Информацион-күңел ачу программасы. 16.35 Документаль фильм: «Сколько в России нефти и умных людей?» 2 нче кисәк. 17.25 «Веди». 18.00 Диснейның тылсымлы дөньясы: «Русалочка», «Новые приключения Винни-Пуха». 18.55 «Мода хәбәрчесе». 19.25 «Ксюшада кунакта». 20.25 Голливудта төшерелгән. Нәфис фильм: «Засада». 22.35 Клип-антракт. В.Казаченко. 22.40 «Тапшырулар тартмасы». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 XX гасыр кадрда һәм кадр артында. «Франсуа Трюффо».

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Бу сезнең көнегез». 7.30 «Шифалы сүз». 8.00 «Хәерле иртә». 9.00 «Турыдан-туры элемтә». 9.55 Көнлек телевизион программа. 10.00 Телеэкранда детектив. Нәфис фильм: «Солдат удачи». 11.30 «Могҗиза тудыру». «Нерв» производство берләшмәсе. 1991 ел. 12.00 «Якшәмбе лабиринты». 13.15 Нәфис фильм: «В моей смерти прошу винить Клаву К.». 14.30 «Классика-5». «Ян, ян, минем йолдызым». Борис Штоколов бенефисы. 15.30 «Депутатларга сүз бирәбез». 16.00 «Палитра» циклыннан телефильм: «Вюйяр» (Франция). 16.30 Чайковскийның балачак альбомы. 2 нче тапшыру. 17.00, 17.50 Баскетбол. Россия чемпионаты. «Спартак» -- «Автодорожник» (Саратов). «Юбилейный» спорт сараеннан трансляция. 17.40 Кечкенә концерт. 17.50 18.30 Мультфильм: «Сказ о Пере-богатыре». 18.40 Алкышлап! Сергей Галанин һәм «Серьга» төркеме. 19.30, 23.15 ТВ мәгълүматлары. 19.50 Безнең кино. Нәфис фильм: «Нелюдь, или В раю запрещена охота». 22.15 Рок легендасы: Вилли Нельсон. 23.40 «Адәм алмасы». 0.40 Рок легендасы: Вилли Нельсон (дәвамы).

## ДҮШӘМБЕ, 28 АВГУСТ

6.00, 19.15 — Соңгы хәбәрләр. 6.15 Иртәнге дулкында. 6.53, 7.58 — Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.00 Информацион-музыкаль программа. 7.45 — Тапшырулар программасы. 8.00, 18.30 — Радио-1. 17.45 «Җырлап узган җәй». 18.15 «Дүшәмбедән-дүшәмбегә». Мәдәният яңалыклары. 19.40 «Татар җыры-95» конкурсы лауреатлары һәм дипломантлары чыгыш ясый.

## СИШӘМБЕ, 29 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 -- Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.53 -- Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.53 -- Тапшырулар программасы. 8.00, 14.30, 18.30, 21.00 -- Радио-1. 12.25--14.30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы. Чыгарылышта: 12.30 «Җырым синең хакта, республикам!» 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 13.30 «Юллар чатында» информацион программасы. 13.45 «Турыдан-туры элемтә». 14.30 «Бердәмлек». Музыкаль программа. Чыгарылышта: Татарстан Республикасы көнен каршылап. «Җырлыйм сиңа, республикам!» Сәнгать осталары һәм музыкаль коллективлар концерты. 15.00 Татарстан Республикасының дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул итүгә 5 ел тулуга багышланган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Дәүләт Советының берләштерелгән тантаналы җыелышыннан һәм концерттан трансляция. 18.30 «Яшьлек» студиясе. 19.45 Сораулар буенча концерт.

## ЧӘРШӘМБЕ, 30 АВГУСТ

### ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КӨНЕ

6.02 Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиевнең бәйрәм котлавы. 6.05 «Татарстан дулкынында». Махсус чыгарылыш. 6.53. 7.58. -- Һава торышы. 6.55, 7.50 -- Белдерүләр. 7.00 Татарстан Республикасы Президенты М.Шәймиевнең бәйрәм котлавы. 7.15 Концерт. «Без Татарстан җирендә яшибез». 7.45, Тапшырулар программасы. 8.00, 11.00, 15.00, 17.00 --- Радио-1. 8.15 Язучы чыгышы. Р.Миннуллин. 8.30 Туган илем --- гүзәл Татарстан. 9.00 Әдәби редакция программасы. «Эзләнү һәм ирешү мизгелләре». 9.30 «Республикам, туган халкым бар». Әдәби-музыкаль композиция. 10.00 «Җитлегү». 10.30 Н.Җиһанов. «Сабантуй» симфониясе. 12.25 «Без Татарстан җирендә яшибез». Сәнгать осталары концерты. 12.30 «Тынычлыкта һәм бердәмлектә» (чуваш телендә). 13.50 «Шушы яктан, шушы туфрактан без». 14.30 «Яшьлек» студиясе. 15.15 Республикада бәйрәм көннәре. (Татар һәм рус телләрендә).

## ПӘНҖЕШӘМБЕ, 31 АВГУСТ

6.00, 7.00, 13.05, 19.15 -- Соңгы хәбәрләр. 6.15 «Иртәнге дулкында». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 -- Һава торышы. 6.55, 7.50 — Белдерүләр. 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 -- Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 -- Радио-1. 12.30 «Балалар җырлый». 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.05 «Сәламәтлек». 19.45 «Композитор Н.Зарипова». Концерт-очерк.

## ҖОМГА, 1 СЕНТЯБРЬ

6.00 «Балкыш». 6.53, 7.58, 13.25, 20.38 -- Һава торышы. 6.55, 7.50 --- Белдерүләр. 7.00, 13.05, 19.15 -- «Соңгы хәбәрләр». 7.15 Концерт. 7.45, 12.25, 20.38 -- Тапшырулар программасы. 8.00, 13.30, 18.30, 20.45 -- Радио-1. 12.30 Симфоник музыка концерты. 13.10 Республика газеталарына күзәтү. 18.00 «Чишмәләр» (чуваш телендә). 19.45 Эстрада ритмнары.

## ШИМБӘ, 2 СЕНТЯБРЬ

6.00, 7.00 --- Соңгы хәбәрләр. 6.15 Авыл эшчәннәре өчен концерт. 6.58, 7.58, 14.30 -- Һава торышы. 7.15 Иртәнге концерт. 7.45, 14.30 -- Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00, 11.00, 14.35 -- Радио-1. 8.20 «Мәсьәләгә бер караш». 8.40 «Көмеш кыңгырау». 9.00 «Сентябрь». Шигърият программасы. 9.30 «Бар җырымны илгә багышладым». М.Җәлил шигырьләренә радиокомпозиция. 10.00 «Кыска хикәяләр». 10.30 «Пар канатлар». 11.45 «Кардәшлеккә чикләр юк». 12.15 Татар халык көйләре. 13.10 Яңалыклар эстафетасы. 13.30 «Яшьлек» студиясе. 14.00 «Сезнең хакта һәм сезнең өчен».

## ЯКШӘМБЕ, 3 СЕНТЯБРЬ

7.02, 7.58, 13.40 -- Һава торышы. 7.04 «Хәерле иртә!» 7.45, 13.40 -- Тапшырулар программасы. 7.50 Белдерүләр. 8.00 «Идел белән Урал арасында». Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы. 9.00 Г.Исхакый. «Борынгы шәкертләр». Хикәя. 9.35 Шигърият. 10.15, 15.40 -- Радио-1. 11.45 «Изгелекне һәм яктылыкны яклап». Өлкәннәр һәм балалар өчен программа. 12.15 «Тел күрке — сүз». 12.45 Ял концерты. 13.45 «Татарстан дулкынында». 14.25 Р.Мингалим. «Кунак кызы гел килмәс». Әлмәт татар дәүләт драма театры спектакле.

Мулланур Вахитовның тууына 110 ел

# КОМИССАРНЫҢ ЯҢАДАН «ТУУЫ»

Озак еллар дəвамында Мулланур Вахитов татар халкы тарихының башлангыч совет чорында иң купшы һəм иң мактала торган шəхес булып йөрде. Зирəк комиссар, турылыклы большевик, интернационализм өчен ялкынлы көрəшче һəм хəтта ки Ленинның якын дусты! Аның исемен урамнар һəм пароходлар, мəктəплəр һəм заводлар йөртте... «Ленинны һəм Вахитовны өйрəнүчелəр»нең күпсанлы гаскəре, кайбер əдиплəр белəн бергə, Вахитовтан партиянең һəм юлбашчыларның телəсə нинди күрсəтмəсен бер карусыз үтəргə əзер торган «кургашын солдат» ясадылар. Гəрчə күп мəсьəлəдə партиянең программасын һəм аның гамəли эшчəнлеген хупласа да, формаль рəвештə ул бу партиядə тормый.

М.Вахитов 1918 елның августында атып үтерелə. Лəкин хəзергə кадəр бу əле ачыкланмаган, һəм Вахитовның үлеме турында төрле фаразлар бар. Аның үлемен татарның күренекле сəяси эшлеклелəре Г.Исхакыйга, Ф.Туктаров һəм Г.Терегуловка сылтыйлар. Хəтта ки, аны атарга да алар ук боерык биргəн, имеш. Вахитовның үлемен политиканлыкка кадəр төшереп ваклыйлар, һəм бу традиция безнең көннəргə кадəр дəвам итə. Əле 60 нчы елларның ахырында гына да Ленинны өйрəнүчелəрдəн берəү моны расланган факт, дип язып чыкты.

Шуңа күрə, үзгəртеп кору чоры башлангач, кешелəрнең аңында милли хəрəкəтне кысучы, большевикларның турылыклы ялчысы дип, Вахитовка карата тискəре мөнəсəбəтнең тууы очраклы хəл түгел. Бу фикерне митингларда кычкырып йөрүче, бик үк мəгълүматлы булмаган «миллəт аталары һəм миллəт аналары» да кыздырып тордылар.

Ə хəллəр күпкə катлаулырак була шул. «Өченче дөнья»ның революция теориясен тудыручы һəм «милли коммунизм» атасы буларак XX гасыр тарихына кергəн Мирсəет Солтангалиев 20 нче еллар башларына хəтле үзен Мулланур Вахитовның шəкерте дип йөри һəм үз идеялəрен фаҗигале рəвештə һəлак булган мөгаллиме фикерлəре һəм ниятлəренең дəвамы дип саный. Һəрхəлдə, Вахитов бервакытта да милли хəрəкəтне большевикларның, советның яңартылган империя структураларына берсүзсез буйсындыру ягында булмый. Бу структураларның тууын ул алдан күрə... 1918 елның башында аның демонстратив рəвештə комиссар постыннан отставкага китүе бик зур резонанс тудыра. Һəм Мулланурның бу гамəлен башка күренекле эшлеклелəр дə хуплый. Шуңа күрə Сталин җитди ташламаларга барырга һəм Вахитовның кире кайтуын үтенергə мəҗбүр була. Көнчыгыш халыкларының милли мəнфəгатьлəрен яклаучы буларак, мөселман Кызыл Армиясен оештыру идеясе, Вахитов үлгəннəн соң, миллəтчел һəм зарарлы дип табыла. Ул вакытта милли дəүлəтне республика итеп төзү вариантының дошманнары буларак, Грасис, Шамигулов, Шаһимəрдəн Ибраһимовларның һ.б. «милли нигилистлар» һəм ата бəйнəлмилəлчелəрнең Вахитовны күралмаулары очраклы булмаган, күрəсең. Ленин белəн Сталин, билгеле бер этапта милли хəрəкəткə якты чырай күрсəтеп, төрек республикалары төзүгə ризалык биреп, алдан күрүчəнлек күрсəтəлəр.

1918 елның августында большевизимга каршы булган кечерəк кенə отряд Казандагы зур гарнизонны тар-мар итə һəм кыска вакытка шəһəрне билəп ала. Казан тарихында шушындый хəтəр көннəр булмаса, Мулланурның язмышы кая таба китəсен əйтүе авыр. Гражданнар сугышы тəмамланганнан соң, совет власте дə аның хөр фикерлелегенə чыдап тормас иде, дип уйлыйм. Солтангалиев фаҗигасе — Вахитов язмышының көзгедəге чагылышы, дияргə кирəктер.

Белмим, Вахитовны шəһəр буйлап бəргəлəнеп йөрергə, аннары инде шəһəрдəн китəргə маташырга нинди сəбəплəр мəҗбүр иткəндер — болар берсе дə безгə мəгълүм түгел, һəм инде без аны бервакытта белə дə алмабыз. Һəрхəлдə, ул шəһəрдə яшерен большевистик оешма төзергə калган булырга тиеш, дигəн фикер бик тə шикле күренə. Аның якыннарына төрмəдəн язган хатлары бар. Алар бик фаҗигале тонда язылган, һəм алардан Вахитовның һəлакəткə дучар булуын аңлаганлыгы сизелеп тора. Аларда сəясəт бөтенлəй юк.

Кайчакта, нишлəп соң Вахитов большевикларны сайлаган, ул бит Учредительное собраниегə башка исемлек буенча үткəн, дилəр. Нишлəргə тиеш иде соң ул? Большевикларның барлык дошманнары бөекдержавачылык шовинизмы һəм «бердəм, бүленмəс» позициясендə торалар. Хəтта шул Колчак кына да казакъ һəм башкорт милли хəрəкəтлəренең иң нəни үтенечлəрен дə катгый рəвештə кире кага. Шулай булгач, Вахитов сайлаган юлның дөреслеген танырга туры килə. Үткəнебезгə ничек кенə карасак та, милли республикаларны большевиклар, Ленин, Сталин төзи. Большевик лидерларының бу мəсьəлəдəге позициясен мөселман халыкларының ул чактагы иң абруйлы эшлеклесе Мулланур Вахитов тирəнəйтергə, җиңүгə таба илтергə омтыла. Бу эшнең барып чыкмавы һəм сəгате куелган шартлаткычның инде безнең заманда шартлавы аның да, аның дəвамчыларының да гаебе түгел.

Шуның өчен генə дə без, милли өметлəрен тормышка ашырыр өчен күп нəрсəгə ия була алган Татарстанның барлык халкы, аңа рəхмəт укырга тиештер. Мөстəкыйль җөмһүрият һəм дөнья җəмəгатьчелеге тарафыннан таныла барган абруйлы Президент, эшкə сəлəтле хөкүмəт, үсеп килə торган парламент — бу болганчык заманыбыз өчен болар азмы əллə? Татарстан суверенлыгының биш еллыгын билгелəп үткəндə, бүген чынбарлыкка əверелгəн нəрсəлəрнең күбесен алдан күрə алган кешене онытырга ярамый, дип уйлыйм. Аңа карата игелекле сүзлəр əйтелеп, һəйкəленə чəчəклəр куелса — бу бик гадел һəм вакытлы гамəл булыр иде.

**Булат СОЛТАНБƏКОВ,**
**тарих фəннəре кандидаты.**

Җəһəт əңгəмə

# КИЛƏЧƏККƏ КАЙТЫП БАРЫШ, ДУСТЫМ

***Мөдəррис Əгълəм... Теле үткен, һəр җавабы — канатлы сүзгə тартым. Шигырьлəрендə — халык язмышы, халык кайгысы. Əйтсə, берəгəйле əйтə. Əйдəгез, шагыйрьнең үзен тыңлап карыйк.***

**— Мөдəррис абый, кеше Җиргə каян килгəн?**

— Күктəн түгел, əлбəттə. Без барыбыз да, җир-су хайваннары һəм үсемлеклəре кебек, җирдə барлыкка килгəнбез. Католиклар да, православиелелəр дə, мөселманнар да — Җир кешелəре. Бер җирдə яшəсəк тə, җанварлар кебек бер-беребезне һəрвакыт ашарга əзербез. Бу — җиһан кануны. Кем җиңəр?

**— Əдəбият нəрсə ул?**

— Кеше сөйлəшə, яза башлау белəн акылын җуйган. Димəк, əдəбият — ул акылдан язу, дигəн сүз.

**— Без татармы?**

— Болгар дигəн дəүлəт булган, əмма болгар дигəн миллəт беркайчан да булмаган. Без — татарлар. Борынгы кыпчак галиме Кашгарый (IX гасыр) төзегəн картада Татарстан гына бар. Стан — ул йорт дигəн сүз. Болгар аңа буйсындырылган дəүлəт булган. Идел — Əтил, Иртыш — Артыш, Ангара — Өндер һ.б. Алимуш хан Болгар дəүлəтен төзегəн дигəн сүз чеп-чи ялган ул. Кашгарый Идел буенда Болгар халкы яши дип əйтмəгəн. Димəк — без татарлар.

**— Миллəт нəрсə?**

— Җир йөзендə башкорт, керəшен, типтəр, нугай, казак халыклары яши, əмма алар арасында татар дигəн бер миллəт тə бар.

**— Ə сəясəт синеңчə нəрсə?**

— Иң зур ямьсезлек сəясəттəн башланган. Ямьсезлек бар икəн, сəясəт тə бар. Сəясəт бар икəн, ямьсезлек тə булырга тиеш. Бүген мин — бар, иртəгə мин юк, дигəн кешелəр эше ул сəясəт.

**— Икътисад нəрсə?**

— Татарлар акча баса башлагач килеп чыккан нəрсə ул. Тиен белəн тəңкə — деньги, күп 00000 — купец, копейка булып калган. Акча безнеке булгач, икътисад та безнеке инде.

**— Əхлак нəрсə?**

— Үзең сайлап алган һəм үзеңə генə хас яшəү рəвеше ул. Дөрес дип саныйсың икəн, ул — дөрес, дөрес дип санамыйсың икəн, дөрес түгел.

**— Кемнəр белəн укып, кемнəр белəн яшəп кеше булдым, дип уйлыйсың?**

— Зөлфəт һəм Фəрит Гыйльметдиновлар белəн очрашу — тормыштагы иң зур бəхетем.

**— Алла бармы?**

— Мин бар икəн, димəк, каяндыр килгəнмен. Минем ата-бабамнар да каяндыр килеп чыккан. Кем иҗат итте икəн минем беренче башлангычымны? Менə шушы сорауга җавап бирə алсаң, мин дə синең соравыңа җавап бирə алырмын.

**— Җиргə төшкəн яңа «пəйгамбəр» Диас Вəлиевнең «Я» романына ничек карыйсың?**

— Йə — бар, йə — юк.

**— Шигърият исəнме əле бездə?**

— Матбугат битлəрендə шигырьлəрдəн дə күп нəрсə юк. Рифма-ритм белəн генə язу шагыйрь булдым дигəн сүз түгел. Чорыбыз графоманнар үрчеп киткəн егерменче, утызынчы елларны хəтерлəтə. Əмма эчке агым барыбер исəн.

**— Акчаң бармы?**

— Зарланганым юк.

**— Мəхəббəткə ничек карыйсың?**

— Ансыз яшəп булмый.

**— Хəзер кая китəргə җыенасың?**

— Килəчəккə кайтып барыш, дустым, килəчəккə...

**Əңгəмəне Заһид МƏХМҮДИ оештырды.**

## ҖАВАП — САВАП

# Мономах бүреге

***Урыс тарихында «Мономах бүреге» дигән гыйбарә бар, «Авыр да соң син, Мономах бүреге», дигән әйтем дә йөри. Нинди бүрек соң ул, ничә килограмм тарткан икән?***

***И.ГЫЙЛӘҖЕВ.***
*Чирмешән.*

Мономах бүреге... Беренчедән, ул аныкы булмаган, чөнки Владимир Мономах 1125 елда үлгән. Ә бүрек, ул үлгәннән соң, 200 ел үткәч кенә эшләнгән.

Мономах бүреге турында тарихта беренче тапкыр XIY гасырда Иван Калита васыятендә телгә алына. Әмма Калита бүрекне «Мономах бүреге» дип атамаган, васыятьтә ул «алтын бүрек» дип кенә әйтелгән. Аның варислары да буыннан-буынга әтиләре таҗын «алтын бүрек» дип кенә тапшыра килгәннәр.

Бу алтын бүрек «Мономах бүреге» дип XYI гасырда Явыз Иван рухи грамотасында телгә алына. Чынында исә «Мономах бүреге» Иван Калитага Алтын Урда ханы Үзбәк тарафыннан бүләк ителгән була. Авырлыгына килгәндә... ул 698 грамм. «Авыр да соң син, Мономах бүреге» дигәне бүрек авырлыгына түгел, ә бәлки власть, хакимлек итүнең авырлыгына ишарәле.

## КЫЗ ЙОЛДЫЗЛЫГЫ КАСТЫНДА ТУГАННАР

# КОТЛЫЙБЫЗ!

**25 август**

**ГАМБӘРОВ** Наис Гыймран улы — шагыйрь, тәнкыйтьче, «Казан утлары» журналының җаваплы сәркатибе.

**МИҢНУЛЛИН** Туфан Габдулла улы — драматург.

**МӘҖИТОВ** Зәет Мәҗит улы — әдәбият галиме, шагыйрь.

**27 август**

**ӘХСӘНОВ** Илдар Гали улы — шагыйрь, публицист.

**28 август**

**ТИМЕРГАЛИНА** Алсу Адлер кызы — рәссам.

**ХАЛИУЛЛОВ** Исмәгыйль Минтаһир улы — рәссам, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

**29 август**

**ВОРОНОВ** Владимир Александрович — Казан дәүләт консерваториясе проректоры, РФнең атказанган сәнгать эшлеклесе.

## ИҖТИҺАТ

**И**лдә саф җилләр исеп киткәч, җөмһүриятебезнең сәяси һәм мәдәни тормышында **бик** күп көчле шәхесләр пәйда булды. **Запаста**гы полковник, техник фәннәр докторы, **Ш.Мәрҗани** исемендәге мәдәни-агарту җәмгыяте президенты **Зәки** ага Зәйнуллин әнә шундый шәхесләрнең берсе **инде.** Аны, 1991 елда Татарстан халкының Русия Президентын сайлауда катнашуына каршы протест белдереп, бер төркем милләтпәрвәрләр белән Ирек мәйданында 12 көн ачлыкта утырган көрәшче буларак та беләбез. Шуның өстенә, ул — бер дигән язучы, публицист та. Зәки аганың матбугатта дөнья күргән саллы-саллы повесть һәм хикәяләре, көн кадагына суга торган ялкынлы язмалары киң катлау укучылар арасында зур кызыксыну тудырды. Әмма ул тагын да киңрәк колачлырак кеше икән. Аның агачтан төрле матур сыннар эшләүче гаҗәеп кызыклы һәм бай фантазияле оста булуы бик азларга гына мәгълүмдер әле.

**Рәсемдәге сыннарга карагыз. Аларда — халык язмышы, сезнең һәм безнең язмышыбыз.**

# Исем-фамилиядәге баш хәрефләр ни сөйли?

Кешенең холык-фигылен билгеләүнең төрле ысуллары бар. Шуларның берсе — инициал хәрефләренең мәгънәсе. Алар түбәндәгеләрне аңлата икән:

А — көч һәм хакимият.

Б — олы хисләргә сәләт.

В — аумакайлык, системалылыкның булмавы.

Г — серлелек.

Д — аралашучанлык, кешеләрне үзеңә җәлеп итү.

Е — тиз рәвештә эшкә керешү, чыдамлылык.

Ж — ышанычсызлык.

З — шикләнүләргә бирелүчәнлек, матди авырлыклар, канәгатьсезлек.

И — тәэсирләнүчәнлек, киеренкелек.

К — зур ихтыяҗлылык, аларга ирешүдә үтә борчылу.

Л — ваклык, мантыйклык, тапкырлык.

М — хезмәт сөючәнлек, үтә вакчыллык.

Н — олы энергия һәм иҗади тәкәбберлек.

О — олы хиссият, серле дулкынлану.

П — тыйнаклык, кешене якын җибәрмәү, шулай ук ялгызлык.

Р — даими киеренкелек, көчле тәэссорат.

С — депрессияләр, күңел төшенкелеге, гасабилану.

Т — чиксез эзләнүләр, идеягә омтылу.

У — борчылу, курку, сиземләү.

Ф — ягымлылык, яраклаша алучанлык.

Х — сексуаль проблемалар, хисләрнең тотрыксызлыгы.

Ц — эчке кичерешләрне тышка чыгаруга омтылу.

Ч — тугрылык.

Ш — көнчелек, килешмәүчәнлек.

Щ — үч алучанлык, интеллектуаль сәләт үсеше.

Э — психологик тигезләнеш эзләү.

Ю — таркаулык, олылык, тәкәбберлек.

Я — зыялылык, иҗади сәләт.

## ГАЗЕТА ҺӘМ УКУЧЫ

# Мәрхабә сиңа, «Мәдәни җомга!»

*Хөрмәтле вә гыйззәтле милләттәшләр, могтәбәр гәзит-ханнар-зыялылар, ошбу көннәрдә күңелебез дәрьядай, шатлык хисләре кичермәктә. Мәгълүм ки, рухи башкалабыз шәһри Казанда күптән түгел, июль аеның изге җомга көнне, татарның атналык әдәбият-сәнгать җаридәсе — гәзите «Мәдәни җомга»ның беренче саны дөнья күрде. Егерме дүрт сәхифәдә тәкъдим кылынган мәгълүмат җәүһәрләрен ихлас вә мөкиббән китеп укыйсың — үзе бер тарихи дөнья ич, билләһи! Ә газиз телебез хосусиятләренә милли җавапчан мөнәсәбәт?! Иншаллаһ, «Мәдәни җомга»быз, әстәгъфируллаһел газыйм, әллә нинди катнаш телдә эш йөртмәс — әкренләп татарның классик-чын әдәби теленә йөз тотар, шул кыйбланы мәсләк санар, халкыбызның күңел шәрифен урыс боламыгыннан коткарыр.*

*Мөхәрририят хезмәткәрләренә саулык-сәламәтлек, иман камиллеге телибез, иҗтиһат — алардан, тәүфыйкъ Аллаһудан насыйб әйләсен... «Өмет»нең өмете мөкәммәл ки, Башкортстан халкы да «Мәдәни җомга»га язылыр, аны, һичшиксез, яратып укыр, безләр исә атналыкны гомерле итүгә кадәри хәл үз өлешебезне кертергә тырышырбыз.*

***Фаил ФӘТХЕТДИН,***
*Башкортстандагы татар яшьләренең «Өмет» гәзите баш мөхәррире.*
***Равил УТӘБАЙ-КӘРИМИ,***
*Шәрык вә Исламият белгече.*

***Бу санда Рушан Шәмсетдинов, Мансур Рәхимов, Ринат Хәсәншин, Айдар Үтәгәнов, Рамил Галиев, Рөстәм Мөхәммәтҗанов (1 нче бит), Мидхәт Шакирҗанов рәсемнәре, Әкрам Шәфигуллин төшергән һәм авторларның шәхси архивыннан алган фотолар файдаланылды.***

Мәдәни ҖОМГА

**Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла**

**Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ**

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

**Телефоннар:**
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге;
32-59-55 — халык тормышы, рухият не яктау;
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

Газетада басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен заказлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрнең тәгаллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
**609403 МФО 265565 в Бауманском отд. ПСБ**

**Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде**

**Индекс — 54129**

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре уңаеннан 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга

Газета редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

**Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе**

**Тираж 8000**
**Заказ 4454**